| 200. | Габделгалләм | 106 |
| 201. | Гәрәй | 107 |
| 202. | Хәсәнҗан | 107 |
| 203. | Закир | 108 |
| 204. | Габделкадыйр | 108 |
| 205. | ? (бозылган) | 110 |
| 206. | Фәйзерахман | 110 |
| 207. | Исхак | 112 |
| 208. | Ибраһим | 112 |
| 209. | Габделбарый | 114 |
| 210. | Габделәхәт | 114 |
| 211. | Хаҗи | 114 |
| 212. | Закир | 124 |
| 213. | Нәҗип | 124 |
| 214. | Фатих | 124 |
| 215. | Хаҗи | 124 |
| 216. | Әхмәтфатих | 126 |
| 217. | Хаҗи | 126 |
| 218. | Әхмәтгариф | 126 |
| 219. | Мөхәммәтшәриф мулла | 126 |
| 220. | Зариф | 126 |
| 221. | Мөхәммәтгариф | 126 |
| 222. | Габдерахман | 126 |
| 223. | Хәсән | 127 |
| 224. | Ибраһим | 127 |
| 225. | Закир | 128 |
| 226. | Шакир | 128 |
| 227. | Йосыф | 128 |
| 228. | Галимҗан | 132 |
| 229. | Йосыфҗан | 132 |
| 230. | Хәким | 135 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 231. | Касим | 135 |
| 232. | Ширияздан | 135 |
| 233. | Фатыйма | 136 |
| 234. | Нигъмәтулла | 137 |
| 235. | Сабирҗан | 138 |
| 236. | Габделҗаббар | 138 |
| 237. | Габдерахман | 138 |
| 238. | Шакирҗан | 138 |
| 239. | Габдулла | 138 |
| 240. | Габидулла | 138 |
| 241. | Мулла Таһир | 138 |
| 242. | Габденасыйр | 141 |
| 243. | Габделхак | 141 |
| 244. | Габделгалим | 141 |
| 245. | Мөхәммәтгали | 141 |
| 246. | Габделкәрим | 141 |
| 247. | Йосыф | 142 |
| 248. | Хөсәен | 142 |
| 249. | Хәсән, Ленинград шәһәрендә яшәгән | 142 |
| 250. | Исхак | 143 |
| 251. | Сөләйман | 143 |
| 252. | Бибигарифә | 143 |
| 253. | Ибраһим | 143 |
| 254. | Хәсән хаҗи | 143 |
| 255. | Исмәгыйль | 143 |
| 256. | Хөсәен | 144 |
| 257. | Галим | 145 |
| 258. | Йосыфҗан | 145 |
| 259. | Мөхәммәт | 146 |
| 260. | Хөснетдин | 147 |
| 261. | Исмәгыйль | 147 |
| 262. | Вәли | 148 |
| 263. | Хәкимҗан | 149 |
| 264. | Гатаулла | 150 |
| 265. | Әхмәтгариф | 150 |
| 266. | Габдерахман | 150 |
| 267. | Фәйзерахман | 150 |
| 268. | Ибраһим | 150 |
| 269. | Исхак | 151 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 270. | Сабирҗан | 151 |
| 271. | Гатаулла | 151 |
| 272. | Әхмәтшаһ | 156 |
| 273. | Газизҗан | 156 |
| 274. | Моталлап | 156 |
| 275. | Хәсәнҗан | 156 |
| 276. | Сәгьдетдин | 163 |
| 277. | Садрыйислам | 163 |
| 278. | Хәсән | 164 |
| 279. | Габдерахман | 165 |
| 280. | Габделкәрим | 165 |
| 281. | Мөхәммәтгариф | 166 |
| 282. | Габделвәли | 166 |
| 283. | Мөхәммәтзариф | 166 |
| 284. | Хәсәнбай | 166 |
| 285. | Йосыф | 168 |
| 286. | Габдулла | 169 |
| 287. | Әхмәтҗан | 169 |
| 288. | Мөхәммәтгали | 170 |
| 289. | Зариф | 175 |
| | *IX буын* | |
| 290. | Мөхәммәтфатих | 179 |
| 291. | Газизә | 185 |
| 292. | ? (бозылган) | 185 |
| 293. | Габделхак | 189 |
| 294. | Габделхәй | 189 |
| 295. | Садыйк | 189 |
| 296. | Габделбарый | 189 |
| 297. | Мөбарәкша | 189 |
| 298. | Шәмсемөхәммәт | 192 |
| 299. | Габделгали | 192 |
| 300. | Габделбарый | 192 |
| 301. | Габделхаликъ | 192 |
| 302. | Шакирҗан | 192 |
| 303. | Закирҗан | 192 |
| 304. | Мөхлисулла | 194 |
| 305. | Габделхалит | 194 |
| 306. | Наил | 198 |
| 307. | Мәҗит | 199 |
| 308. | Хәмит | 199 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 309. | Габделхаликъ | 203 |
| 310. | Габделхәй | 204 |
| 311. | Шакир | 204 |
| 312. | Исхак | 205 |
| 313. | Миңнемулла | 205 |
| 314. | Мөхетдин | 205 |
| 315. | Мөбарәкша | 205 |
| 316. | Хәбибрахман | 221 |
| 317. | Габделхак | 205 |
| 318. | Габдулла | 205 |
| 319. | Исмәгыйль | 205 |
| 320. | Сабир | 205 |
| 321. | Исмәгыйль | 208 |
| 322. | Муса | 208 |
| 323. | Нәкыйп | 210 |
| 324. | Кәшшаф | 210 |
| 325. | Рәшит | 210 |
| 326. | Зариф (Тәкыя) | 213 |
| 327. | Мөхәммәтшәриф | 213 |
| 328. | Хөсәен | 221 |
| 329. | Габдерахман | 221 |
| 330. | Гариф | 225 |
| 331. | Зариф | 225 |
| 332. | Гариф | 240 |
| 333. | Һади | 242 |
| 334. | Гомәр | 243 |
| 335. | Габделҗаббар | 244 |
| 336. | Габдесаттар | 244 |
| 337. | Габдерахман | 244 |
| 338. | Габделхак | 248 |
| 339. | Мулла Йосыф | 248 |
| 340. | Габделкотдус | 248 |
| 341. | Габдерәүф | 248 |
| 342. | Әхмәтгали | 252 |
| 343. | Хәмзә | 252 |
| 344. | Исмәгыйль | 252 |
| 345. | Мостафа | 252 |
| 346. | Әхмәтгани | 252 |
| 347. | Мөхәммәтгали | 254 |
| 348. | Әхмәтгали | 254 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 349. | Габдерахман | 254 |
| 350. | Габделәхәт | 256 |
| 351. | Фәйзерахман | 256 |
| 352. | Габдуллаҗан | 256 |
| 353. | Хәсәнҗан | 257 |
| 354. | Исхак | 259 |
| 355. | Мөхәммәтшәриф | 259 |
| 356. | Хөснетдин | 260 |
| 357. | Вәли | 260 |
| 358. | Тимергали | 260 |
| 359. | Нәҗибә | 260 |
| 360. | Мәрьям | 261 |
| 361. | Нигъмәтулла | 262 |
| 362. | Гомәр | 264 |
| 363. | Галимҗан | 264 |
| 364. | Исмәгыйль | 269 |
| 365. | Габделбәр | 275 |
| 366. | Шәмсетдин | 275 |
| 367. | Шакир | 279 |
| 368. | Исмәгыйль | 279 |
| 369. | Гобәйдулла | 279 |
| 370. | Габдулла | 286 |
| 371. | Исмәгыйль | 286 |
| 372. | Әхмәтзыя | 287 |
| 373. | Габдулла | 287 |
| 374. | Барый | 287 |
| 375. | Ибраһим | 287 |
| 376. | Исмәгыйль | 287 |
| 377. | Мөхәммәтшәриф | 287 |
| 378. | Гомәр | 288 |
| 379. | Габдерахман | 288 |
| | *X буын* | |
| 380. | Һашим | 292 |
| 381. | Касыйм | 292 |
| 382. | Суфыя | 292 |
| 383. | Мәхмүт | 295 |
| 384. | Галимулла | 321 |
| 385. | Мостафа | 321 |
| 386. | Мостафа | 321 |
| 387. | Фатих | 339 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 388. | Фоат | 339 |
| 389. | Хәдичә | 341 |
| 390. | Касыйм | 342 |
| 391. | Гомәр | 341 |
| 392. | Рәхимҗан | 341 |
| 393. | Рәхимҗан | 341 |
| 394. | Галимҗан | 342 |
| 395. | Сабирҗан | 342 |
| 396. | Мөхәммәтҗан | 342 |
| 397. | Шәрифҗан | 342 |
| 398. | Габдулла | 342 |
| 399. | Сәлимҗан | 347 |
| 400. | Хәмит | 347 |
| 401. | Рәшит | 347 |
| 402. | Исмәгыйль | 348 |
| 403. | Габделбәр | 348 |
| 404. | Габдерәүф | 348 |
| 405. | Мөхәммәт | 348 |
| 406. | Фатыйма | 350 |
| 407. | Сабирҗан | 352 |
| 408. | Шакирҗан | 352 |
| 409. | Харис | 353 |
| 410. | Хәбип | 353 |
| 411. | Касыйм | 353 |
| 412. | Яхъя | 354 |
| 413. | Исмәгыйль | 357 |
| 414. | Габдулла | 357 |
| 415. | Шамил | 363 |
| 416. | Камил, 1941 нче елда сугышта вафат | 363 |
| 417. | ? | 364 |
| 418. | ? | 364 |
| 419. | ? | 369 |
| 420. | ? | 369 |
| 421. | Хәдичә | 371 |
| | *XI буын* | |
| 422. | Наил | 380 |
| 423. | Гамбәр | 387 |
| 424. | Әлфия | 408 |
| 425. | Альфрит | 408 |
| 426. | Фаил | 408 |
| 427. | Наил | 408 |
| 428. | Ирек | 409 |
| 429. | Әлфия | 409 |
| 430. | Камил | 412 |
| 431. | Фаил | 412 |
| | *XII буын* | |
| 432. | Ләйлә | 422 |
| | *XIII буын* | |
| 433. | Фәридә | 432 |
| | *XIV буын* | |
| 434. | Тимур | 433 |

### *Искәрмә*

Ишман нәселе шәҗәрәсенең асылын аңлау өчен аның шактый катлаулы легендасын анализлау мөһим. Шушы максат белән Ш. Мәрҗани хезмәтендә китерелгән Ишман тарихына кагылышлы мәгълүматларны искә алып узабыз. Мәчкәрә авылы элек Ишман Иле атамасы белән мәгълүм була. Ишман Иленә XVII йөзнең икенче яртысында Бөрбашы авылыннан Ишман бине Туктаргали бине Көчек бине Табаҗ исемле зат үзенең кардәшләре белән күчеп килеп, утар ясап торганнар.

Ишман, Бөрбашындагы Ишемкә дигән бер зат белән араларында ызгыш чыгып, Мәчкәрәгә килеп утыра. Хәтта Бөрбашындагы

агач мәчетне дә сүтеп, Мәчкәрәгә күчереп сала. Мәчкәрәгә башка авыллардан күчеп килүчеләр дә күп була. Бу нәселдән Туктаргали бине Көчек сәүдәгәр булып танылган, ул Бөрбашында яшәп үлгән. Бөрбашы авылын урыслар Көчек авылы дип атаганнар.

Бөрбашында Туктаргалинең Мәмәт дигән бер улы кала. Аның нәселе – Байморад бине Ишморад бине Ишман бине Корбанай бине Бигәш бине Мәмәт бине Туктаргали. Туктаргалинең ике улы Ишман вә Ишкәй Мәчкәрәдә яшәгәннәр, нәселләре анда калган.

Ш. Мәрҗанинең «Мөстафадел-әхбар фи әхвале Казан вә Болгар» хезмәтендә әлеге нәсел хакында мондый мәгълүматлар китерелә: «Гали-кол Ишмәннән – Гайед вә Габдессәлам вә Габделмәннан вә Сәгыйд вә Бәшир вә Нәзир вә Өтәмеш исмендә йиде углы улды. Вә Гали-кол Ишмәндин Гайед вә Үтәмеш – ике углы калып, Үтәмештән Габдессәлам вә андин Мөхәммәдрәхим вә Габдулла туганнар. Аларның нәселләре шәҗәрәсе бу заманда Габдулла бине Габдессәлам бине Хәлил бине Йосыф бине Ишман бине Туктаргали бине Көчек бине Табаҗ бине Кодаш бине Сөләйман әл-Кирмани рәвешендә мәгълүм». Әлеге шәҗәрәнең XIX гасырдан бирле күчерелә килгән унлап тексты бар.

Алар нигездә нәселнең килеп чыгу мәсьәләсендә ике версияне сөйлиләр.

Беренче версия буенча Хан Кирмән шәһәрен көчләп чукындырганда, бер солдат ташландык өйдән бишектә яткан ир бала табып чыга һәм аны үзенеке итеп үстерә. Үсеп җиткәч, егет булгач, аңа Алабуга ягыннан бер мишәр кызы алып биреп, аларга Ядгәр Иле дигән авылда йорт салып, башка чыгара. Бу версиядә нәселнең Касыйм шәһәреннән чыгуы һәм аны мишәр кызына өйләндерү – игътибарга лаек хәбәрләр. Нәселдәге иң ерак бабаның Сөләйман Кирмани дип йөртелеп, алдагы мәгълүматлар белән ярашуы да кызыклы.

Икенче версия нигезендә, нәсел Шәһре Болгардан килгән, дигән риваять ята. Әлбәттә, бу беренче версиягә каршы килми, аны куәтли генә, чөнки Хан Кирмәннән килүчеләр өчен бу яклар, Болгар вилаяте буларак, нык танылган була.

Гомумән алганда, Мәчкәрәгә нигез салучыларның Хан Кирмәннән чыккан татарлар булуын шәҗәрәнең ике варианты да раслый. Аларның бу якларга күчү вакыты XVII гасырның урталарына туры килә.

Нәселнең Сөембикә улы Үтәмеш Гәрәйгә катнашы булуын кискен инкяр итеп булмый. Үтәмеш Гәрәйнең урыс күзәтүчеләреннән читтә баласы тууы бик мөмкин, чөнки Казан шаһзадәсенең яшьли үлүе, аның чит дингә ихтирамы булмаганлыктан, ашыктырылганга охшый. Һәрхәлдә Казан ханнарының урыс әсирлегендә дөньядан вакытсыз китү тарихлары шундый фикергә этәрә.

Шундый ук хәл Казан байлары Юнысовларның да башыннан кичкән тарих. Йосыф мирза улы Юныстан чыгуларын бу нәсел бик озак сер итеп саклап, бүген генә мәгълүмат тарала башлады.

Мәчкәрәдән чыккан Үтәмешевләр, Мәскәүдә бөтен дөньяга мәгълүм академиклар дәрәҗәсенә ирешеп, үзләренең Казан һәм Нугай Урдасы токымнары белән бәйле нәсел шәҗәрәләрен өйрәнә башладылар.

Тагын бер факт кызыклы. Мәчкәрә мәдрәсәсенең атаклы мөдәррисе Габдулла бине Яхъя әл-Мәчкәрәви әл-Чиртуши (1775–1859) – тумышы белән Чистай ягындагы Чиртуш авылы кешесе. Аның шәҗәрәсендәге дүртенче бабасы да Сөләйман исемле була, һәм бу нәселнең Чистай якларына Хан-Кирмәннән күчеп килгәнлеген раслаган документлар бар.

Гомумән алганда, Касыйм татарлары Касыймда чукындыру сәясәте көчәйгәч, Урта Идел һәм Оренбург якларына күпләп күчеп утырганнар.

### Төбәкнең иң борынгы ташбилгесе

Кукмара төбәгендә борынгы кулъязма китаплар белән беррәттән тарихи ташбилгеләр дә сакланып калган. Бу бер дә гаҗәп түгел, чөнки аның җирләрендә инде XIII–XIV гасырлардагы кала эзләрен археолог галим Альберт Борһанов моннан берничә ел элек ачкан иде[1]. Кукмара төбәге авылларында Сарай һәм Болгарда идарә иткән Габдулла хан (Кара бәк) кебек бөек кешеләрнең нәсел варислары әлегәчә яшәвен дәвам итә. Шушы хан нәселеннән булган бөек татар композиторы Рөстәм Яхин үзе генә дә ни тора!

Кабер өсләренә язулы ташбилгеләр кую традициясе Алтын Урда дәверендә яңарып китә. Кукмара төбәгендә Алтын Урда чорының ташбилге үрнәкләре безнең көннәргә кадәр сакланмаса да, алар,

[1] Бурханов А.А. Городская цивилизация Золотой Орды: программа спецкурса. Казань: Gumanitaria, 2005. С. 40; Бурханов Альберт. Золотоордынские памятники Поволжья. Стамбул – Казань, 2005. С. 40.

әлбәттә, булганнар. Тәре йөртүчеләрнең XIV гасырның икенче яртысыннан яңа көч белән кабынып киткән талау-җимерү һөҗүмнәре безнең милли-мәдәни һәйкәлләребезнең күпләп юкка чыгуына, җимерелүенә сәбәп булган.

Шулай да Кукмара төбәгендә XVII гасырның соңгы чирегендә куелган гүзәл эчтәлекле һәм бизәкле бер ташбилге Өлге авылы кырында ниндидер могҗиза белән генә сакланып калган. Ул ташның текстын без 1984–1985 елларда укып чыктык. Аның татарча өлеше түбәндәгечә яңгырый.



... тарих миңдә туксан икидә дирләр ирди, Җамбакты углы Туйкә бай – Казан шәхәрендин, үзи вакытында бу билгини куйдый, ирәнләрдин дога өмид өчүн.

Күрәрмен дөньйаны вәйран барый, бакый ирмәс һәмишә йук карары!

Йазды Кил-Мөхәммәд Ишман углы. (Һижри 1092 ел, милади ысул белән 1681 елга туры килә).

Ташны атаклы оста Кил-Мөхәммәд бине Ишман иҗат иткән. Ул үзе дә хәзерге Кукмара төбәгенә керә торган Мәчкәрә авылы кешесе булган, дип уйларга нигез бар. Гүр иясенең Казанда белем алуы да шәһәрнең ул вакытларда ук татар-мөселманнар өчен рухи мәркәз булуын күрсәтә. Мәрхүм Туйкәне Казанда яшәгән Мелла Мамай (?–1677) мәдрәсәсендә укыган шәкерт, дип саный алабыз. Чөнки Казанда ул дәверләрдә берничә мәдрәсә эшләве шикле. XVII гасыр урталарында калада фәкать мелла Мамай мәдрәсәсе булуы гына мәгълүм.

Димәк, Өлге җирендә Казанның укымышлысы тәрбияләгән зат хатирәсе сакланган.

# КУЛЪЯЗМАЛАР ЯНМЫЙ

*Айдар Гайнетдинов*

Институтыбызның Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә Кукмара районына караган күп кенә фольклор әсәрләре, язмалар, музыкаль, археографик материаллар саклана. Алар нигездә төрле елларда оештырылган фәнни  экспедицияләр вакытында җирле халыктан җыелган.

Кукмара районына Институтның иң беренче фольклор экспедициясе 1951 елның июнь – июль айларында оештырыла. Аны атаклы галим Хәмит Ярми җитәкли. Экспедициядә Институт хезмәткәрләреннән Халидә Гатина, Эдуард Касыймов, Наил Гыйззәтуллин, Салих Гарипов, Сания Шәмсетдинова, Мәрва Богдановалар катнаша. Алар, коеп яуган яңгырларга, кыздырып торган кояшка карамыйча, ике ай буе фольклор материалларын җыеп йөриләр. Шуннан ук Балтач ягына юнәләләр.

1984 елда фольклорчылар кабат бу төбәккә халык авыз иҗаты әсәрләре җыярга чыгалар.

Археографик материал җыю буенча беренче экспедиция бу районга Институт хезмәткәре, әдәбият галиме Рафис Әхмәтов тарафыннан 1977 елда оештырыла. Ул Югары Өскебаш авылында булып, шактый гына борынгы кулъязма һәм басма китаплар җыеп кайта.

1978 елның июль аенда әдәбият галиме Әнвәр Шәрипов Кукмара районының Күкшел, Мәчкәрә авылларына бара һәм күп кенә археографик материал таба.

Шул ук елны Рафис Әхмәтов кабат Кукмара районына юл тота. Бу юлы ул Битләнгер авылында була һәм, әлбәттә, буш кул белән кайтмый.

Шул ук елда Г. Гыйниятуллин Түбән Өскебаш авылына бара. Ул да берникадәр борынгы кулъязма һәм басма китаплар табу бәхетенә ирешә.

Институтта эшләүче күренекле әдәбият галиме, археограф Марсель Әхмәтҗанов та 1984 елны Кукмараның үзендә, районндагы Өлге, Пычак авылларында булып, күп кенә борынгы кулъязмалар һәм сирәк китаплар таба, борынгы кабер ташларын өйрәнеп кайта. Ә 1985 елда ул Бучирә (Березняк), Камышлы, Киндеркүл, Адай авылларына барып чыга.

1970 нче еллардан башлап бүгенге көнгә кадәр тел белеме галимнәре, һәр биш ел саен диярлек, Кукмараның бик күп авылларына экспедициягә чыгып, диалектология буенча материал туплап торалар.

Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә төрле кешеләр тарафыннан җибәрелгән фольклор материаллары да саклана. Галимнәр, газеталар, радио аша халыкка мөрәҗәгать итеп, үзләре белгән, үзләрендә сакланган халык авыз иҗаты үрнәкләрен, борынгы кулъязмаларны һәм китапларны Институтка җибәрүләрен үтенәләр. Шул сәбәпле илнең төрле почмакларыннан (нигездә хат белән) күп кенә материаллар килә. Алар арасында Кукмара районының Байлангар, Мәмәшир, Мәчкәрә, Сәрдекбаш, Югары Өскебаш, Түбән Өскебаш, Төркәш, Шепшеңәр һ.б. авыллардан җибәрелгәннәре бар.

1951 елдан соң Кукмара районында халык авыз иҗаты үрнәкләре җыю һәм 1985 елдан бирле археографик материал туплау тукталып калган иде. Анда бару инде өстебездә фарыз гамәл кебек тора иде. Шуңа күрә Кукмара районына экспедициягә бик теләп кузгалдык. Район администрациясендә булып, анда эшләүче хезмәткәрләр белән таныштык, аларның фикерләрен, тәкъдимнәрен тыңладык. Район администрациясе безне Зур Сәрдек авылындагы гимназия бинасына урнаштырды, анда яшәр өчен бөтен уңайлыклар тудырылды.

Шуны да әйтергә кирәк: безнең фәнни экспедициябез комплекслы булды. Анда фольклор, археография, тел, сәнгатькә караган материалларны җыючылар да бар иде. Археографик материалны җыю исә миңа йөкләнде.

Вакытны әрәм итмичә, шул ук көнне өч авылда – Купка, Адай, Чишмәбаш авылларында булдык. Авылда яшәүчеләр безгә 19 басма китап, 7 кулъязма китап, 7 кулъязма дәфтәр тапшырдылар. Купка

авылында гарәп телендә язылган зур күләмле өч кулъязма табылды. Шуларның берсе, 1850 елга караганы, эчтәлеге буенча Табаранының хәдисләр китабы булырга тиеш. Калган икесе дә шул чорга туры килә торган әсәрләр.

Адай авылында исә төрле мәсьәләләр хакында хәдисләр китабы табылды. Кәгазе буенча ул XIX гасырга карый.

Чишмәбаш авылында табылган кулъязма Коръән кыйммәтле табышлардан булды. Палеографик билгеләре буенча ул XVIII гасырга карый.

Бу авылда фольклор әсәрләре дә табылды. Мәсәлән, «Мәүлед эн-нәби» касыйдәсе һәм мөнәҗәтләр язылган ике дәфтәр. Дәфтәрдә «аны Яңа Сәрдек авылында яшәүче Шакир хатыны Гарифә 1976 елда күчереп язган» диелгән. Әлбәттә, алар гарәп графикасында язылганнар. Мөнәҗәтләр арасында «Мәрхәбә», «Шәһре рамазан» кебек заманында киң танылган әсәрләр бар. Түбәндә исеме күрсәтелмәгән бер әсәрдән өзек китерелә:

Укыйк әле, укыйк әле, әйдә җиде әбҗәдне,
Укысаң җиде әбҗәдне, Аллаһ бирер сигез җәннәтне.
Укыйк әле, укыйк әле, телләребез талганчы,
Бер Ходага итик зикер, сигез җәннәтне алганчы.
Итик зикер, итик шөкер бер Ходаның үзенә,
Сигез җәннәт бирсен иде барча мөэмин колына.
Укыйм-язам, укыйм-язам укыган китапларны,
Гүргә барып кергәчтеннән җиңел кыл хисапларны.

Күргәнебезчә, бу мөнәҗәтләрдә җирле халыкның сөйләм үзенчәлекләре дә чагыла. Гомумән, Кукмара төбәгендә язма рәвештә сакланган фольклор әсәрләре күп җыелды. Алар арасында әле бөтенләй өйрәнелмәгән һәм басылмаган әсәрләр шактый. Киләчәктә алар халык авыз иҗаты әсәрләре буенча төзелүче томнарга да кертелер, дигән өмет бар. Хәзерге өлкәннәр күңелендә сакланган татар фольклор әсәрләрен җыю кыенлашканнан-кыенлаша бара. Чөнки аларны хәтерләрендә саклаучы өлкән буын вәкилләре елдан-ел азая. Шуңа күрә хәзер аларны язма чыганаклардан гына эзләргә кала.

Уразай авылында бер кызыклы хат табылды. Ул 1913 елның 12 октябрендә Мифтахетдин Салихов тарафыннан кызы Тәзкирәгә һәм кияве мулла Госманга атап язылган. Аннан аңлашылганча, ул

үзе дә, аның кияве дә, кодасы да (киявенең атасы) муллалар булган. Хат бик пөхтә, матур итеп язылган. Шуны да әйтергә кирәк: безгә бу хатны тапшыручы Р. Харрасов үзе дә авыл мулласы. Димәк, әгәр телгә алынган кешеләр аның бабалары икән, бу эш аңа нәселдән үк килә торган булып чыга.

Уразай авылында шулай ук ике кульязма Коръән табылды. Аларның берсен 1911 елның 26 мартында мулла Җәлал бине Мөхәммәди әл-Борбашый күчереп язган. Исеменнән күренгәнчә, ул үзе Балтач районының Борбаш авылыныкы булган. Икенче Коръәннең язылу еллары, күчерүчесе язылмаган.

Бу авылда бер дастан фрагменты да табылды. Ул ярты биттән генә гыйбарәт. Шулай булса да, тексты борынгы булу сәбәпле, әһәмияткә ия.

Уразай авылында мөнәҗәтләр укырга яратканнарын табылган дәфтәрләрдән яхшы аңлап була. Алар арасында Мөхәммәд пәйгамбәр, миграҗ вакыйгасы, җомга көн, дога, «Аятелкөрси» турындагылары бар. Шулай ук дәфтәрдә борынгы текст белән язылган «Зәкиябану абыстай бәете» дә бар. Җитмеш яшьлек Зәкиябану абыстай, ниндидер сәбәпләр аркасында, үз туган җиреннән китәргә мәҗбүр була. Бу хәлгә ул бик кайгыра, борчыла һәм үзенең эчке кичерешләрен шигъри юлларга сала:

Туган илдән китү миңа
Каберләргә кергән кебек.
«Зияратка, – газиз балам, –
Китәм, әни», – дигән кебек.

Укыткан кызларым кала,
Алар миңа, гүя, бала,
Алардан аерылу берлән
Сабыр бирсен үзе Алла.

Туган илдә күршеләрем
Гүя, миңа анам кебек,
Алардан аерылу миңа
Анамдан аерылган кебек.

Сәрдекбаш авылында яшәүче берәүнең бер тартма борынгы кульязмасы булган, ул аларны, кая куярга белмәгәч, зиратка илтеп күмгән, никадәр хәзинә юкка чыккан. Аларны мәчетләргә тапшы-

рырга кирәк иде, чөнки, экспедицияләрдә йөргәндә, борынгы кулъязмаларны, иске китапларны эзләп мәчетләргә кермичә калмыйбыз. Муллалар гадәттә, безгә якты йөз күрсәтеп, аларны мирасханәбезгә бүләк итеп җибәрәләр.

6 июньдә Манзарас авылында булырга туры килде. Авылның элеккеге имамы М. Фәтхуллин безгә бер зур капчык борынгы кулъязмалар тапшырды. Анда барлыгы 74 берәмлек борынгы кулъязмалар һәм китаплар булуы ачыкланды. Алар арасында бик күп мөнәҗәтләр, бәетләр, риваятьләр, догалар, хотбәләр, хатлар, бөтиләр бар. Җыелган материал арасында кулъязма Коръән һәм Коръән тәфсире дә бар, ләкин тулы түгел. Палеографик һәм су билгеләре буенча алар XIX гасырга карый.

Арада гарәп графикасында гына түгел, латин графикасында язылган кулъязмалар да бар. Мәсәлән, 1930 елда Кукмараның үзендә язылган бер шигырь сакланган. Аның имзасы булса да, авторын төгәл ачыклау мөмкин түгел.

Кәчимир авылында яшәүче мулла Габдулланың кызы Әминә күчереп язган «Килгән кунакларны хөрмәтләп» дигән мөнәҗәттә шундый юллар бар:

Сез килдегез инде безгә,
Хода рәхмәт итсен сезгә.
Хак Тәгалә хозурына
Барсак иде бергә-бергә.

Сез килдегез инде безгә,
Хода рәхмәт итсен сезгә.
Бакый иманыбыз берлә
Китсәк иде бергә-бергә.

Ә ике биттән торган васыятьнамә, XX гасыр урталарына караса да, гарәп графикасында язылган. Эчтәлеге дә шактый үзенчәлекле: аны язучы, үзе үлгәннән соң, балаларына нәрсәләр эшләргә кирәкләкләрен, аларга нәсыйхәтләрен язган.

«Рамазан» бәетендә, текстыннан аңлашылганча, утыз бер яшьлек Рамазан исемле ир кешенең фаҗигале рәвештә (янып) вафат булуы бәян ителә. Шулай ук 1930 нчы елларда муллаларны репрессияләү заманында язылган бер бәет тә табылды. Ул Кукмара районының Мәчкәрә авылы мулласы турында булса кирәк:

Иртә торып тышка чыксам,
Хәбәр бирде бер карга,
Әйдә, мулла, ятрәк, диеп
Чакыралар ябарга.

Мине тотып алдылар да
Бер бүлмәгә яптылар,
Ябып кына куймадылар,
Йозаклап ук алдылар.

Күкшел тавын менгән чакта
Мин карадым каерылып,
Шәмсүриям Мәчкәрәдә
Кала инде аерылып.

Күзем нурым, сиңа әйтәм:
Намазыңны калдырма,
Агаларыңның сүзен тот,
Хәтерләрен сындырма!

Табылган материаллар арасында татар халык җырлары да шактый. Совет заманында бик күпләр, шул исәптән кукмаралылар да, бәхет эзләп Урта Азиягә чыгып китәләр. Матди яктан үзләрен бәхетлерәк санасалар да, рухи яктан алар туган җирләреннән аерылу сагышын авыр кичерәләр. Манзарас авылында табылган хатларның берсеннән алынган бу юллар шуны раслый:

Иртә торып тышка чыксам,
Чәйханәдә үзбәкләр.
Үзбәкстан илләрендә
Өзеләдер үзәкләр.

Бу авылда тарихи документлар да табылды. Аларның берсе – еллык имтихан шәһадәтнамәсе. Ул Янсыбы авылындагы башлангыч мәдрәсәнең 4 нче сыйныф шәкерте Галимҗан Борһан улына 1913 елның 10 апрелендә бирелгән булган. Барлык имтиханнарын уңышлы гына тапшырып, шәкерт 5 нче сыйныфка күчерелгән. Ул вакытта мәдрәсә җитәкчесе Ногман Исхаков, мөгаллимнәрнең берсе имам Фәйзулла Камалов булган.

Икенче документ исә совет заманына карый. Ул 1925 елның 25 ноябрендә Шәрәфиев Габбас Каюм улына бирелгән аттестат.

Бу кеше Омск шәһәрендә 81 нче полк мәктәбендә укып, эшче-крестьян Кызыл армиясенең кече лейтенанты дәрәҗәсен ала.

Моннан тыш тагын түбәндәге документлар табылды: 1931 елгы хисап кенәгәсе һәм колхозчының эш кенәгәләре, 1946 елгы медаль белән бирелгән таныклык, 1951 елгы пенсия таныклыгы, 1952 елда җиденче сыйныфны тәмамлау турындагы шәһадәтнамә. Алар, әлбәттә, әле якын тарихка карасалар да, безнең өчен әһәмияткә ия, чөнки еллар үткән саен мондый документларның да кыйммәте арта бара.

Басма хезмәтләр арасында берничә генә булса да гарәп телендә язылган һәм XIX гасырда Мисырда нәшер ителгән китаплар да бар.

Кәркәвеч авылында XX йөз башында яшәгән бер шәкертнең кызыклы гына дәфтәре табылды. Аны укып, без мәдрәсәдә ни рәвешле белем алганнарын, буш вакытларында шәкертләрнең нәрсә белән шөгыльләнгәннәрен белә алабыз. Шулай ук 1855 елгы бер мәҗмуга да табылды. Анда бик күп әсәрләр бирелгән: авырганда укыла торган догалар, хәдисләр, хикәяләр, мөнәҗәтләр һәм XIX гасыр шагыйре Һибәтулла Салиховның шигырьләре. Болардан тыш, намаз үзенчәлекләре турында язылган борынгы китап та кыйммәтле табышлардан булды. Шәмсекамәр Ярмөхәммәд кызының мөнәҗәтләр дәфтәре дә фольклор өчен әһәмияткә ия. Анда төрле дини багышлаулар да бик күп китерелә.

Салтык-Ерыклы авылында кульязма китапларга тап булдык: бер мәҗмуга, борынгы Коръән битләре, кульязма дәфтәрләр, хатлар, багышлаулар, мөнәҗәтләр, җырлар, шәмаил. Мәҗмугасы XIX гасырга карый, анда бик күп кызыклы материаллар китерелгән: «Гакыйдәи мәнзумә», Аллаһ һәм Мөхәммәд пәйгамбәр исемнәре, «Тәварихы Болгария», 41 ясин һәм истихара намазы хакында язмалар, шигырьләр, төрле тылсымнар, ырымнар һ.б. Ырымнардан бер өзек: «Йите диңгез артында күшек бар, аның эчендә бер кыз бар. Көмеш сачы алтын. Качан ки аны йитеп бозса, бу фәлән кеше анда бозсын. Яман хаста кире кайт, кит! Йите диңгез артында бер кара козгын бар, борыны көмеш, тырнагы алтын. Аны кеше бозса, бу фәләнне анда бозсын. Яман хаста кире кайт, кит! Йите диңгез артында кара башлы елан бар. Бер муезы алтын, бер муезы көмеш. Ул еланны качан кеше йитеп бозса, бу фәлән кеше анда бозсын. Яман хаста кире кайт, кит! Ак атлы булат кылычлы, ак ук садаклы ак күн кисә, яман хаста кире кайт, кит!..»

Кулъязма китаплардан тыш, әле фотога алу юлы белән ясалган китаплар да табылды. Алар инде бик үк борынгы түгел. Ләкин бу күренеш татар халкының төрле юллар белән үзләренең китапларын саклап калырга тырышулары хакында сөйли.

Кукмара районында татарлар гына түгел, удмуртлар да күп яши. Халык исәбе буенча алар татарлардан кала икенче урында тора. Шуңа күрә, удмурт авыллары белән дә танышыр өчен, Важашур, Оштырма-Юмья авылларына юнәлдек. Кызганыч, ул якларда археографик һәм эпиграфик материал бөтенләй табылмады. Бу инде аңлашыла да, удмуртларда язу совет заманнарына кадәр нык үсеш алмаган. Шулай булса да, аларның халык авыз иҗаты, гореф-гадәтләре, диннәре (мәҗүсилек тә бар) белән танышу кызыклы һәм файдалы булды.

Шулай ук керәшен татарлары яшәгән Үрәсбаш авылында да булдык. Монда да археографик һәм эпиграфик материал табылмады. Алар инде, христиан динендә булганлыктан, традицион татар әдәби культурасыннан аерылганнар һәм мөселман татарлары кебек язуны актив кулланмаганнар. Фәкать мөселманнар менталитетында гына гарәп графикасында язылган һәр язма ниндидер изге нәрсә булып саналган һәм санала да. Шул сәбәпле аларны халык ташларга уңайсызланган, курыккан, чормаларга, сандык төпләренә, шкаф өсләренә куеп сакларга тырышкан.

Төркәш авылында күбрәк басма китаплар җыелды: «Әл-лөбаб тәрҗемәсе» (1917), «Фәттахетдин кыйссасы» (1917), «Ваба вә андан сакланмак өчен истигъмаль кыйлына торган әсбаб вә чаралар» (1893). Бу авылда гектография ысулы белән язылган 1907 елгы бер ташбасма китап та табылды. Кулъязмалардан фәкать бер Коръән бите һәм мөнәҗәтләр, багышлаулар язылган дәфтәр табылды. Бу дәфтәрдә Коръән турында язылган мөнәҗәттә шундый юллар бар:

Йаным пакьлаем дисәң,
Йөзеңне аклаем дисәң,
Үзеңне саклаем дисәң,
Кичен-көндез укы Коръән!

Нырты авылында, аңа 1930 елда гына нигез салынганлыктан, археографик материал табылмады.

Ләкин бу авылдан ерак түгел генә урнашкан Шепшеңәр авылында бик күп бай археографик материалга юлыктык. Аларны безгә

авыл имамы К. Газизов тапшырды. Үзе муллалар нәселеннән булганлыктан, борынгы кулъязма һәм басма китаплар аңа әби-бабаларыннан изге мирас буларак күчкән, һәм ул аларны бик кадерләп саклаган. Материаллар арасында палеографик билгеләре буенча XVII гасыр ахырына карый торган борынгы кулъязма китап (җыентык рәвешендә) бар. Анда әлегә хәтле билгеле булмаган Кол Нуран Муса улының «Кыйссаи Гуккяша»поэмасы барлыгы ачыкланды. Аның эчтәлегенә килгәндә, бу әсәрдә Мөхәммәд пәйгамбәрнең үз вафаты алдыннан Гуккяша исемле сәхабә белән булган бер вакыйгасы сурәтләнә. Шулай ук билгесез Сөләйман исемле шагыйрьнең Мөхәммәд пәйгамбәргә багышланган зур күләмле поэмасы табылды. Китапта булган бу әсәрләрнең барысы да бик борынгы тел белән язылган, хәрефләрнең язылышы да борынгыча. Кызганыч, авторларының кайда туулары, тормыш юллары хакында бернәрсә дә билгеле түгел. Исемнәре, аталарының исемнәре, фәкать әсәрләрендә телгә алынган булу сәбәпле генә, ачыкланды. Болардан тыш, җыентыкта авторы билгесез булган бер шигырь, изгеләр исемлеге, кайбер догалар һәм аларның фазыйләтләре, фарсы телендә дини эчтәлекле язмалар китерелә. Ягъни Кукмара районында табылган материалларның иң борынгысы – шушы китап булды. «Кыйссаи Гуккяша» шигыреннән бер өзек:

Әйдәем Гуккяша-рәсүл кыйссасын,
Ишетеб чыкаруң күңел госсасын,
Кәлләнең сиз тоталым рәсүл сөннәтен,
Тиләдим бу ислам, иман гыйззәтен.

Була кем шәфәгать кыйлгай хак рәсүл,
Каулар хәзрәтендин гасый өммәтин.
Бу кабих бәйет алган аты Кол Нуран,
Тиләгем әйзү андин ахыр вакыт даимән.

Укуган газизләр онутмасыңыз,
Кыйамәт көнендә буласыз әман.
Атам Муса әйзәрмен сәлам,
Дога кыйлыб йад төне-көне мәдам.

Шепшеңәр авылында төрле ырым догалары шактый табылды. Алар гадәттә төрле тормыш ситуацияләрендә кулланылганнар. Мәсәлән, күз, колак яисә башка әгъзалар авыртса, бала еласа, эт

тешләсә һ.б. очракларның һәркайсының үзенә хас догасы бар икән. Аларның бөтенесе дә укылмаган, кайберләрен кесәгә салып йөрткәннәр, суга агызганнар һ.б. Кайбер догалар бөтенләй ислам чыганакларыннан алынмаган, димәк, халык аларны үзләре иҗат иткән булып чыга. Аларны халык авыз иҗатының бер төре итеп карарга кирәк. Болар рәтенә «Бәхет дәүләт» догасын кертергә мөмкин. Әлеге авылда табылган бу догадан өзек: «Әссәламе галәйкем, йә, бәхет дәүләт. Әйү вә хуш кил, кил, йә, бәхет дәүләт. Кулдашлык илә кил, кил, йә, бәхет дәүләт. Ай тик ага кил, кил, йә, бәхет дәүләт. Көн вә кояш тик туга кил, кил, йә, бәхет дәүләт. Ягмур тик йага кил, кил, йә, бәхет дәүләт. Кар тик йага кил, кил, йә, бәхет дәүләт...» Болардан тыш, Мөхәммәд пәйгамбәр мөһеренең сурәте ясалган кәгазь бите дә табылды. Аны ничек кулланырга кирәк икәне дә шунда ук язылган: «Буны иртәңге намаз артындан чын ихлас күңелегезне салуб карасагыз, һич бәла-каза күрмәссез, ахырда бик зур әҗер алурсыз». Болар белән бергә әле тагын билгеле булмаган төрле шигырьләр, җырлар да табылды.

Сәрдәвеч авылында нигездә керәшен татарлары яши икән. Шулай булуга карамастан, анда да ике кульязма бит таптык. Беренчесендә – догалар язылган, икенчесе исә – борынгы документ, төгәлрәк әйткәндә, метрика дәфтәренең бер бите. Анда Сәрдәвеч авылында 1915 елда теркәлгән никах турында язылган. Никахны Шаммаз мулла укыган.

Ядегәр авылының имамы безгә мәчет чормасында яткан кульязма һәм басма китаплар тутырылган бер капчык тапшырды. Анда бер басма Коръән һәм өч кульязма китап барлыгы ачык-ланды. Кульязма китапларның икесе гарәп теле грамматикасына карый. Өченчесе исә – Насретдин Әбел-Касыйм бине Йосыф Әл-Хөсәйнинең мөселман хокукы мәсьәләләрен яктырткан «Китаб әл-мөлтәкат» әсәре. Елы язылмаса да, ул, су билгеләре буенча, XIX гасыр башына карый. Бу китап заманында Таҗетдин бине Ярмөхәммәднеке булган.

Ядегәрдә яшәүчеләрнең күбесенең кушаматлары булуына игътибар иттек. Бу, бер яктан, бик кызык күренеш булса да, икенче яктан, фән өчен зур әһәмияткә ия. Чөнки ул халыкның яшәү рәвеше, гадәтләре, телнең үзенчәлеге, лексикасы һ.б. хакында мәгълүмат бирә. Авылда борынгы кушаматларның мисаллары: Песи, Күсе, Бүти, Бәрәңге, Әбәдә һ.б.

Кенәбаш авылында да берничә кулъязма дәфтәр таптык. Аларда вәгазьләр, догалар, бәетләр, мөнәҗәтләр язылган. Бәетләрдән ялгыз ана, атасы сатып җибәргән кыз хакында язылганнары аеруча кызыксыну уятты.

Шулай ук бу авылда бәетләр, мөнәҗәтләр, шигырьләр иҗат итүче Әхмәди Җәмалетдин улының кулъязмалары табылды. Ул әсәрләрен 1916 елда Австриядә әсирлектә булган чакта язып калдырган, үзе исә Кукмара районының Киндеркүл авылыннан булган. Табылган дәфтәрдә Әхмәди Җәмалетдин улының өч бәете, бер мөнәҗәте һәм бер шигыре язылган. Әсәрләре оста итеп, рифмалары туры китерелеп язылган. Бәетләрендә үзенең сугыштагы хәлләрен, авырлыкларын, якыннарыннан аерылуның газапларын сурәтли. Мөнәҗәтендә традицион дини мотивлар урын алган, шигырендә исә туган җирләреннән аерылу сәбәпле барлыкка килгән хәсрәте, эчке кичерешләре турында бәян ителә. Бу табыш Кукмара районын XX гасыр башында иҗат иткән бер әдипкә баетты, дип әйтергә мөмкин. Хәзер аның әсәрләрен фәнни әйләнешкә кертергә генә кала. Әхмәди Җәмалетдин улының әсәрләреннән өзекләрне укып китик:

Тәкбир әйтеп каршы алдык
Быел Корбан гаетен.
Без язабыз, сез тыңлагыз
Бу сугышның бәетен.

Австриянең җирләрендә
Рельсалары тар икән,
Австриянең кулларында
Ризыклары бар икән.

Кояш баеп, көн кич булса,
Шинель ябынып ятабыз.
Австрияләр каршы килсә,
Көне-төне атабыз.

Мөнәҗәт әйләдем даим,
Хода кыйлсын бәңа ярдәм.
Китабындадыр дәрман,
Рәхим кыйл, йә, рәхим Алла!

Әгәр син кыйлмасаң ярдәм,
Хатадыр кыйлганым һәр дәм.
Гафу әйлә, безне, мәүләм,
Рәхим кыйл, йә, рәхим Алла!

Шулай итеп, экспедициябез вакытында тупланган археографик материаллар арасында сирәк китаплар, борынгы кулъязмалар шактый булды. Хәтта әлегә кадәр билгеле булмаган әсәрләр дә табылды, кайбер борынгы әдипләрнең исемнәре ачыкланды. Шуңа күрә бу экспедицияне, бик уңышлы булды, дип саный алабыз.

# ИГЕЛЕК ЧИШМӘЛӘРЕ

*Фирдәвес Гарипова*

Авыллар – милләтебезнең терәге, мәшһүр шәхесләр тәрбияләп үстергән рухи нигезебез.

Кукмара районыннан да гаҗәеп дәрәҗәдә тырыш, уңган, зирәк фикерле, зыялы, фидакарь затлар чыккан. Бу төбәктә 5 Советлар Союзы герое, 7 Социалистик Хезмәт Герое, 34 спорт мастеры тәрбияләнгән. Бу – зур байлык, районның визит карточкасы. Уңган, тәрбияле, умыртка сөяге нык булган халык арасыннан гына шундый батырлар һәм тырыш эшлеклеләр чыга. Хуҗалык итүнең бер генә тармагында да алар сынатмыйлар. Матур һәм күңелле итеп яшиләр, нәтиҗәле эшлиләр.

Кукмаралылар үз төбәкләренең тарихын, рухи тормышын һ.б. үзенчәлекләрен дә күз карасы кебек кадерләп саклыйлар.

**Кукмара**

Шәһәр тибындагы Кукмара бистәсе – районның үзәге, Казаннан 120 чакрым ераклыкта урнашкан.

«Татарстан Республикасының административ-территориаль бүленеше» (2005 елның 1 апреленә) белешмәсендә күрсәтелгәнчә, Кукмара районы 1965 елның 12 гыйнварында оештырылган. Территориясе – 1492,1 км$^2$. Халкының саны – 52,8 мең кеше. Административ берәмлекләр саны: җирле үзидарә советлары – 29; шәһәр тибындагы бистә – 1, авыл торак пунктлары – 123 (берсендә инде кеше яшәми).

Кукмара атамасы тарихи чыганакларда, белешмәләрдә шактый очрый.

Казан өязе теркәү кенәгәсендә (1602–1603 еллар), Д.А. Корсаков (1908) җыеп чыгарган белешмәлектә Кукмара искә алына. Кукмара

авылында 124 ясаклы һәм 7 йомышлы татар яшәгәнлеге билгеле. Икенче Кукмара авылында исә ясак түли торган 30 татар көн иткән. Иноземцев фамилияле сәүдәгәрнең бакыр эретү заводында 440 эшче эшләгән. А. Артемьев нәширлегендә басылып чыккан һәм 1859 елгы мәгълүматлар тупланган белешмәдә дә Кукмара атамасы очрый. Норма суы ярына утырган Кукмарада 125 хуҗалык булган. Аларда 432 ир-ат һәм 425 хатын-кыз көн иткән. Чиркәү эшләгән, ял көннәрендә базар җыелган. Икенче Кукмара (Таишево) авылы Уштарма суы ярына урнашкан. Андагы 35 хуҗалыкта 100 ир-ат һәм 99 хатын-кыз гомер кичергән. Норма суы ярына нигезләнгән Олы Кукмара авылындагы 99 хуҗалыкта 370 ир-ат һәм 411 хатын-кыз гомер иткән, 2 мәчет эшләгән. 1898 елда басылып чыккан белешмәлектә күрсәтелгәнчә, Кукмарада руслар, ә Икенче Кукмарада (Таишевода) татарлар яшәгән. К.П. Берстель бастырып чыгарган тарихи белешмәлектә (1908) Кукмарада 831 рус кешесе, Икенче Кукмарада 278 татар кешесе яшәгәнлеге искәртелә.

1928 елдан Кукмара шәһәр тибындагы бистә статусы ала һәм Кукмара районының үзәге исәпләнә. Ул Республиканың төньяк өлешендә, Киров өлкәсе белән чиктә урнашкан.

Кукмара атамасы каян килеп чыккан соң?

Аны кайберәүләр мари теле белән бәйли (районда марилар шактый яши). Бу вариант буенча, Кукмарага ике мари нигез салган. Маричадан тәрҗемә иткәндә кок – «ике» сүзен аңлата, ә *мара / мари* мари халкының үзатамасы: *кук ~ кок* + *мара ~ мари* – ике мари сүзен белдерә.

Икенче вариантны болай сөйлиләр. *Кук* сүзе борынгы фарсы телендә «тау» мәгънәсен аңлата. Чыннан да, Кукмара бистәсе аны төрле яктан уратып алган нарат урманлы таулар уртасына урнашкан. Кукмара буйлап зур булмаган Норма суы ага һәм бистәне икегә бүлә. Ул башлангычын Нормабаш авылы янындагы чишмәдән ала.

Таулардан элек ком чыгарганнар, шуңа күрә аның тирә-юне казылып беткән булган. Тау тирәсен яшелләндерүгә киез итек фабрикасы эшчеләре күп көч куйганнар. Яшелләндерү эшен, беренчеләрдән булып, Хәким Гали улы Хәйруллин башлый – 1 нче мәктәп янында бакча булдыра.

Кукмара 1600 елларда ук барлыкка килгән, ә 1640 елларда монда шактый бай бакыр ятмалары табыла. Бу исә бистәнең (ул чагында кечкенә генә бер авылның) үсешенә зур йогынты ясый.

Бистәдә вак һөнәрчелек бик нык үскән була. Бистәнең үзәгендә зур базар элек-электән эшләп килгән. 1914 елда ул үзәк базар исемен алган.

1910 елда киез итек фабрикасы хуҗалары заказы буенча беренче тимер юл салына башлый. 1960 елларда бистәдә ипи заводы, көнкүреш комбинаты, Казан язу машиналары заводының филиалы, азык комбинаты, май-сөт комбинаты, элеватор сафка баса. 1961–1967 елларда Норма елгасы аша күпер төзелә. 1967–1968 елларда Кукмараның урамнарына асфальт җәелә. 1970 елда, В.И. Ленинның 100 еллыгына багышлап, музыка-сәнгать мәктәбе, ресторан, кинотеатр төзелә. Соңгы елларда спорт мәктәбе, яшь туристлар станциясе, музей, компьютер үзәге, гостиница төзелгән.

Элек бистәнең Таеш өлешендә (микрорайонында) мәчет һәм ерактан ук күренә торган иң биек урында 2 чиркәү булган. 1930 елларда мәчет-чиркәүләр ябыла һәм җимерелә.

Соңгы елларда өлкәннәр тәкъдиме белән Кукмара бистәсенең төньяк чигендә яңа мәчет төзегәннәр. Төзелешкә барлык оешмалар да ярдәм иткән. Мәчеттә дини укулар да алып барыла, мәдрәсә дә эшли.

Кукмара шифаханәсе 1901 елда земство акчасына төзелә. Мәдәният сарае 1954 елда салына. «Хезмәт даны» исемендәге район газетасы 1930 елдан бирле чыгып килә.

Инкыйлабка кадәр Кукмарада Комаров һәм Родыгин фамилияле байларның киез итек фабрикасында китапханә дә була. 1919 елда бистәдә район китапханәсе, 1933 елда балалар китапханәсе ачыла. 1951 елда кичке эшче-яшьләр мәктәбе эшли башлый.

Кукмара районында 30 урта мәктәп бар. Шуларның икесе гимназия. Берсе – Кукмарада, икенчесе – Зур Сәрдек авылында. Тулы булмаган мәктәп берәү, ул – Туембаш авылында. Районда барлыгы 45 башлангыч мәктәп бар. Хакимият вәкилләренең һәм район мәгариф бүлеге җитәкчесенең тырышлыгы белән башлангыч мәктәпләр берсе дә ябылмый. Мәктәпләр, белем бирү белән бергә, мәдәният учагы хезмәтен дә үтиләр.

Кукмара районында Президентның «Бәләкәч» программасы әйбәт үтәлә. Районда элек 56 балалар бакчасы булса, хәзер алар 59 га җиткән.

Кукмараның халык телендә «могҗизалар кыры» дип йөртелгән өлешендә яңа йортлар төзелә. Бу йортлар, чыннан да, могҗизалы төстә калкып чыгалар. Кукмара хәзер елдан-ел зурая бара.

Инкыйлабка кадәр Кукмарада алты гына урам була, хәзер урамнар саны илледән артык: В. Ленин, К. Нәҗми, Г. Тукай, А. Пушкин, В. Азин, Чулпан, Нариманов, Һ. Такташ, Ш. Усманов, Г. Ильясов, Г. Ибраһимов, Казанцев, Ф. Яруллин урамы, А. Булатов, Грибоедов, Т. Гыйззәт, М. Худяков, Г. Титов, В. Маяковский, Ш. Мәрҗани, С. Сәйдәшев, Н. Идрисов, М. Җәлил, Н. Чернышевский, Ә. Җиһаншин, Яр буе, М. Вахитов, Спорт (Спортивная), В. Кельмаков, Май (Майская), Хәлфин, Көнчыгыш (Восточная), М. Гафури, Ю. Гагарин, Г. Гафиятуллин, Н. Баян, Г. Әхмәтов, Ш. Башкиров, Бакча (Садовая), Парк, Мичурин, 9 нчы Май, К. Тинчурин, Завод, М. Ломоносов, И. Гази, З. Басыйрова, М. Рахманкулова, Р. Шәрипов, К. Шакиров, К. Насыйри, И. Износков, М. Әмир, Ф. Әмирхан, Х. Әхмәтшин, Б. Таҗетдинов, Җ. Бикташи, Г. Сөләйманова, Р. Яхин, М. Әмир, М. Девятаев, Г. Камал, Лобачевский, Академик Королев һ.б.

Кукмара эшчеләр бистәсе урамнарының күбесе халкыбызның күренекле уллары һәм кызлары исемнәре белән аталган. Шулай ук бистәнең үзендә һәм район авылларында туып-үскән күренекле шәхесләрнең исемнәре барланып, аларны урам исемнәре рәвешендә мәңгеләштерү эше дә әйбәт куелган.

Кукмара халкы әби-баба ята торган зиратка да зур игътибар бирә. Зиратның тирә-юне тотып алынган, каберләр һәм ташлар каралган, төзекләндерелгән.

## Адай авылы

Адай авылы район үзәге Кукмара эшчеләр бистәсеннән 18 чакрымда, җирле үзидарә Советы үзәге Зур Сәрдек авылыннан 5 чакрым ераклыкта урнашкан.

1878 елның 26 ноябрь датасы белән бу авыл «Аграрный вопрос и крестьянское движение в Татарии XIX века» (М.-Л., 1936. с. 393–396) дигән хезмәттә искә алына. Анда яшәүче халык, имеш, үзләрен чукындыралар икән, дигән хәбәр ишетәләр һәм шактый зур чуалышлар оештыралар.

Бу урында Олыс би шәҗәрәсен китерү урынлы булыр. М. Әхмәтҗанов мәгълүматларына караганда, ул Кукмара районындагы Адай, Балыклы авыллары, Баулыдагы Бәйрәкә һәм Әлмәттәге Тайсуган авыллары белән бәйле. Шәҗәрә үзәгендә мондый исемнәр билгеләнгән (Мәрҗани варианты буенча): Ямәк би (чыгышы белән Болгардан) → Сәрдек → Байтәвәккәл → Барәш → Ямаш →

Сабыргуҗы → Тунлачы → Ниякә → Тәмәк → Ишмөхәммәт → Балтай → Габделкәрим → Исхак (1802 елда вафат) → Гали. «…Олыс би нәселенең хәзерге Кукмара районына карый торган Адай, Балыклы, Сәрдек авылларыннан Оренбург Каргалысына, Тайсуган, Бәйрәкә авылларына, Казанга XVII гасыр ахыры – XVIII гасырның беренче яртыларында таралганлыгы күренә. Олыс би шәҗәрәсе – борынгы ыру-кабилә шәҗәрәсе рудиментларын саклаган сирәк нәсел шәҗәрәләренең берсе. …Олыс би нәселе урта гасырларда Нократ кенәзлегенә буйсынган татарлардан булган. Аларның бу төбәккә килеп чыгышы XIV гасырның икенче яртысына карый».

Диалектолог Нәҗия апа Борһанова мәгълүматларына караганда, Адай авылы халкы июнь башында, күршедәге Купка, Аш Буҗи, Зур Сәрдек, Сәрдекбаш, Уразай, Кара Елга, Олыяз, Югары Казаклар, Түбән Казаклар авыллары белән бергәләшеп, Яссы Болын җыены үткәргән.

Авыл артык зур булмаган, салмак агышлы Бөре суы буена утырган. Авылны икегә бүлеп, челтерәп, йөгерек инеш ага. Инеш буе – таллыклар, алар авылга ямь өсти. Авыл моннан күп еллар элек инешнең югары агымында утырган булган, ә хәзерге урынында элек марилар яшәгән, дип сөйлиләр.

Авыл халкы тиз генә күбәеп китү аркасында, йорт салу өчен тигез урын җитмәгәнгә күрә, киңәшкәннәр дә, инеш буйлап бераз түбәнгәрәк күчеп утырырга булганнар. Яңа җиргә иң элек Адайхан исемле аксакал төшеп урнаша, аңа башкалар да иярә. Бу урында яшәгән марилар исә: «Киттек, киттек», – дип, Бөре елгасының түбән агымына, суның икенче ягына чыгып нигез салалар. Ул авылны хәзер Китәк дип атыйлар. Болар риваять кенә булсалар да, ихтимал, күпмедер дөреслек тә бардыр.

Тора-бара авыл шактый зурайган. Ул ике мәхәлләгә бүленгән, ике мәчет эшләгән. Мәхәлләләрнең берсе – суның бирге ягында, икенчесе – аргы ягында булган. Яманаты чыккан 1930 нчы елларда мәчетләрнең манаралары киселгән, кайсын мәктәп, кайсын хуҗалык биналары итеп үзгәрткәннәр.

Адай атамасының килеп чыгышын Гомәр ага Саттаров болай аңлата: «Кукмара һәм Актаныш районнарындагы Адай авыллары атамасының нигезендә Адай дигән борынгы төрки кеше исеме ята. Бу авылларга Адай исемле кеше нигез салган булырга тиеш».

Авыл уртасында Изгеләр чишмәсе челтерәп ага. Авыл халкы аны карый, чистартып тора. Авыл уртасында ук тагын янәшә урнашкан ике кое бар. Берсен – Сәхабетдин коесы, икенчесен Матур кое дип йөртәләр. Икенчесе бик матурлап һәм бизәкләп эшләнгән. Әчи чишмәсенең суын халык яратып эчә. Аннан түбәндәрәк Кортлы чишмә челтери. Ләкин аның суы бик чиста түгел, халык аннан суны мал-туар өчен ала. Ә иң зур һәм билгеле чишмә – Фәтхерахман чишмәсе. Бу чишмәгә йортны, бизәкләп, Хәлиуллин Рафаэль исемле кеше эшләгән, ә Фәтхерахман исемлесе яннарына агачлар утыртып, аны карап һәм чистартып тора.

Авылда башлангыч мәктәп, балалар бакчасы, медпункт, мәдәният йорты эшли. Кызганыч, китапханә күрше авылга күчерелгән.

Авылда тарих музее юк, ләкин халыктан җыелган элекке эш кораллары, бизәнү әйберләре, тәңкә-чулпылар Зур Сәрдек гимназиясе музеена тапшырылган.

Авылда мәчет төзегәннәр. Зиратны зурайтып, яңа койма белән әйләндереп алганнар. Хәким исемле абзый аны карап һәм күзәтеп, печәнен чабып тора. Ел саен анда авыл өлкәннәре һәм яшьләр өмә үткәрәләр, куакларын төплиләр, караучысыз калган каберләрне рәтлиләр. Авылга кергәндә, зират чиста һәм ямьле булып күренеп тора.

Авыл зурая бара. Чит өлкәләрдә яшәүчеләр арасыннан авылга күчеп кайтучылар да бар икән.

Ялгыз яшәүче өлкәннәр авыл халкының игътибар үзәгендә, аларга һәрдаим ярдәм итеп торалар, күрше-күлән пешкән ризыгыннан һәм яккан мунчасыннан калдырмый. Авыл хакимияте дә, аларның яшәеше белән кызыксынып, матди ярдәм күрсәтеп тора.

## Әсән Елга авылы

Әсән Елга авылы район үзәге Кукмара эшчеләр бистәсеннән 9 чакрымда, җирле үзидарә совет үзәге Пычак авылыннан – 2, Нократ Аланы пристаненнән 17 чакрым ераклыкта урнашкан.

Өлкәннәр авыллары оешу турында болай сөйлиләр: «Борын заманнарда Әсән исемле кеше елга башлана торган чишмә янына килеп, йорт салып яши башлаган. Елга буйлап йомычка агып төшкәч, кешеләр, кызыксынып, аның башлангычына барып караганнар. Килгән халык Әсәнне тапкан. Әсән үзе генә яши алмаган, күчеп киткән. Авыл Әсән Елгасы дип йөртелә башлаган (ул хәзер Әсән Елга дип атала)».

Халык телендә авыл оешу турында икенче риваять тә йөри.

Элекке заманнарда авыл кырыеннан ага торган елга мул сулы булган. Авылдан бераз читтәрәк, тау битендә Әсән исемле кеше үзе генә яшәгән. Көннәрдән бер көнне аның йортында ут чыккан һәм ул янгынны сүндерү өчен су ташыганда елгага баткан. Әсәнне коткарып кала алмаганнар, йорты да янып беткән. Шуннан авыл Әсән Елга исеме алган.

Авыл Республиканың төньяк-көнчыгышында урнашкан. Табигате бик матур. Авылның аръягыннан инеш ага. Инеш буен ямь-яшел таллар, биек булып үскән тупыллар бизи.

Тирә-яктан авылны Шуран тавы, Нарат тавы, Аксай калкулыклары, Беренче кабырга, Икенче кабырга, Өченче кабырга, Ялгыз карама басулары әйләндереп алган. Тау-калкулык итәкләреннән челтер-челтер килеп чишмә-чыганаклар ага.

Әгәр, тау башына менеп, авылга күз салсаң, алда гаҗәеп матур күренеш ачыла. Еракта ямь-яшел урман, иксез-чиксез тигезлектә басу-кырлар җәйрәп ята.

Авыл бер озын урамнан тора. Йортлар бер-берсенә каратып салынган. Тирә-як халкы Әсән Елга авылы урамын «чәч юлы кебек туры» дип сөйли. Урам бер башыннан икенче башына кадәр 3 чакрымга сузылган, ике ягында төп-төз агачлар үсә. Урамга 1919 елларда ук кул белән таш түшәгән булганнар.

Халык телендә авылны Көек (Көйгән, ягъни көек) дип тә йөртәләр. Бу исем каты янгыннардан соң калган, диләр.

Авылның нәкъ уртасында мәчет урнашкан. Ул шактый күптән салынган. Аның кайчан төзелүен төгәл генә белүче юк. Ул мәчеткә хәзерге халыкның ата-бабалары йөргән. Мәчет манарасы, ничектер, киселмичә калган. 1991 елда мәчетне һәм аның манарасын яңартканнар. 1870 елларда салынган бу мәчет тарихи һәйкәл булып исәпләнә. 2011 елда аның каршына яңа мәчет салып куялар. Авыл картлары анда намаз укырга йөри. Колхозлашу чорларына кадәр мәчет белән рәттән урнашкан мәдрәсәдә муллалар ир балаларга сабак укытканнар. Ә кызлар абыстайга йөреп сабак алган. Соңыннан мәдрәсә бинасы мәктәпкә әйләндерелгән.

Авыл халкы зиратны карап һәм тәрбияләп тора. Чардугансыз һәм таш куелмаган кабер юк.

Әсән Елгада авыл тарихына багышланган музей ачканнар. Музей өчен экспонатлар тулыландырыла. Авылда башлангыч мәктәп

ябылган, балалар Пычак авылы мәктәбенә йөреп укыйлар; клуб, китапханә, кибет, медпункт бар. Балалар бакчасы 1976 елдан бирле эшли.

Авылда өлкән буынга игътибар аеруча зур. Әби-бабайлар сөйләвенә караганда, авылдагы бер генә карт-карчык та картлар йортына бирелмәгән. Балалары булмаган карт-карчыкларны карау һәм тәрбияләүне социаль яклау хезмәткәрләренә йөкләгәннәр. Аларга хезмәт хакы түләнә. Авыл халкына бирелә торган ашлык, печән, бал һәм башка әйберләрдән пенсионерлар да өлешсез калмый. 1991 елдан башлап халык үзәкләштерелгән газдан файдалана. Хуҗалыкларга газ кертү чыгымнарын ул вакытта колхоз үз өстенә алган булган.

Авыл советы җирлегендәге унберьеллык мәктәп Пычак белән Морт авыллары арасында (Пычакка якынрак) урнаштырылган.

Хәзер һәр йортка дип әйтерлек су кертелгән. Чишмә-кизләүләр каралып тора. Алар тибеп чыккан урынга матур итеп кечкенә генә өйләр эшләп куйганнар.

Бу төбәктән күтәрелеп киткән күренекле шәхесләр: Пугачев явында полковник дәрәҗәсендә йөргән Мәсәгут Гомәрев (Пычак), татар халык җырчысы Мәрьям Рахманкулова (Арпаяз), әдәбият галиме, язучы Фуат Галимуллин (Арпаяз), күренекле профессор Мәхмүт Яхин (Пычак), Фәйзелхак Газизуллин (Пычак), техник фәннәр докторы, СССРның Дәүләт бүләге лауреаты Фуат Шакиров (Арпаяз), Дубылтыда (Латвия) үткәрелгән яшь драматурглар семинарында дүрт дистә каләмдәшләре арасында беренчелекне яулаган Халисә Нигъмәтуллина (Пычак), күренекле шагыйрь Әхмәт Юныс (Әсән-Елга) һ.б. Авылдашлары шагыйрь Әхмәт Юнысны онытмыйлар. Ул укыган һәм укыткан мәктәптә туган якны өйрәнүгә багышланган музейның бер почмагы шагыйрьгә багышланган.

Халыкның тормышы матур, йортлары таза һәм нык. Читтә яшәүче халык туган авылларына сагынып кайталар. Бу сагынуны Әхмәт Юныс менә мондый шигырь юлларына сала:

Әсән Елга, ямьле Әсән Елга!
Мин кайтырмын сиңа тагын да,
Алмагачлар үсеп, шушы юлга
Алмалары төшкән чагында.

## Байлангар авылы

Байлангар авылы район үзәге Кукмара эшчеләр бистәсеннән 12 чакрымда, Нократ Аланы пристаненнан 22 чакрым ераклыкта урнашкан.

Авыл атамасы шактый тарихи чыганакларда теркәлгән. Әйтик, Казан ханлыгы чоры авыл атамаларын исәпкә алган исемлектә Байлангар авылы күрсәтелгән. Д.А. Корсаков белешмәсе мәгълүматларына караганда (XVIII гасыр), Байлангар авылында 162 йомышлы татар яшәгән. Байлангар авылын А. Артемьев (1866) тарихи белешмәсеннән түбәндәгечә күз алдына китерәбез: Норма суы ярына утырган авылның 150 хуҗалыгында 532 ир-ат һәм 563 хатын-кыз яшәгән, мәчет эшләгән. Байлангарны И.А. Износков (1864) болай искә ала: авыл Норма суы буена урнашкан, анда 560 ир-ат һәм 587 хатын-кыз яшәгән. 1898 елда басылып чыккан белешмәдә күрсәтелгәнчә, авылда татар кешеләре яшәгән. К.П. Берстель (1908) белешмәсендәге мәгълүматларга караганда, авылда 1343 татар теркәлгән.

Тел галиме Нәҗия Борһанова мәгълүматларына караганда, Байлангар авылы халкы Өлге, Татар Кукмарасы, Манзарас, Кәчимир, Киндеркүл, Ташлы елга, Пычак, Арпаяз, Камышлы, Каенсар, Иске Пенәгәр авыллары белән Өлге җыены үткәрә торган булганнар. Ул июньнең соңгы декадасында оештырылган.

Өлкәннәр сөйләвенчә, Байлангар авылын Чурай тавы итәгенә нигезләгәннәр. Бу тирәләрдә, авыл оешканчы, кара урман үскән. Иске Йорт дигән авылдан 3 бай малае, бирегә төшеп, урманнарны кистергәннәр, йортлар төзеткәннәр һәм яшәп калганнар. Авылга алар хөрмәтенә Байоланнар исеме бирелгән. Тора-бара атама Байлангар булып үзгәреп киткән. Авыл XV гасыр ахырларында оешкан.

Олыларның фикере дөрес булса кирәк, чөнки авыл атамасы Казан ханлыгы чорында оешкан авыллар исемлегенә кертелгән.

Авылны урталай ярып, Норма елгасы ага. Елганың бер ягында Аю күле ялтырап ята. Бик ераклардан кайткан кешеләр суын алып китә торган изге чишмә – Салкын чишмә белән дә дан тота ул Байлангар. Бу чишмә бура белән буралган, түбәсенә манара белән ай куелган. Аның янында бер кабер дә бар. Бу каберне карап, чистартып торалар.

Авыл тирәсендә зур урманнар булмаса да, вак урманнар бар. Халык аларны Рәхилә, Рәхимә һәм Кашаф урманнары дип атый.

Болын исемнәрен дә әле халык хәтерендә саклый: Мулла болыны, Ташлык, Исәнлек, Ферма болыны һ.б. Кызганыч, хәзер тирәюньдәге географик берәмлекләрнең исемнәре онытылып бара.

Элекке заманнардан ук бу авыл халкының кушаматы «усаллар» булган. Халык моны чукындыру сәясәте чоры белән бәйләп аңлата. Чукындыручылар килүне алдан күргән авыл халкы Чурай тау башына менгән һәм аларны таш атып каршы алган, чукындыруга каршы торган.

Өлкәннәр сөйләве буенча, элек авылда зур гына «ат тегермәне» булган. Тегермән ташларын махсус җайланма ярдәмендә атлар әйләндергән.

Элек авыл уртасында зур гына мәчет эшләгән. Янында мәдрәсә дә булган. Анда Нурый мулла белән Зариф мулла дин сабагы укытканнар. Яманаты чыккан елларда мәчетнең манарасы киселә. Бүген аның урынында яңа мәчет балкып утыра.

Авылда хәзер урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә, балалар бакчасы, медпункт, туган якны өйрәнү музее эшли. Халык үзәкләштерелгән газ яга, йортларга су кертелгән. Юлларга асфальт түшәлгән.

Байлангар авылының урта хәлле крестьян гаиләсендә язучы Мәгъсүм Насыйбуллин туып үскән.

## Битләнгер (Аксыбы) авылы

Битләнгер авылы район үзәге Кукмарадан 24 чакрым ераклыкта, җирле үзидарә советы үзәге Түбән Өскебаштан – 2, Гурьевка пристаненнан 19 чакрым ераклыкта урнашкан.

Авыл атамасы тарихи белешмәләрдә шактый еш искә алына. А. Артемьев җыеп чыгарган тарихи белешмәдән (1859) күренгәнчә, авыл Акцыбово (Битләнгер) формасында бирелгән. Өске суы ярына утырган бу авылда 55 хуҗалык булып, аларда 182 ир-ат һәм 176 хатын-кыз көн күргән, мәчет эшләгән. И.А. Износков җыеп чыгарган белешмәдән аңлашылганча, исемлектә авыл Аксуфи, Акцибово, татарча Балтанир, Белтангир вариантлары белән күрсәтелгән. Өске суы ярына урнашкан бу авылда 185 ир-ат һәм 179 хатын-кыз көн иткән. Аксуфи атамасы авылны беренче тапкыр нигезләгән шәхескә нисбәтле рәвештә барлыкка килгән. 1898 елда басылып чыккан тарихи белешмәдә авыл Битләнгер (Аксебо) дип теркәлгән.

К.П. Берстель бастырып чыгарган белешмәдә (1908) авыл Битләнгер (Акунбово) дип атала. Анда 634 татар кешесе яшәгән.

Нажия апа Борһанова мәгълүматларына караганда, Битләнгер (Аксыбы) авылы халкы, күршедәге Югары Тәкәнеш, Түбән Тәкәнеш, Урта Тәкәнеш, Югары Козгынчы, Түбән Козгынчы, Түбән Дусай, Тулбай, Олыяз, Иске Чәбья, Яңа Чәбья, Шәмәк, Көмеш күл (Биләтле), Алгай, Өске, Сарбай (Каравыл), Югары Өскебаш (Казаклар), Түбән Өскебаш авыллары белән бергә, 12–18 июньдә (иске стиль белән) Тукташ җыены үткәрә торган булган. (Тукташ, күрәсең, бу зур җыенның башлыгы булгандыр.)

Өлкән буын сөйләвенә караганда, авыл болай оешкан: «Ике бертуган, абыйлы-энеле Аксуфый белән Янсуфый, бәхет эзләп юлга чыгалар. Аларның юллары бик озын һәм катлаулы була. Янсуфый хәзерге Кукмарадан ерак түгел генә бер аланлыкка тукталып төпләнеп калса да, Аксуфый юлын дәвам итә. Бик еракка китмичә генә, елга буендагы бер аланлыкка чыга һәм шунда төпләнеп кала. Үзе өчен алачык ясый, урман кисеп утын әзерли, җирне эшкәртеп бераз ашлык та чәчә. Елганың уң ягында чыга торган чишмәне чистарта, су юлын киңәйтә.

Озакламый монда берән-сәрән кешеләр дә килә башлый. Бу якларны ошатканнары шушында урнашып та кала. Бер-берсе белән уртак тел табып, үзара ярдәмләшеп матур гына яши башлыйлар, Аксуфый хөрмәтенә авылны Аксыбы дип атыйлар...»

Авыл зураеп үсеп китә. Урмандагы агачлар киселгән һәм төпләнгән. Шулай итеп ашлык чәчү өчен җир дә ачылган. Халык болан, поши, куян аулаган. Тиреләреннән тун-бүрек теккәннәр. Торабара халык сыер, сарык кебек мал-туар да асрый башлаган.

Көннәрнең берендә күрше Өскебаш халкы Аксыбыга таба җирләрен арттыра башлый. Өскебашлар Аксыбы халкының җирен ала икән, дигән хәбәр тарала. Бу хәбәрне ишетүгә җиде хуҗалык, Галим исемле кешегә ияреп, түбәнрәк, хәзерге күпер янына төшеп утыра. Ике авыл арасында бәрелеш тә булып ала. Соңрак бу урынга башка хуҗалыклар да төшеп утыра.

Авылда Дөббәрүш исемле бик укымышлы кеше була. Ул халыкны да белемле итәргә тырыша. Алар гаиләдә җиде бала үсәләр һәм җидесе җиде авылга урнашалар. Ул вакытта ук инде укымышлы кешегә халык изге зат, дип карый торган була. Җиде туган утырган 7 авылда да алар хөрмәтенә чишмәгә «Изгеләр чишмәсе» дип исем

бирелә. Аксыбылылар да бер чишмәне «Изге чишмә» дип йөртә. Халык Аксуфыйга да изге зат, дип караган. Әлеге чишмәне Аксуфый карап һәм чистартып торган. Хәзерге көндә чишмә өе манаралап эшләнгән һәм өстенә ай куелган. Аның эчендә янәшә ике чишмә ургылып тора. Суы бик шифалы, диләр. Авыл халкының күбесе суны шуннан эчә. Су алу өчен башка җирләрдән килүчеләр дә байтак.

Авыл зурайганнан-зурая. Урамның күпердән өскә таба урнашкан өлешендә яшәүчеләрне – «югары очлар», ә күпердән түбән утырганнарын «түбән очлар» дип йөртәләр. Күпернең икенче ягына, тау башына да өйләр салына. Бу урын халык теленә Атау дип кереп калган. Авыл ягыннан Өске инеше ага. Ул Югары Өскебаш авылы яныннан башланып, Түбән Өскебаш, Мамадыш районының Зур Өске һ.б. авылларны үтеп, Шия елгасына кушыла.

Авылда элек тә таза тормышлы кешеләр шактый булган. Түбән очта яшәгән Садыйк бай эшне әйбәт итеп, җиренә җиткереп эшләве белән аерылып торган. Ул алны-ялны белмичә эшләп, шактый байлык туплаган. Садыйк бай кешеләре иртә таңнан торып, елга буенда дегет кайнатканнар. Бу елганы һәм монда чыга торган чишмәне Завод як, Завод елгасы, Завод чишмә дип йөртәләр.

Күпер янында тагын бер чишмә бар. Аны Мотыйгулла чишмәсе дип атаганнар. Ә Изгеләр чишмәсе белән авыл арасындагы чишмә Маһирә чишмәсе дип йөртелә.

Төньяктан – Югары Өскебаш, көньяктан Түбән Өскебаш белән чикләнгән, ә көнчыгыштан һәм көнбатыштан урман белән уратылган Аксыбы авылы кешеләре, җир кирәк булгач, күмәк төстә урман кисә башлыйлар. Алар йорт салу өчен агачлы гына түгел, ашлык чәчү өчен җирле дә булалар. Бу эшкәртелгән җир Эчке ышна дип йөртелә.

Урманнарны халык Тау як урман, Аръяк урман дип атый.

Тау як урман ягыннан Өске суына Битләнгер инеше килеп кушыла. Заманында аның суы шактый мул иде, диләр.

Хәзер халык телендә авыл атамасы ике төрле кулланыла: Битләнгер һәм Аксыбы. Битләнгер атамасы югарыда телгә алынган Битләнгер инешенә мөнәсәбәтле булса кирәк. Ләкин авыл халкы күңеленә Аксыбы атамасы якынрак. Сөйләм телендә авылны Аксыбы дип йөртәләр, ә Битләнгер атамасы рәсми документларда гына кулланыла.

Электә авыл уртасында мәчет салынган булган. Кыз балалар абыстайда, ир балалар муллада сабак укыганнар. Бу балалар аннан соң Түбән Өскебаш авылы мәдрәсәсенә барып белем алганнар.

Авылда Динмөхәммәт исемле бик көчле, батыр кеше яшәгән. Халык сөйләвенә караганда, хәтта чукындырырга килүчеләр дә Динмөхәммәттән куркып, авылга керми киткәннәр имеш.

1917 елгы гражданнар сугышына авылдан 57 кеше китә. Шуларның 31 е авылга кире әйләнеп кайта, калган 26 сы һәлак була. Күбесе Азин дивизиясендә сугыша.

1929 елда авылда башлангыч мәктәп ачыла. Бу мәктәптә читтән килгән Басыйр, Каюм, Бәдәр, Галимә исемле укытучылар белем бирә. Алар авылдагы Зиннур абзыйларда фатирда торып эшләгәннәр.

1929 елда халыкны көчләп колхозга кертәләр. Ләкин колхоз озак яшәми, таркала. Шуннан соң авылда колхоз тормышы турында агитация-пропаганда эшләре җәелдерелә һәм кешеләр кабат колхозга язылалар. Колхозга бары тик 2 хуҗалык кына керми кала. Колхозны «Ворошилов» исеме белән атыйлар һәм ул Тәкәнеш районына керә. Колхозда барысы 90 баш ат, 4 сыер исәпләнелә. Колхоз яралгач та куян, сарык фермасы ачыла.

1931 елда авылдан 5 хуҗалык «кулак» дип аталып, Себергә куыла. Алар арасында Миңлеәхмәт, Габдулла, Гыйльман, Низами һәм авыл мулласы гаиләләре була. Көне-төне эшләү исәбенә башкалардан арурак яшәүче бу кешеләргә нахак бәла тагыла һәм аларны «кеше өстеннән көн күрүчеләр» дип атыйлар. Аларның мал-туары, умарталыклары колхозга алына, милекләре халыкка таратыла. Соңыннан гына аларның Магнитогорскига китеп урнашулары мәгълүм була. Вакытлар узу белән аларның балалары авылга кире әйләнеп кайта.

Тора-бара колхоз тернәкләнеп китә. Басуларда эш кайнап тора. Ә басу-кырлар ат белән сукалана әле. Колхозга 2 чәчү машинасы һәм 1 урак машинасы алалар.

Колхоз 7 бригадага бүленә, кирәкле әсбаплар һәр бригадага бүлеп бирелә.

1930–1931 елларда уңыш әйбәт кенә алына. Эшкә соң чыгып, эш нормасын үтәмәгән звеноларга һәм ялкауларга чыпта байраклар һәм «ташбака»лар бирү тәртибе кертелә. Шуңа күрә колхозчылар бик тырышып эшлиләр, эш нормасын үтәмәүне, эш сыйфаты начар булуны оят саныйлар.

1937 елда иген аеруча уңган. Бер хезмәт көненә 7 шәр килограмм исәбеннән ашлык биргәннәр. Тырышып эшләп, хезмәт көне күбрәк булган кешеләргә ашлыкны кызыл олау белән илткәннәр.

1937 елда колхозга тонна ярым йөк күтәрешле машина кайта. Авылда беренче шофер булып Зәки Закиров эшли.

1941–1945 еллардагы Ватан сугышы вакытында колхоздагы барлык хезмәт хатын-кыз җилкәсенә кала. «Барысы да фронт өчен, барысы да җиңү өчен» чакыруы астында көн-төн эшләргә туры килә аларга. Авыл халкы өч бригадага бүленеп эшли.

Хатыннар, яшүсмерләр көрәк белән басу казыйлар, үгез җигеп җир сукалыйлар. Картлар орлык чәчә. Тәкәнештә махсус курсларда укып кайткан Миңлеголова Фәрханә «Фардзон» тракторына утыра. Тәкәнештән килгән Хәбибрахман исемле кеше дә тракторда эшли башлый. Чәчү өчен ашлык Нократ Аланыннан һәм Кукмара элеваторыннан кайтарыла. Хатын-кызлар һәм егәре булган картлар капчык белән аркаларына асып, чәчүлек орлык ташыйлар. Яз көннәрендә Нократ суы аша чыгып, ашлык алып кайту бик авыр була. Боз чатнап, боз астына китү очраклары да булгалады, дип сөйлиләр.

Кыш көннәрендә хатын-кызлар урман кисәләр, утын ташыйлар.

Колхозның сарык фермасында Сәгыйдә һәм Мәгыйшә апалар эшли. 10–15 хатын-кыз җыелышып сарык йонын алып, аны дәүләткә тапшыралар. Көне-төне эшләүгә хезмәт көненә нибары 200 әр грамм икмәк бирелгәнен дә әйтеп китик.

Кичләрен авыл уртасындагы клубта җыелышлар үткәрелә, концерт һәм спектакльләр куела. Авыл халкы үз күңелен үзе күтәрергә дә вакыт таба. Һәр шимбә саен өмә оештыралар. Бу өмәләрдә мәктәп укучылары да актив катнаша. Сугышчылар өчен авыл халкы җылы бияләйләр, оекбашлар бәйли, башка кирәк-яраклар хәстәрләп, фронтка озата.

Хатын-кызларның күбесе окоп казырга, кайберләре Нократ Аланына, Мамадышка урман кисәргә җибәрелә.

1943 елдан башлап, авылга яраланган сугышчылар кайта башлый. Күп кешеләрнең үлгән хәбәре килә.

Сугыш бетү, бер яктан, шатлык алып килсә, икенче яктан, күз яшьләре дә күп түгелә. Сугышка киткән 150 кешенең 65 е чит җир-

ләрдә үлеп кала. Рәхимсез сугыш авылдагы 30 хатынны ирсез, 80гә якын баланы ятим итеп калдыра.

Татарстанның Александр Матросов үрнәген кабатлаган 25 каһарманы арасында Кукмара районыннан да ике батыр була.

Аның берсе – Әхмәтгали Мөхәммәди улы Мөхәммәдиев. Ул 1923 елның 3 июлендә туган. Нәсел-тамырлары Кукмара районының Битләнгер авылы һәм Мамадыш районының Югары Ушмы авылына барып тоташа. Сугышка кадәр ул Донецк өлкәсенең Кызыл Армия районындагы Дмитров шәһәрендә яши, шахтада эшли. Сугышка алынганнан соң, 299 нчы номерлы укчы дивизиянең 960 нчы укчы полкы разведчигы була. 1944 елның 26 февраленә каршы төндә Кировоград өлкәсенең бер авылы янында һәлак була. Күрсәткән батырлыклары өчен ул Ленин ордены һәм III дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнә.

Икенче батыр – Битләнгер авылы егете Нух Идрис улы Идрисов. Ул 1918 елда Битләнгер (Аксыбы) авылында туган. Әтисе гражданнар сугышыннан бик авыр яраланып кайта һәм 1921 елда вафат була. Ачлык гаиләдәге биш баланың өчесенең гомерен өзә. Гаиләне алып бару, олы бала булганлыктан, Нух җилкәсенә төшә.

Идрисовлар гаиләсе колхозга беренчеләрдән булып керә. Нух унике яшеннән колхозда эшли башлый. Бераздан аны хат ташучы, аннары клуб мөдире итеп билгелиләр, ә авыл комсомоллары аны үзләренә җитәкче итеп сайлыйлар. Тора-бара комсорг егет бригадирлар курсын тәмамлый һәм аны егерме яшендә «Ворошилов» колхозына рәис итеп сайлыйлар. Кая куйсалар да, Нух Идрисов үз эшен намус белән башкара.

1938 елда ул хәрби хезмәткә алына. Аннан кайткач, Нухны яңадан колхозга рәис итеп куялар. Бу вакытта ул авылда укытучы булып эшләүче Наҗия исемле кызга өйләнә. Матур гына яшәп ятканда сугыш башлана, Нух Идрисов фронтка китә. 1944 елның 27 июлендә ул Александр Матросов батырлыгын кабатлый, немец амбразурасын күкрәге белән каплый. Аңа шушы батырлыгы өчен I дәрәҗә Ватан сугышы ордены бирелә. Орденны сугыш беткәннән соң 24 ел үткәч, хатыны Наҗия апага тапшыралар. Наҗия апа сугыштан үзенә ире язган хатларны һәм орденны бик кадерләп саклый.

Нух Идрисов шигъри җанлы кеше булган, күңелендәге хисләрен рифмага салган.

**Без җиңәргә килдек бу җиргә!**

…Карелиянең алтын иртәсендә
Тапшырдылар синең хатыңны.
Хисләремдә – ташкын, йөрәгемдә – ялкын,
Шатлыгымнан күңелем очынды!
Хатың ачып укыйм… Һәр сүзеңдә –
Шундый көчле, якты мәхәббәт!..
Күктә йөзә сихри ак болытлар,
Күк өсләре – зәңгәр зөбәрҗәт…
Менә – сигнал! Батарея ата,
Кузгалабыз хәзер һөҗүмгә.
Без алырбыз таш каланы, тауны –
Без җиңәргә килдек бу җиргә!
Сугыштан соң, җиңү бәхете белән
Хат язармын сиңа, гүзәлем!..
Башың имә, яшькә чыланмасын
Мине сөйгән кара күзләрең!

1943 ел, 10 февраль

**Син көт, иркәм!**

Син көт, иркәм, син көт – мин кайтырмын,
Шомыртлар ак чәчәк атканда!..
Тәрәзәңне чиртеп уятырмын
Җиңү белән өйгә кайтканда!
Салкын чишмәләрне урарбыз да
Без йөрербез бергә болында.
Мин сөйләрмен сиңа яшь егетнең
Үлмәс батырлыгы турында.
Дошман тылларына разведкага
Барган чакта урман буеннан,
Мәхәббәтең миңа гайрәт бирде
Һәм саклады дошман угыннан.
Кайда гына, иркәм, йөрсәм дә мин,
Син булырсың һәрчак күңелемдә.
Атакага бардым синең белән
Һәм ял иттем нарат төбендә…
Син көт, иркәм, син көт – мин кайтырмын,
Шомыртлар ак чәчәк атканда!
Тәрәзәңне чиртеп уятырмын,
Җиңү белән өйгә кайтканда!

1943 ел, 22 февраль

Нух Идрисов Карелиянең Суоярви районында җирләнгән. 1984 елда аның сөякләре «Туганнар каберлегенә» күчерелә. Ә туган авылында ул утырткан пар каен шаулап үсеп утыра. Шушы каен янында батырга истәлек тактасы куелган. Түбән Өскебаш урта мәктәбе Нух Идрисов исемен йөртә һәм мәктәп каршында матур чәчәкләргә күмелгән һәйкәл балкып тора.

1945 елда «Ворошилов» колхозы «Авангард» дип үзгәртелә. Шушы елны колхозга фронтка җибәрелгән атлар кайта башлый.

Элек авыл яшьләре клубта «Биш парлы», «Йөзек салыш», «Назалы», «Зил-зил-зиләле», «Каеш сугыш» уеннарын яратып уйнаганнар. Җырлап, биеп күңел ачулар еш булган. Авыл гармунчылары Гыйльметдин, Вакыйф, Мулланур, Таһир, Муллаәхмәт абыйлар гармун уйнап, авыл урамнарын, клубтагы кичәләрне гөрләткәннәр. Аулак өйдә яшьләр пилмәннәр, яргычтан бодай ярып, бөккәннәр пешергәннәр. Яшьләр бер-берсе белән шушындый кичәләрдә очраша, таныша һәм кавыша торган булганнар. Кызларны чит авылга кияүгә бирүне бер дә яратмаганнар, хәтта аны хурлык дип санаганнар. Егетләр үз авыллары кызларына өйләнәләр, кызлар үз авыллары егетләренә кияүгә чыгалар. Авыл туганлашып бетә.

Авыл уртасында урнашкан мәктәпнең бик матур бакчасы була. Җәй көне, урып-җыю вакытында мәктәпкәчә яшьтәге балалар шул мәктәптә тәрбияләнә. Балаларын ышанычлы кулларга тапшырган ата-аналар басуда тырышып эшләгәннәр. Мәктәптә балаларны Шәмсебану, Сәгыйдәбану, Мәймүнә, Зарифа апалар караган.

Мәктәптә Каюм абый, Бәдәр һәм Галимә апалар укыткан. Соңрак ирле-хатынлы Рәкыйп абый белән Гөлсем апа һәм Нурзидә, Разия апалар да эшләгән. Аннары мәктәп өскәрәк күчереп салына. Укучылар 4 нче сыйныф белемне шул мәктәптә алалар. Алга таба уку өчен авылдан 12 чакрым ераклыктагы Кәркәвеч мәктәбенә йөрергә туры килә.

1937 елда Казаклар авылында җидееллык мәктәп ачыла, 1959 елда бу мәктәп сигезьеллык итеп үзгәртелә. Укуын дәвам итәргә теләгән балалар Кәркәвеч авылына йөреп унъеллык белем алганнар.

Ул елларда яшьләр авылда төпләнеп эшкә урнашалар, шунда өйләнеп тормыш коралар. Йортлар аз булса да, халык саны 600 гә җитә.

Авыл мәчетенең манарасы 1934 елның 14 апрель көнне киселә. Иртән кояш ялтырап чыга, көн матур була. Ләкин, манараны

кисеп төшерүгә, кара болыт чыгып, давыллап яңгыр ява башлый. Мәчетнең аен Ибраһим исемле кеше үз хуҗалыгына алып кайтып яшерә.

1956 елда Казаклар (Югары Өскебаш), Аксыбы, Түбән Өскебаш, Кызыл Тау һәм Никольский авыллары берләшеп, «Таң» колхозы булып оешалар. Авылда колхозга караган бер умарталык, атлар һәм сыер фермасы була.

Заманалар үзгәрә, укырга керү, читтән эш эзләү максаты белән яшьләр авылдан китә башлый. 1970 елда авылда 620 кеше исәпләнсә, 1980 елда 480 кешегә кала.

1970 елның 22 декабрендә авылда балалар бакчасы ачыла. 1980 елда Түбән Өскебаш авылында унъеллык мәктәп ачыла. Укучылар Аксыбы авылыннан 3 чакрым ераклыкта урнашкан шул Түбән Өскебаш авылындагы мәктәпкә йөреп укый башлыйлар.

1980–1985 елларда, колхозда эшләргә кеше кимү сәбәпле, унынчы сыйныфны тәмамлаучы яшьләрне бер елга авылда алып калып эшләтәләр.

1990 елда Аксыбы зиратында сугыш кырларында батырларча һәлак булган кешеләр истәлегенә биеклеге 18 метрлы манара төзелә. Анда гражданнар һәм Ватан сугышында һәлак булучылар исемлеге теркәлгән.

1992 елда авылда яңа башлангыч мәктәп салына. Мәктәп мөдире итеп Әнисә Мөхәммәтҗанова билгеләнә һәм алар өч укытучы – Фирдәвия Закирова, Миләүшә Әгъләмова һәм Әнисә Мөхәммәтҗанова балаларга башлангыч белем бирәләр.

1992 елда авылда яңа мәчет салынып бетә. Биш вакыт намаз, гает намазы шушы мәчеттә укыла. Битләнгер (Аксыбы) авылы карты Галәветдин агай мәчет ачтыру, сугыш кырларында һәлак булучылар истәлегенә һәйкәл булдыру өчен аеруча тырышып эшләгән.

1992 елда авылга су колонкалардан килә башлый. Авылдагы 15 коеның өсләре берәм-берәм кадаклана. Эчәргә чишмә суларына йөргән авыл халкы инде чишмәгә кер чайкарга гына бара башлый.

Авылда ялгыз картларга игътибар зур. Авыл халкы аларга кулыннан килгәнчә булыша, балалар да шефлык итәләр.

«Үлгәннәрнең каберен бел, исәннәрнең кадерен бел», – ди халык. Авыл халкы әби-баба ята торган зиратны карап һәм тәрбияләп торуга да зур әһәмият бирә. Зиратның тирә-юне киртә белән әйләндереп алынган, коймасы буялган.

1992 елда колхоз рәисе итеп билгеләнгән Раиф Газизуллин авылга су керттергән, юлларны күтәртеп, таш түшәткән.

Авылга үзәкләштерелгән газ кергән.

Авылда яз көннәрендә зәрә (дәрә) бәйрәм ителәә. Балалар өйдән-өйгә кереп:

Дәр-дәр дәрәгә
Бүген түгел, иртәгә,
Абыстайлар, түтәйләр,
Бай, диләр, бай, диләр,
… абыйны бай, диләр,
Берәр кашык май, диләр,
Күкәй дә ярый, диләр, –

дип такмаклап, ярма, май, йомырка җыялар, аны, тау башында учак ягып, казан асып пешерәләр һәм халыкка тараталар. Шул көнне һәр хуҗалык күп итеп йомырка «кызарта». Иртәгесен балалар иртүк торып, «кызарткан» йомырка җыялар, аны тәгәрәтеп уйныйлар. Җырлар-биеп, уеннар уйнап бәйрәм үткәрелә.

Җәй көне сабан туйлары бик күңелле үтә. Анда милли көрәш, ат чабышы, колга башына менү, капчык сугышлары, чиләк-көянтә күтәреп, кашыкка йомырка салып, капчык киеп йөгерү кебек ярышлар үткәрелә.

Авыл басуында Завод елгасы (янында кайчандыр сумала кайната торган завод булган), Янык елгасы, Дәүли елгасы, Пәсе елгасы, Битләнгер елгасы (халык аны Инеш дип йөртә) бар. Авыл уртасындагы чишмә дә, авыл читендәге Изгеләр чишмәсенә дә бизәлеп, зәвык белән кечкенә генә йорт эшләнгән. Моннан башка тагын Завод елгасы чишмәсе, Олы чишмә, Маһирә чишмәләре бар. Күлләр: Мунчала күле, Казаклар күле һ.б. Авыл тирәсендәге урманнар: Аръяк урман, Тау як урман, Сәшәрә посадкасы, Каенлык, Кыр башы урманы, Keләвеш урманы һ.б.

Авылда башлангыч мәктәп, балалар бакчасы, кибет һәм клуб бар.

### Вахит (Бүлиле) авылы

Вахит авылы Кукмара эшчеләр бистәсеннән 28 чакрымда, җирле үзидарә советы үзәге Янил авылыннан – 3, тимер юл станциясе Шәмәрдәннән – 15, Нократ Аланы пристаненнан 36 чакрым ераклыкта урнашкан.

Вахит авылы халкы күршедәге Янил, Ядегәр, Тарлау, Югары Шәмәрдән, Түбән Шәмәрдән, Бөер, Каенсар авыллары белән бергә июнь уртасында Янил җыены, Тарлау җыены бәйрәм иткән.

Колхозлашу чорына кадәр Вахит авылы Бүлиле атамасы белән йөртелгән.

Халык телендә Бүлиле атамасының барлыкка килүе турында төрле фикерләр яши. Элек авыл Югары Бүлиле һәм Түбән Бүлиле дип аталган һәм ике мәхәлләдән торган. Алар тоташмаган да булганнар. Бераздан ике мәхәллә арасындагы буш урынга кешеләр килеп йортлар салганнар, мәхәлләләр кушылып киткән. Ә халык телендә Югары оч һәм Түбән оч атамалары әле дә сакланып калган.

Авыл бик матур урында. Аңа ямь биреп буеннан-буена тау сузылган. Бу тауның төрле өлешләренә элек-электән атама бирелгән. Вәли тавы, Кала-тау, Тәбәнәк тау, Янил тавы, Кәҗә тавы һ.б. исемнәр халык телендә хәзер дә кулланыла.

Вәли тавы атамасының килеп чыгышы болай булган: элек авылда Вәли исемле бик бай мулла булган. Ул тегермән тоткан. Шул тегермән турысындагы агачсыз тау аның исеме белән йөртелгән. Янәшәдә Кала тавы бар. Ул – арада иң биеге. Артыш күп үскәнгә, аны Артышлы тау дип тә атыйлар. Сугыш елларында ягарга булмау сәбәпле, тау өстендә үскән агачларны кисеп ягып бетергәннәр һәм ул пеләшләнеп калган.

Сугыш елларында авыл янында хәрби эшкә өйрәнү полкы торган. Болар да агачларны утын итеп якканнар. Сугыштан соң халык тауларга нарат агачы үсентеләре утырткан. Хәзер алар бик матур булып үсеп киткәннәр. Кәҗә тавы – сөзәк кенә тәбәнәк тау. Кәҗә тавының бер өлешендә чикләвек куаклары, төрле агачлар үсә. Элек бу агачлар арасында кыр кәҗәләре яшәгән. Кала тауда элек бакыр чыгарганнар, ул урынны Бакыр базы дип йөртәләр. Ул җирләр хәзер батынкы булып тора, өстендә печән үсә.

Элек тауларны төрле яктан саклаганнар, кеше кертмәгәннәр. Чикләвек һ.б. әйберләр җыю өчен билгеле бер вакыт билгеләнгән булган. (Ә хәзер елның теләсә кайсы вакытында тауга барып, теләгән әйбереңне җыярга мөмкин. Бирегә күрше авыллардан да җиләк, гөмбә, дару үләннәре, чикләвек җыярга киләләр.) Тау өчен Миңлегол абзый Гомәров җаваплы булган. Ул үз эшен күңел биреп эшләгән. Тауда, андагы урманда чисталык, пөхтәлек һәм тәртип хөкем сөрә. Тау итәкләрендә элек яшелчә үстергәннәр, хәзер анда

болынлыклар җәелеп киткән. Язгы эшләр беткәч, Кала тавы астындагы болынлыкта Сабан туе үткәрелә. Бу бәйрәмгә төрле төбәкләрдән кунаклар, авыл халкы җыела. Калган болынлыкларда хәзер көтү йөри.

Тау итәге буйлап, бормаланып-бормаланып, Бөре елгасы ага. Бу су Балтач районының Борбаш авылыннан башлана. Вахит (Бүлиле) авылына төшеп җиткәнче аңа шактый инешләр кушыла.

Авылда чишмәләр дә күп, алар таудан агып чыгалар. Шул чишмәләрнең берсен (хәзер аны Вәли тау асты чишмәсе дип йөриләр) Вәли бай карап һәм чистартып торган. Ул бик саран булган, авыл халкына чишмәдән су алырга рөхсәт итмәгән. Үзе вафат булгач кына кешеләр ул чишмәдән эчәргә су ала башлаганнар. Чишмә өстенә кечкенә өй ясап куелган. Чишмә янында яшәүче Д. Яруллина аңа багышлап мондый шигырь язган:

Авылымның тау кырында
Чишмә ага күптәннән.
Безнең авыл халкы аннан
Эчәргә су китергән.

Әби сөйләве буенча,
Отып алдым мин шуны:
Бу чишмәнең нигезенә
Тигән осталар кулы.

Чишмәбезнең көчлелеге
Кимеде тора-бара,
Юлына таш үскәнлектән,
Әкренләп кора бара.

Читтә йөрүчеләр кайта,
Онталмый чишмә тәмен.
Чистартыйк без чишмәләрне,
Югалтмыйк авыл ямен.

Вәли чишмәсеннән берничә метр гына ераклыкта Камали чишмәсе челтерәп агып ята. Бөре елгасы ярында иске генә бер йорт бар, ул чишмә янында урнашкан. Шул йортта ялгызы гына бер әби яшәгән, ул чишмәне гел чистартып һәм карап торган. Ул үзе күптән мәрхүмә инде, ләкин халык телендә чишмә һаман аның исеме белән атап йөртелә. Авыл башындагы бик матур өйчек эчендә Авыл башы чишмәсе агып ята. Бу чишмәләрнең өчесе дә Түбән очта. Ә дүртенче чишмә – Югары очта. Элек-электән бу чишмә-кизләүне Миңлегол абзый Юнысов караган. Яше олы булса да, ул чишмә янында еш күренгән. Миңлегол абзый: «Авылның Мәккәсе дә, Мәдинәсе дә шушы чишмә», – дип әйтергә яраткан. Элек авылның кызлары, яшь киленнәре чишмә сукмагында очрашып сәлам алышканнар, авылның соңгы хәбәрләре дә шунда таралган. Чишмә буен иңләп үскән таллар да күпне күргән һәм күпне ишеткән. Элек бу чишмәне

Чокыр чишмәсе дип атап йөрткәннәр. Хәзер, инде әйткәнебезчә, Миңлегол чишмәсе исемен йөртә. Хәзер су торбалар аша һәркемнең йортына кертелгән. Шулай да, чишмәгә сукмак өзелми – суга булмаса, җанга сихәт алырга баралар.

Югарыда саналган географик берәмлекләрдән тыш, авыл тирәюнендә тагын да матур урыннар күп. Исемнәре дә үзенчәлекле.

Чабыла исемен йөрткән урын элек бик зур булган. Аны икегә бүлеп, берсен – Якты Чабыла, икенчесен Караңгы Чабыла дип атаганнар. Якты Чабыланың табигый байлыкларыннан кеше иркен файдаланган. Ә Караңгы Чабылада кеше йөрмәгән, чөнки анда урман бик куе булган, хәтта качкыннар да яшәгән имеш. Анда печәнгә һәм җиләккә дә барырга батырчылык итмәгәннәр.

Ни өчен бу урынны Чабыла дип атаганнар? Кайберәүләр әйтүенә караганда, әлеге атама «печән чабу» дигән сүздән алынган (печәнле урыннар чабылу җире дип аталганнар). Хәзерге вакытта анда агачлык калмаган, берән-сәрән артыш агачлары гына үсеп утыра.

Торна сазлыгын авылда һәркем белә. Олылар, элек бу урынның суы шактый ишле иде, дип сөйлиләр. Торналар шунда килеп бала чыгарып ятканнар. Тора-бара аның суы да, сазлыгы да кипкән. Ул җирне көрәк белән эшкәрткәннәр, арпа, солы һәм борчак чәчкәннәр.

Торна сазлыгының икенче тарафында элек Шалтыра суы аккан. Суы тавышланып, шалтырап аккан өчен аны шулай атаганнар. Су буйларында җиләкләр һәм печән әйбәт үскән. Шалтыраның инде суы кипкән, су аккан урын гына бераз беленеп тора. Яз көннәрендә генә бу урыннан шалтырап су ага. Ул Янил белән Вахит авылларын тоташтыручы юлны кисеп, Печмән аша Бөреле елгасына койган. Элек юллар сукмак кына булганлыктан, күп вакыт кешеләр су аркылы чыга да алмаганнар.

Шалтырадан, басу буйлап, Югары очка менеп киткәч, үзәнлеккә килеп чыгасың. Бу үзәнлекнең исеме – Чокыр башы. Бу атаманың килеп чыгышы турында өлкәннәр болай сөйли: әле Бүлиле авылы барлыкка килгәнче үк, авыл урынының күп өлеше сазлыклы җир булган. Иң элек авылдан өстәрәк җиргә берничә удмурт (ар) гаиләсе килеп тормыш корып җибәргән. Алар үз авылларыннан астарак урнашкан бу сазлыкны ничек бетерергә белмәгәннәр. Озак уйлаганнан соң, алар үз авылларыннан башлап түбәнгә, аска таба ат белән сукалап, бер ерганак ясап төшкәннәр. Тора-бара ул ерганак елгага

әверелеп, авылны Югары оч һәм Түбән очка бүлеп аккан. Бу хәл татарлар килеп утырганчы булган, дип сөйлиләр. Елганың башланган җирендә зур чокыр барлыкка килгән, аның озынлыгы берничә метр чамасы булып, ул урынны Чокыр башы дип йөртә башлаганнар. Анда су аз, ләкин вак чишмәләр чыгып тора. Андагы печәнлек җирләргә, җиләкләргә, мәтрүшкә үсә торган урыннарга сокланмый мөмкин түгел.

Моннан ерак та түгел, авылның Питомнигы булган. Аның барлыкка килү тарихы болай: Татарстан Республикасының атказанган укытучысы Хәким ага Гыйльмуллин җитәкчелегендәге башлангыч мәктәп бакчасы ямь-яшел агачларга төренеп, авылга ямь биреп утырган. Анда җиләк-җимеш агачлары да, яшелчәләр дә үстерелгән. Балалар хезмәткә өйрәнгәннәр, тәҗрибә алганнар. Бакчаның кереме дә шактый булган. 1948 елда Хәким ага, мәктәптә генә түгел, колхозда да җиләк-җимеш бакчасы булдыру буенча эш башлый. Элек әрем үсеп утырган бер урынга колхозчылар һәм укучылар көче белән 500 төп карлыган куагы утыртыла.

1949 елда ул газетада «Авылларны җимеш бакчалары белән чолгап алыйк» исеме астында укучыларга ачык хат рәвешендә мөрәҗәгать белән чыга: «Ун елдан артык инде мин үз хуҗалыгымда бакчачылык белән шөгыльләнәм. Бу эштә минем шактый тәҗрибәм бар… Минем зур булмаган бакчамда хәзер Мичурин сортларыннан 3 төрле карлыган, 2 төрле кура җиләге, берничә төр алмагач, ике кара җимеш һ.б. төр агачлар бар. Алар ел саен күп кенә җимеш бирәләр. Мин үз тәҗрибәмне башкаларга бирергә, бигрәк тә колхоз бакчачылыгын оештыруда файдаланырга тырышам. Узган көз үз бакчамнан 100 төп җиләк-җимеш үсентесе биреп, колхозда җимеш бакчасы оештырдык. Башка урыннардан да байтак кына үсенте табып, колхозда 4 гектар җимеш бакчасы булдырдык. Анда 3 мең төптән артык төрле җимеш агачлары утырттык. Быел яз көне 7 мең төп карлыган, 5 мең төп кура җиләге утыртылачак. Балалар көче белән колхоз бакчасына 300 төп агач утырттык, 6 тонна көл җыйнап тапшырдык. Колхозчылар арасында аңлату эшләрен уңышлы алып бару нәтиҗәсендә, кыр ышыклау полосалары утыртуда хәзерлек эше яхшы үткәрелә. Агач утыртылачак ике гектар җир көздән тирән итеп сөреп калынды. Питомник өчен участок билгеләнде һәм минераль ашламалар хәзерләнде. Агач орлыклары хәзерләү уңышлы бара. 300 килограмм нарат күркәсе җыелды. Кыр ышыклау урман

полосалары утыртуга хәзерлектә мәктәп коллективларының колхозларга эшлекле ярдәмен булдырыйк. Шулай ук һәрбер авылда җимеш бакчалары оештыру эшендә булышлык күрсәтик. Безнең авыллар җимеш бакчалары белән чолгап алынсын!»

1961 елда бакчада 2 мең төп алмагач, 8 мең төп карлыган һәм күп кенә башка төрле җиләк-җимеш агачлары утырталар. 9 гектар җир биләгән бу бакча гөрләп үсеп китә, аның питомнигыннан башка колхозлар һәм хәтта чит районнардан да агач үсентеләре килеп ала башлыйлар.

Питомник авылның горурлыгына әверелә. Читендә генә базы да булган. Аны «җиләк-җимеш базы» яки «җиләк-җимеш склады» дип йөрткәннәр. Өлгергән җиләк-җимешне эшкәрткәнче, сатканчы шунда саклаганнар. Хәким ага вафат булгач, питомник та беткән һәм еллар узу белән кыргый бер урманлыкка әйләнгән.

Авыл янындагы тагын бер урын турында халык шактый гыйбрәтле вакыйга сөйли. Бу урын Шәмәрдән бистәсе ягыннан килгәндә хәзерге асфальт юлдан уң якта, 5 метр чамасы читтәрәк. Анда 3 колачлы ялгыз нарат утырган. Бу нарат зур һәм нык булган. Еллар үтү белән ул корыган, бер ботагы гына яшел килеш калган. Тора-бара ул ботак та корый, ләкин нарат һаман авып төшмәгән. Аның куркыныч исеме дә бар. Халык аны «Сихерле нарат» дип йөри. Нарат күп еллар авылның маягы булып торган, кешеләр, буранда адашканда, аңа карап юнәлеш билгеләгәннәр. Ләкин авыл халкы наратның үзе янына ук барырга курыккан. Әле биш-ун ел элек кенә нарат ауган һәм аны яндырганнар.

Авыл халкы телендә Сихерле нарат турында төрле имеш-мимешләр дә йөри. Имештер, наратны яндыручы кеше бригадир Ильяс абзый аның ботакларын өенә алып кайткан икән дә, төнлә кемдер тәрәзә шакып: «Китереп куй!» – дигән ди.

Аерым урыннарның исем-атамалары шәхес исемнәренә нисбәтле рәвештә барлыкка килгән: Мулла борыны (печәнлек җир), Мокми басмасы, Сәрби күпере, Чәпәй күпере, Чәпәй бөясе, Апчи коесы һ.б. Басма һәм күперләр түбән һәм югары мәхәлләләр арасыннан ага торган елга аша салынган. Әле дә халыкка хезмәт итәләр.

Югары очның бер урамы башында Чәпәй бөясе бар. Ни өчен аны бөя дип йөртәләр? Авыл уртасындагы елганы бүлеп юл салынган, су шунда бөялеп тора. Бөя бик тирән. Үрдәк-казлар анда җәй буена рәхәтләнә.

Мөхим таллыгының да үз тарихы бар. Элек Мөхим исемле кеше үзенең бакчасы артында Бөре елгасының ярын киртәләп ала. Анда күп төрле агачлар (бигрәк тә тал) үсә. Мөхим карт анда беркемне дә кертмәгән, нык саклаган. Бу абзый хәзер үзе мәрхүм, әтисе бүлеп алган агачлык аның улы Фәрит кулында.

Уенлык исеме алган урын да игътибарга лаек. Бөре елгасы янындагы чирәмле болынлык ул. Бик күп гореф-гадәтләрне саклаган, яшьләрне кавыштырган изге урын бу Уенлык. Элек анда язгы-җәйге кичләрдә уеннар бик еш оештырылган. Хәзер инде Уенлыкка җыелу онытылып бара…

Авыл халкы төрле кәсеп белән шөгыльләнгән. 1932–1934 елларда авылда зур таш бина салып, анда «Артель» ачканнар. Аны икенче төрле «Тун, бүрек артеле» дип тә атаганнар. Бу артельдә, тире эшкәртеп, толыплар, бүрекләр теккәннәр, бияләй һәм телогрейкалар да җитештерелгән. Тире әчетергә суны Бөредән хатын-кызлар ташыган. Тирене атлар белән Казаннан да алып кайтканнар. Әзер әйберне күрше авылларга сатканнар.

Сугыш елларында «Артель»дә эштә хатын-кызлар гына кала. Аларның җитештергән әйберләре турыдан-туры фронтка озатылган.

Авыл хатын-кызлары шәл бәйләргә дә оста булганнар. Бүлилене икенче төрле «шәлчеләр авылы» дип тә йөрткәннәр.

Сугышка алынган ир-егетләрнең күбесе әйләнеп кайтмаган. 1975 елда шулар хөрмәтенә авыл уртасына һәйкәл куела. Анда үлгән сугышчыларның исеме, фамилиясе язылган. Һәйкәлне ел саен төзекләндереп торалар.

Бүлиледә элек ике мәчет эшләгән. Берсе – Югары очта, икенчесе Түбән очта. 1930 елларда мәчетләрне сүткәннәр. Түбән очтагы мәчет урынына зират ясаганнар. Аны «Түбән оч зираты» дип атаганнар. Югары очтагы мәчет урынында да, шулай ук, зират ачканнар. Анысын «Югары оч зираты» дип йөрткәннәр. Ике зират та киртәләп алынган. Бу мәңгелек йорт авыл кешеләренең игътибар үзәгендә.

Авыл уртасына халык көче белән матур мәчет салып куелган. Аны төзүгә авылда туып-үскән экстрасенс Рәфыйк Миңнекәй дә матди яктан ярдәм иткән. Картлар да, яшьләр дә мәчеткә бик теләп йөри.

Хәзер авыл зур. Йортлар төзек, матур итеп буялган. Авылда башлангыч мәктәп, медпункт, клуб, китапханә, кибет эшли. Шулай ук ике җирдә шәхси кибет тә бар. Авыл кырыннан асфальт юл үтә.

Ялгыз әби-бабаларны халык онытмый. Аларга җирле үзидарә матди яктан булышып тора, мәктәп укучылары да өй эшләренә ярдәм итә. Авылдан картлар йортына җибәрелгән карт-карчыклар юк.

Бүлиледә борынгыдан сакланып килгән гореф-гадәтләргә, йолаларга һәм традицияләргә ихтирам зур. «Нәүруз», «Сөмбелә», «Каз өмәсе» бәйрәмнәре үткәрелә. Халкыбызның күңел бизәкләрен, осталыгын күрсәтү максатыннан башка төрле кичәләр дә оештырыла. Авыл эшчәннәренең хезмәтен зурлап та кичәләр үткәрелә, алдынгыларга бүләкләр бирелә.

## Зур Кукмара авылы

Зур Кукмара авылы район үзәге Кукмара эшчеләр бистәсеннән 3 чакрымда, Нократ Аланыннан 14 чакрым ераклыкта урнашкан.

Зур Кукмара авылы тарихи белешмәләрдә еш искә алына.

А. Артемьев нәширлегендә бастырып чыгарылган белешмәдә (ул 1859 ел мәгълүматларын эченә ала) күрсәтелгәнчә, Норма суы ярына урнашкан Зур Кукмара авылының 99 хуҗалыгында 370 ир-ат һәм 411 хатын-кыз яшәгән. 1898 елда басылып чыккан белешмә мәгълүматларына караганда, Зур Кукмара авылында татарлар көн күргән.

Авыл матур һәм уңайлы җиргә утырган. Авыл каршында тау, тау астыннан, авылны буеннан-буена иңләп, Норма суы ага. Норма елгасына чишмәләрдән җыелган инеш кушыла. Быргы чишмәсенең тарихы кызыклы гына икән. Инкыйлабка кадәр солдат хезмәте 25 елга сузылган. Егетләр 20 яшьтә китеп, 45 яшьтә генә кайтканнар. Ялга кайткан солдатларны халык зурлап каршылаган, өй саен кунакка йөрткәннәр. Кайткан солдатлар шул инеш буенда, ямь-яшел чирәмлектә быргылар кычкыртып ял итеп ятканнар. Шуннан соң халык ул инешне Быргы инеше дип атый башлаган. Авыл уртасыннан тагын бер инеш ага, ул да чишмәләрдән җыйналган. Аның башланган урынын Солдат болыны дип атыйлар. 25 ел хезмәт иткән солдатларның гаиләләренә шушы болынны бүлеп, печән чабарга рөхсәт иткәннәр.

Зур Кукмарага якын гына район үзәге – Кукмара эшчеләр бистәсе утырган. Хәзер яңа өйләр күп салына, бу ике торак пунктны кушылып ук беткән дияргә мөмкин. Район үзәге шулай ук тау итәгенә урнашкан. Тау башлары нарат, чыршы агачлары белән капланган. Әле 20–25 еллар элек кенә берни үсмәгән таулар өстендә 1 нче, 2 нче номерлы мәктәп укучылары, итек фабрикасы һәм тегү фабрикасы эшчеләре тырышлыгы белән урман күтәрелеп киткән.

Зур Кукмара элек район үзәге саналган Кукмарадан зуррак булган, шуңа да аны Зур Кукмара дип йөрткәннәр. Ул хәзер дә үсүен дәвам итә. Бер яктан ул Кукмара эшчеләр бистәсенә барып тоташа, икенче яктан күрше Рудник авылына кадәр киңәйгән. Элек авылның ике ягында бәрәңге, чөгендер басулары булган, хәзерге вакытта бу басу җирләрендә яңа хуҗалыклар барлыкка килгән, чөнки соңгы вакытларда авылга күчеп килүчеләр саны арта бара.

Элек авылда мәктәп сигезьеллык кына булган. Укучылар урта белемне Кукмара эшчеләр бистәсенә йөреп, 1 нче номерлы урта мәктәптә алганнар. Хәзер үз авылларында урта мәктәп бар. Авылда ике урында балалар бакчасы эшли. Мәдәният йорты, элемтә үзәге, китапханә бар.

Авыл уртасында яңа мәчет балкып утыра. Мәчеткә йөрүчеләр елдан-ел арта бара.

Авыл халкы бик тырыш һәм эшчән. Тормышлары нык. Дус яшиләр. Бу авыл халкы кәсепле, вакытны бушка үткәрми. Авылның киләчәге өметле.

## Зур Сәрдек авылы

Зур Сәрдек авылы район үзәге Кукмара эшчеләр бистәсеннән 20 чакрымда, Нократ Аланыннан 29 чакрым ераклыкта урнашкан.

Нәҗия Борһанова мәгълүматларына караганда, Зур Сәрдек авылы халкы күршедәге Адай, Купка, Аш-Буҗи, Сәрдекбаш, Уразай, Кара Елга, Олыяз, Югары Казаклар, Түбән Казаклар авыллары белән Яссы болын җыенын бәйрәм иткәннәр. Ул июнь башында үткәрелгән.

Зур Сәрдек авылының утырган урыны матур. Авыл уртасыннан, бормаланып-бормаланып, Сәрдек инеше ага. Ул суын авылның икенче очындагы Бөре елгасына коя.

Олылар сөйләвенә караганда, элек авыл утырган җирләр ылыслы урман белән капланган булган. Иген игү өчен җирне халык урманнан чистартып әзерләгән.

Авыл халкының төп кәсебе игенчелек һәм терлекчелек булган. Шул ук вакытта авылда һәм аның тирәсендә сәнәгать предприятиеләренең беренче чаткылары үсеп чыга. XIX гасырның 20 нче елларында авыл тирәсендә бакыр чыгару шахталары эшли. Ләкин, бакыр ятмалары аз булу сәбәпле, бу төр сәнәгать үсеп китә алмый. Дөрес, кустарь юл белән бакыр чыгару әле шактый дәвам итә.

XIX гасыр ахырларында Шаһи исемле байларның кытат (туку) фабрикасы эшли. Фабрика Зур Сәрдек һәм Чишмәбаш (элек бу авыл Коллар авылы дип аталган) авыллары арасында урнашкан була. Бу үзәнлек халык телендә Фабрика чокыры дип йөртелә. Хәзер ул чокыр урынында плотина төзелгән. Кытат фабрикасы мануфактура тибында булып, мамык җептән ситсалар эшләп чыгарган. Әмма фабрика үсеп китә алмый. Фабриканың эше тукталу сәбәбе кирәкле чималның үзләрендә булмавы белән бәйле. XX гасыр башында фабрика яшәүдән туктый, аның хуҗалары Казанга күчеп китәләр. Бакыр шахталарында һәм кытат фабрикасында авыл крестьяннары ялланып эшләгән. Авыл халкы алпавыт крестьяннары булмыйча, казна крестьяннары исәпләнгән.

1876 елгы хисап алу мәгълүматлары буенча, Зур Сәрдектә 206 хуҗалык булып, аларда 1448 кеше яшәгән. Шулар арасында 732 ир-ат, 716 хатын-кыз көн күргән. Авылның җир мәйданы зур булган, басу чикләре 25 чакрымга җиткән. Күрәсең, аерым крестьян хуҗалыклары өчен ул вакыттагы техника белән ерактагы җирләрне эшкәртү кыен булгандыр. Шуның өчен крестьян хуҗалыкларының бер өлеше кечкенәрәк бистәләр (поселоклар) оештыралар. 1916–1918 елларда Яңа Сәрдек авылы, 1919–1920 елларда Салкын Чишмә авылы барлыкка килә. Күчеп утырулар 1929–1930 елларда да була. Бу елларда Каенлык, Бакчасарай, Алма-Ата авыллары барлыкка килә.

1917 елга кадәр үк авылда укый-яза белүчеләр була. Хат язарга кирәк булса, яза белүче кешене өйгә чакырып, хат язган өчен чәй эчертеп, сыйлап җибәрә торган булганнар. Русча адрес яздырыр өчен күрше Китәк авылына өяз идарәсендәге писергә барганнар. Адрес язуның бәясе 1 тиен торган.

Авылда мәдрәсә эшләгән. Ир балалар мулла өенә барып, мулладан яки хәлфәдән, кыз балалар абыстайдан сабак ала торган булганнар.

1912 елда авылда русча укыту өчен мәктәп ачыла. Шул мәктәптә укыган Сәүбән Сөләйманов сөйләвенә караганда, укыр өчен укучылар туплау зур кыенлыкларга очрый. Мәктәпкә мулла рөхсәте белән генә укырга керергә мөмкин була. Бу мәктәп 1914 елда ябыла.

Гражданнар сугышы башлангач, авылның сугышка яраклы кешеләре сугышта катнашалар. Авыл ярлыларыннан Рамазан Сафиуллин, Хәйретдин Бәдретдинов, агалы-энеле Габдулла һәм Хәбибулла

Хәлиуллиннар һ.б., үзләре теләп, фронтка китәләр һәм сугыш кырларында үлеп калалар. Авыл кешеләреннән Сәхип Мортазин һәм Хәким Хәмидуллин, гражданнар сугышында күрсәткән батырлыклары өчен, Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгәннәр. Сугышта бу авылдан 32 кеше үлеп кала.

1930 елның кышында Зур Сәрдек авылы кешеләре колхозга керә башлый.

Колхозны оештыруда 25 меңчеләрнең берсе саналган Ханнановның роле зур була. Башта 32 хуҗалык колхозга керә. Аларның җир эшкәртү кораллары һәм атлары берләштерелә. Беренче колхоз «Маяк» исемендә була. Колхоз рәисе итеп Фатыйх Шәрәфетдинов билгеләнә. Колхозчыларга авылга якынрак булган яхшы җирләр бирелә, кибеткә кайткан әйберләр дә иң беренче колхозчыларга сатыла. Шуңа да карамастан, колхозга керергә теләүчеләр саны аз була. Көчләп колхозга кертү эше башлана. Бу хәл крестьяннар арасында зур ризасызлык тудыра.

Соңыннан авылдагы барлык кешеләр дә колхозга кереп бетәләр. Колхозчыларның гомуми җыелышында Дәүли Фарукшин тарафыннан колхозның исемен «Сталин» дип үзгәртергә дигән тәкъдим кертелә һәм 1932 елдан колхоз «Сталин» исемен йөртә башлый. Рәисе итеп Хәниф Мостафин сайлана. 1932 елның 15 апрелендә идарәнең беренче җыелышы була. Җыелышта хисапчы итеп Харис Зарипов, хуҗалык эшләре мөдире булып Хәким Насибуллин, кырчылык бригадирына Хәким Шәйхетдинов, ат караучылар итеп Габдрахман Нуриев, Мөхәммәтгали Вәлиевләр билгеләнә.

Хәниф Мостафиннан соң колхоз рәисе булып Миңнемулла Гыйззәтуллин эшли. Бу вакытта нигездә колхозлашу тәмамлана, әмма колхозның хәле авыр була әле. Шул елларда колхозга 6 делянка агач бирелә. Ул агачтан 1931 елда 50 баш сыер һәм 50 баш бозау асрарлык ферма бинасы төзиләр. Сыерларны аңа хәтле, урын булмау сәбәпле, колхозчылар хуҗалыкларында тотканнар.

1933 елда авылда 200 баш өчен ат абзары һәм зур амбар салына. Колхозда 3 бригада оештырыла. Анда яшелчәчелек белән дә шөгыльләнәләр, кыяр, чөгендер, кишер һәм кәбестә үстерә башлыйлар. Шул елны яшелчәчелектән зур керем алына (1964 елга кадәр колхозда кошчылык фермасы да яшәп килә).

1934 елның язында колхозга йөк машинасы бирелә. Аны йөртү өчен Мөгыйн Вильданов белән Зәки Шәрифуллинны Чаллыда

шоферлар курсында укытып кайтаралар. Зәки абзый шушы машина белән Ватан сугышында катнаша. Яралангannan соң, машинасын санитар батальонына калдырып, ул авылга кайта.

1936 елның көзендә Янил авылында МТС оештырыла. Авылга беренче комбайн 1937 елда кайтарылган.

Элек мәдрәсә хезмәтен үтәгән бина 1929–1930 елларда уку йорты итеп үзгәртелә. Моңа кадәр ул аерым йортларда була. Уку йорты мөдире булып Рәҗәп Әминов эшли. 1932 елда мәчетне клуб итеп җайлаштыралар.

Авылда сабантуй бәйрәме көнендә сугыш башлана. Зур Сәрдеккә эвакуацияләнгән кешеләр күчеп килә башлый. Иң элек аларны югары мәктәп бинасына урнаштыралар, соңыннан йортларга тараталар.

Бөек Ватан сугышы елларында Зур Сәрдектән 134 кеше үлеп кала. Сугыш тәмамлануга 20 ел тулу уңае белән Зур Сәрдек урта мәктәбе каршында, алар истәлеген мәңгеләштерү йөзеннән, һәйкәл төзелә.

Сугыштан соң колхозның җитәкчесе булып Миңнемулла Гыйззәтуллин эшли. 1950 елларда вак артельләрне берләштерү башлана. 1953 елда «Динамо» колхозы (Чишмәбаш авылы) һәм «Сталин» исемендәге колхоз (Зур Сәрдек авылы) берләштерелә.

1951–1965 елларда игенчелек белән беррәттән терлекчелеккә дә зур игътибар бирелә. Товарлыклы-сөтчелек фермасын Бәдретдин Гайфетдинов җитәкли. Фермада эшләр механикалаштырыла башлый.

Авыл янынннан Бөре суы ага. Күкле елганың хәзер суы юк. Бу төбәктә тагын Сәрдек, Чишмәле елгалары бар. Чишмәләрдән Корбанай һәм Рәҗәп чишмәләрен атарга мөмкин.

1915 елда авылда 3 тегермән эшләгән. Аның икесе Бөре елгасында, ә берсе Сәрдек суында урнашкан булган. Бөре елгасындагы тегермәннәрнең хуҗасы Василий исемле рус кешесе була. Бу тегермәннәрне халык Бачарка дип йөрткән. Күрәсең, алар Василий исемен шулай үзгәрткәннәрдер. Инкыйлабтан соң байларның малмөлкәте тартып алына, үзләре куыла. Шулар белән бергә Василий дә авылдан китәргә мәҗбүр була. Ул, бик олы яшьтә булганлыктан, авылда гына яшәп калырга рөхсәт сораган, ләкин аны барыбер җибәргәннәр. Василийның энесе Сәрдек суында тегермән төзи, ләкин язгы ташу бу тегермәнне алып китә. Аны халык Сәнкә тегермәне дип йөрткән. Шулай итеп авылда бер генә тегермән кала. Колхозлашу елларында тегермәнне колхоз ала һәм әйбәтләп төзәтә.

Ләкин сугыш елларында ул эшләүдән туктый. Сугыштан соң Миңлемулла һәм Мөхлис исемле кешеләр бу тегермәнне яңадан торгызалар.

Сугыш елларында исә тимерче Шәрәфи кул тегермәне ясый. Халык шуннан файдалана.

Зур Сәрдек тирәсе төрле урын атамаларына да бай: Озак тау, Туркай тавы, Чишмә тавы һ.б.; Бачарка болыны, Карлыган бакчасы, Кортлык (авыл кырыендагы куаклык), Ләндереш болыны, Мари зираты, Тамак (Бөре һәм Сәрдек елгалары кушылган урын), Тау басуы, Фабрика күпере, Фабрика чокыры, Шәйхи уелдыгы (Бөре елгасының бер уелдыгы), Югары басу, Җиңү паркы һ.б.

Хәзерге вакытта Зур Сәрдек авылы районда зур авылларның берсе санала.

Районадагы ике гимназиянең берсе – Зур Сәрдектә (икенчесе – Кукмарада).

Авылда балалар бакчасы, мәдәният йорты, китапханә, элемтә үзәге, даруханә, фельдшер-акушерлык пункты халыкка хезмәт күрсәтә.

Элек авылда өч мәхәллә булган, дип сөйлиләр. Хәзер дә мәчет эшли.

Авыл халкы зиратны карап, чистартып тора. Авыл өлкәннәренә дә игътибар бар.

Зур Сәрдектә илкүләм танылган шәхесләрдән 1959–1979 елларда «Коммунизмга» колхозы рәисе булып эшләгән Камил Фаяз улы Шакиров исеме һәркемгә таныш. Ул Социалистик Хезмәт герое, 1966–1970 елларда СССР Югары Советы депутаты булган. Хатыны Фәния ханым белән алар бер кыз, өч ул тәрбияләп үстергәннәр. Бер уллары – Наил Камил улы – Кукмара районы хакимияте башлыгы булып эшләгән. Илдар исемлесе – «Игенче» күмәк хуҗалыгы рәисе вазифасын башкарган, ләкин вакытсыз вафат булган. Шамил исә эшкуар. Кызлары Дания – укытучы булып эшли.

Чаңгычы Ания Галимуллина да шушы авыл чирәмендә уйнап үскән, Казанда университет тәмамлаган. Ул – Финляндия һәм Швециядә Европа беренчелегенә үткәрелгән чаңгы ярышларында катнашып, алгы урыннарны яулаган спортчы.

Гаян ага Әхмәтшин – куллары алтын шәхесләрнең берсе. Сугыш елларында ул, әсирлеккә төшеп, Франция һәм Германия җирләрендә эшләгән. Котылып кайткач, озак кына төрмәдә утыра, күп еллар буе Зур Сәрдек мәктәбендә хезмәт дәресләре укыта.

Европа халыкларының (француз, инглиз, немец һ.б.) телләрен әйбәт белә.

Әнә шундый эшчән, булдыклы Сәрдек кешеләре. Берсеннән-берсе уңган балта осталары белән дә дан тота бу як.

## Купка авылы

Купка авылы район үзәге Кукмара эшчеләр бистәсеннән 16 чакрымда, җирле үзидарә советы үзәге Зур Сәрдек авылыннан – 2, Нократ Аланыннан 26 чакрым ераклыкта урнашкан.

Купка авылы элек тау итәгендә утырган. Шул тирәдән Казан юлы үткән. Юлаучылар халыкка зыян салып, әйберләрен талап һәм урлап китә торган булганнар. Авыл халкы, җыелышып уйлашканнан соң, бу урынны ташлап, тау башына күченә. Тау астыннан кубып, тау башына утырганга күрә, авыл «купкан» сүзеннән Купка атамасы алган, дип сөйлиләр. Бу, билгеле, халык этимологиясенә кайтып кала.

Авыл халкы туй мәҗлесләрендә:

Ай Наласа, Наласа,
Наласаны су баса.
Купканы да басар иде,
Тау башында булмаса, –

дип җырлый.

Авылдан ерак түгел Бөре елгасы ага. Елга Бөртамак авылы янында Нократка кушыла. Купка ягында тагын Балык күле, Апач сазлыгы, Хәли чишмәсе, Әхмәдулла коесы, Зиннур чишмәсе бар. Авылдан бераз читтәрәк яшь урманнар шаулап утыра.

Авыл балалары, башлангыч белем алганнан соң, урта белем алу өчен Зур Сәрдек авылына баралар. Алар үзләренә йөрер өчен кыскарак юл салганнар. Шулай итеп, халык телендә яңа атама – Укучылар юлы кулланыла башлый.

Авыл янында Иске зират һәм Яңа зират бар. Иске зират авылдан 1,5 чакрымда читтәрәк урнашкан булган. Хәзер бу урынны халык койма белән уратып алган. Яңа зират исә авыл уртасында. Тирәсе киртә белән тотып алынган. Мәетләрне күмәр өчен махсус әсбаплар куеп торырга кечкенә генә өй дә салып куйганнар.

Авылда мәчет төзелгән. Мәчеткә картлар гына түгел, урта яшьтәге ир-атлар һәм укучы балалар да йөри. Авыл хаклы иманга йөз белән борылган.

Авылда башлангыч мәктәп, клуб, китапханә, кибет һәм балалар бакчасы эшли.

Халык үзәкләштерелгән газ яга, хуҗалыкларның күбесенә су кертелгән, юлларга асфальт түшәлгән.

Авылда яши торган өлкән буын вәкилләренә игътибар зур.

## Мәмәшир авылы

Мәмәшир авылы Кукмара эшчеләр бистәсеннән 32 чакрымда, Нократ Аланыннан 22 чакрым ераклыкта урнашкан.

Археограф Һ.В. Йосыпов авыл зиратында XVII йөзгә мөнәсәбәтле кабер ташларына тап булган.

Наҗия апа Борһанова мәгълүматларына караганда, бу авыл халкы күршедәге Салкын Чишмә авылы белән бергә июнь ахырында Мәмәшир җыены үткәрә торган булган.

Мәмәшир авылына кайчан нигез салынуы анык кына билгеле түгел. 1929 елда авылда көчле янгын булган, дин әһелләре алып барган елъязма тарих шунда юкка чыккан.

Авыл өлкәннәре сөйләве буенча, Мәмәшир авылы урыны элек тоташ урман белән капланган булган. Казан ханлыгы Явыз Иван тарафыннан тез чүктерелгән заманнарда, ат урлауда гаепләнеп хөкемгә тартылган, ләкин качарга өлгергән Томакай исемле бер кеше, гаиләсен алып, шушы урынга килеп урнаша.

Идел, Кама елгалары буйлап элекке Болгар якларыннан бу тирәләргә тагын бер кеше килеп чыга. Аны Болгар бабай дип атыйлар. Болгар бабайның урнашкан урыны Томакай бабай алачыгыннан ерак булмый.

Елганың каршы як ярына гаиләсе белән Мөхәммәтшәриф исемле кеше килеп урнаша. Торган җирләренең арасы ерак булмаса да, бу өч кеше бер-берсен белмиләр.

Язгы көннәрнең берсендә, елга ташыган чагында, Болгар бабай судан агып килүче йомычкалар күрә, урман эченнән күтәрелгән төтенгә дә игътибар итә. Бөре елгасы буенча көймә белән өскә таба, төтен тарафына менеп китә. Агымга каршы бераз йөзгәч, ярга чыга һәм Мөхәммәтшәриф гаиләсен таба. Күрешеп-сөйләшкәч, Мөхәммәтшәриф йомычкаларның югарыдан агып килүен әйтә. Алар киңәш-табыш итәләр һәм якын-тирәдә башка кешеләр дә яшәргә тиеш, дигән нәтиҗәгә киләләр. Болгар бабай көймәсендә алар икәүләп

елга буйлап тагын бераз күтәреләләр. Алар хәзерге Мәмәширнең Түбән оч урамында качкын Томакайның җирне казып ясаган куышын табалар. Куе, кара урман арасында ялгыз яшәү куркыныч булганга, болар берләшергә уйлыйлар. Томакай бабай урынын яшәү өчен уңайлы дип табалар. Мөхәммәтшәриф һәм Болгар бабай гаиләләре белән шушы урынга күчеп киләләр. Авылга шулай нигез салына. Мөхәммәтшәриф зиһене, үткенлеге, сүзгә тапкырлыгы белән башкалардан аерылып торган. Шуңа күрә авылны аның исеме белән атаганнар. Мөхәммәтшәриф исеме җыйнаклана, кыскара торгач, авыл атамасы Мәмәширгә әйләнә.

Мәмәшир авылы җирләре өч яктан Киров өлкәсенә уелып кереп утырган. Авыл янындагы болынның уң ягында Бөре елгасы ага. Бөренең теге як ярында Киров өлкәсе башлана.

Бөре елгасы бормалана-бормалана тау тезмәләре итәген юып килә дә Нократка кушыла.

Авыл басуларында елга-инешләр, сазлык-баткаклыклар һәм күлләр дә бар. Дуңгыз елгасы Бөре суына кушыла. Дуңгыз фермасы яныннан акканга аны шулай атаганнар. Нократка тагын Бөдрә, Чирай, Шәрбән, Нәби, Аракы исемле вак инешләр коя. Түбән оч белән Югары очны аерып торучы елганы Усман елгасы дип атыйлар. Елга янындагы таллыкта, авыл кешеләре сөйләве буенча, Усман исемле качкын яшеренеп яткан. Усман елгасының бер тармагы Баткак исеме белән йөртелә. Авылны урталайга ярып инеш үтә. Бу инеш янындагы чишмәне Мир чишмәсе дип атыйлар. Бөтен авыл халкы чәйгә суны чишмәдән ала. Бөре суы бассейнында Кара бия сазы, Бака ерымы һ.б. сазлыклар һәм ерым-ерганаклар бар. Болында Иске инеш атамасы алган сусыз кечкенә генә елга, Кызыл яр, Тегермән бөясе (буа сүзен авыл халкы шулай атый), Яшелчә бөясе, Чирмеш агышы (агыш сүзе кечү мәгънәсендә кулланыла) бар.

Мәмәшир авылы шактый зур авыллардан санала. Анда күперләр дә күп. Югары оч күпере, Түбән оч белән Тау башы арасындагы күпер Шәмәй күпере дип йөртелә. Авыл таралып утырган, анда 9 урам исәпләнә: Югары оч, Түбән оч, Тау башы урамы, Аргы тау башы, Бирге тау башы, Яңа урам, Яшьләр урамы (халык аны Комгансызлар урамы дип тә атый), Аргы як (яисә Чукрак урам), Мәктәп урамы, Картлар урамы.

Бүгенге көндә Мәмәширдә урта мәктәп, ике катлы балалар бакчасы, зур гына китапханә, элемтә үзәге, кибет, медпункт эшли.

Авылда 1994 елда мәчет ачылган. Мәчет манарасы очындагы ай авылга иман нуры чәчә.

Авыл халкы электән килгән барлык йола-кануннарны һәм гореф-гадәтләрне дәвам итәргә тырыша. Сабан туе, каз өмәсе, кыш озату, өй туе, никах укыту, бәби туе кебек чаралар әле дә уздырыла. Соңгы елларда Яшьләр урамында Урам көне уздыру традициягә кереп киткән. Ул июль аенда билгеләп үтелә. Һәр хуҗалыкның ишек алдында матур итеп табын әзерләнә, олысы-яше, бала-чагасы бергә җыелып, күңел ачалар. Бу бәйрәмдә һәркем актив катнаша.

Мәмәширдә йортлар матур, халыкның тормышы әйбәт.

## Мәчкәрә авылы

Мәчкәрә авылы җирле үзидарә советыннан – 2 чакрымда, район үзәге Кукмара бистәсеннән 25 чакрым ераклыкта урнашкан. Ул Күкшел җирле үзидарә территориясендә утырган.

Мәчкәрә атамасы тарихи белешмәләрдә дә очрый. «Аграрный вопрос и крестьянское движение в Татарии XIX века» (М.-Л., 1936. с. 393–396) дигән чыганакта ул 1878 елның 26 ноябрь датасы белән искә алына. Авыл халкы үзләрен чукындырырга телиләр дигән хәбәр ишетә һәм шуңа ризасызлык йөзеннән баш күтәрә.

Мәчкәрә авылы Шиһабетдин Мәрҗани китабында искә алынган. Авыл турында галим кызыклы мәгълүматлар язып калдыра: «Мәчкәрә авылы – Ишман иле, дип йөртелгән, байларының һәм шәкертләренең күплеге ягыннан күренекле бер авыл. Бу нигездә ар халкыннан бер төркем урнашкан авыл булган. Бөрбашы авылыннан Ишмәт бине Туктаргали бине Көчек бине Тәбеҗ исемле кеше, хайваннары һәм йорт-җирләре белән авылдан читкә чыгып, утар ясап урнашкан. Бераздан соң ул Бөрбашында яшәүче Әшмәкә исемле кеше белән дошманлашып, шул Әшмәкәнең җәбер һәм хурлауларына түзә алмыйча, үз утарыннан бөтенләй күчеп, Мәчкәрәдә урнашкан. Бөрбашы авылына салган мәчетен сүтеп, Мәчкәрәгә күчергән. Бераздан соң Туймәҗ бине Туйкә исемле кеше ул мәчетне Бөрбашы авылына яңадан кайтарып, авыл халкына һәм имамнарына биргән. Бу мәчет хәзер дә мирас юлы белән имамнан имамга күчеп килә.

Өлкән бабалары Тәбеҗ, Бөре суы башында йорт һәм алачык салып, тимерчелек белән кәсеп итеп вафат булган. Хәзергә чаклы ул урыннан күмер, тимер калдыклары, иске дагалар чыга һәм Бөрбашы кешеләре аны «Йорт-елга» дип атыйлар. Ләкин ул елга

тирәсендә булган агачлар бетеп, суы корыгач, Тәбеҗнең улы Көчек ул урыннан ярты миль кадәрге җиргә – елганың югары агымы тирәсенә килеп йорт салган һәм аның янына кайбер авыллардан кешеләр күчеп килеп, шуннан Бөре авылы оешкан. Шуңа күрә ул авыл Россия хөкүмәте документларында әлеге Көчеккә мөнәсәбәттән исемләнә. Көчекнең углы Туктаргали Оренбург һәм Каргалы тирәләрендә сәүдә белән гомер итеп, 1669 елда вафат була һәм шушы авылның каберлегендә җирләнә. Каберлекнең уртасында, кабере өстенә исемен һәм вафат булу тарихын язган таш бар. Өч углыннан Мәмәт исемлесе Бөрбашында калып, авыл халкының күбрәге шул Мәмәт нәселеннән килә...

Ул авылның әле хәзер дә исән иске таш мәчетен 1791 елның азагында Габдулла бай төзетеп, 1793 елда анда беренче намаз укылган. Бу кеше үзе йөз яшькә якын яшәп, 1832 елда Мәчкәрә карьясында вафат булган. Җеназасын мелла Габдулла бине Яхъя укыган һәм шундагы каберлеккә җирләнгән. Анасы – Зөһрә исемле хатын. Мичән башы карьясеннән, анасы бабасы ягыннан Габдулла байга туган булган. Габдулла илнең олы байларыннан булып, дәүләтенең зурлыгы, юмартлыгы, гыйлем һәм дингә мәхәббәте, галимнәргә дуслыгы белән шөһрәт казанган. Яхшылык һәм изгелекләренең истәлеге итеп йөз иллеләп мәчет салдыралар, дип сөйлиләр. Монысын Алла үзе белә...».

Мәчкәрә авылындагы сәүдәгәр Н. Хәсәновның XIX йөздә салынган кечерәк кибете һәм шул ук йөздә салынган ике мәчет 2144, 2145, 2146 номерлары белән «Татарстан Республикасы: тарих һәм мәдәният һәйкәлләре» дип аталган китапта искә алына.

Атама буларак Мәчкәрә белән бер ояга тагын түбәндәге исем-атамаларны кертә алабыз. Мәшкәлә – Актай суының уң кушылдыгы, Спас районы җирләреннән ага. Лениногорск районында Мәчкәрә исемле елга бар. Ул – Дала Зәе елгасының сул кушылдыгы.

Мәчкәрә атамасын ничек аңлатырга?

Кайбер галимнәр бу атаманы фин-угыр телләреннән чыгып анализлыйлар.

Авыл һәм гидроним атамалары төрки этноним «маскар»га мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән. Татар теле диалектларында *ч-–с–ш* авазларының чиратлашуы табигый күренеш, мәсәлән: *чәч – сач, чишмә – сишмә – тишмә* һ.б. Урта диалект вәкилләрендә, бигрәк тә Казан арты төбәгендә яшәүче халык телендә, күп сүзләр-

дә *а–ә* авазлары параллель рәвештә кулланыла: *ачы – әче, акрын – әкрен, мачы – мәче* һ.б.

Тарихи әдәбиятта маскарлар дорбет кабиләләренең бер өлешен тәшкил иткән хотоннар ыруы булып исәпләнә. Галимнәр фикеренә караганда, төрки маскарларның бер өлеше көнбатышка таба күчеп килеп, казакъ халкы составына шушы исем белән кергән. Казакъларның Кече Жузында маскар этнонимы очрый. Бу этноним татарларда да билгеле. Катай ыруының бер тармагы шушы исемне йөртә. Ике борынгы кара-кытай авылы шушы исемне алган. Димәк, маскара кабиләләренең бер өлеше – казакъларга, икенчеләре – татарлар составына килеп кушылган.

Мәчкәрә – маскара атамасы төркиләр кайчандыр яшәгән һәм хәзер яши торган урыннарда шактый очрый. Чиләбе өлкәсендә Маскара суы бар. Мокша суы бассейнында да Маскара исемле елга билгеле. Күрәсең, бу атама да маскар этнонимына килеп тоташа.

Элек бай гаиләләр авылда 2–3 хуҗалык кына булсалар да, авылның барлык җир, су һәм урманнарына хуҗа булганнар. Иң зур җир хуҗасы Зәйнуллин Шакир авылның яхшы һәм уңдырышлы җирләрен үзендә тоткан.

Аның берүзендә барлык крестьяннар файдаланган кадәр җир булган. Ярлы крестьяннар Шакир байга юк кына хезмәт хакына эшләгәннәр.

Авылдагы атаклы байның икенчесе Үтәмешев булган. Ул үз кулында Нократ аръягындагы урманнарны, Мәчкәрә белән Тәмәй авыллары арасындагы болыннарны һәм Мәчкәрә тегермәне янындагы җирләрне тоткан. Мәчкәрә белән Тәмәй авыллары арасындагы Бөре елгасы буенда урнашкан кытат фабрикасына да Үтәмешевлар хуҗа булган. Бу фабрика Оренбургтагы сәүдәгәрләр өчен тукыма җитештергән. Әйләнә-тирә авыллардагы халык Үтәмешевләр фабрикасында эшләгән. Туку фабрикасы янында эрләү мануфактурасы да булган. Җеп эрләү өчен мамык Урта Азиядән китерелгән.

Авылда ике мәдрәсә эшләгән. Беренчесе Мәхмүдов дигән мулла мәдрәсәсе булган. Ул мәдрәсә «Мәхмүдия» дип аталган. Бу мәдрәсәдә якын-тирә авыллардагы мулла малайлары укыган. Мәдрәсә тәмамлаганнан соң алар үз авылларына яисә башка авылларда мулла булып эшләгәннәр.

Икенчесе Еникеев Нәҗип мулла мәдрәсәсе булган. Анда авылдагы хәллерәк кешеләрнең ир балалары укыган.

1914 елда башланган Герман сугышы авыл халкына зур бәхетсезлекләр китерә. Авыл халкы бу сугыш турында мондый җыр да чыгарган:

Мәчкәрә тавы башына
Кемдер яулык ташлаган,
Без бәхетсез балаларга
Герман сугыш башлаган.

Авылга гражданнар сугышы җилләре дә кагылып үтә. 1918 елда авылдан 5–6 чакрым ераклыктагы Яңа авыл янында, Нократ суы буенда сугышлар аеруча көчле була. Биредә Колчак гаскәрләренә каршы Азин дивизиясе сугыша. Ул тирәдәге окоплар хәзер дә саклана икән. Бу дивизиядә сугышкан солдатлар Мәчкәрә һәм Мәмәшир авылларында торганнар.

Бөре елгасы буе авылларында яшәүче крестьяннар Азин гаскәрләрен азык белән тәэмин иткәннәр, атлар биргәннәр. Мәчкәрә авылыннан гражданнар сугышында Исмәгыйль Кадыйров, Закир Ибраһимов, Исхак Кадыйров, Абдулла Зарипов, Мөхәммәтҗан Хафизов һ.б. катнашканнар.

Сугыш тәмамланганнан соң, авылларда совет хакимиятен ныгыту эшләре башлана. Мәчкәрә авылында бу эштә яңа оешкан комсомол комитетының роле зур булган.

Авылда комсомол оешмасы 1918 елда Малмыж өязе комсомол комитеты инструкторы Гаян Динмөхәммәтов тарафыннан төзелгән. Беренче комсомоллар булып Әхмәт Мәхмүтов, Гәрәй Вәлиев, Бакый Хәсәнев, Галимҗан Гыйльманов, Фатыйх Хәмзин, Касыйм Исхаков һ.б. саналалар.

Нигездә алар культура-агарту эшләрен башлап, оештырып йөргәннәр, спектакльләр куйганнар; концертлар бирү, әдәби кичәләр оештыру, укый-яза белмәүчеләрне укыту, аерым эшләрдә ярлылар комитетына булышу, авыл халкын газета-журналлар белән тәэмин итү, аңлату эшләре алып бару белән мәшгуль булганнар.

Гыйльминур апа Кадыйрова сөйләвенә караганда, балаларның барысын бергә җыеп, авылда беренче укыткан укытучы Вәлиева булган.

Авылда пионер оешмасы төзелү дә шушы вакытларга туры килә. Беренче пионерлардан булган укытучы Шамил Бакиров түбәндәгеләрне сөйләде. Пионер оешмасы авылда 1925 елда төзелә. Беренче тапкыр пионерга Шамил Бакиров, Мөбарәк Сәлахов, Тәс-

кирә Сәлахиева, Мәгъмүрә Исмәгыйлева, Харис Исхаков, Харис Сәлахиев, Минһаҗетдин Сабиров, Миңлемулла Әхмәдиев, Хәйретдин Баһавиев һ.б. кабул ителә.

Авылда күмәк хуҗалыклар оеша башлау 1929 елга туры килә. Иң беренче булып колхозга Ибраһим Фәттахов, Габделхак Вәисов, Габдрахман Хөсәенов һ.б. кергәннәр. 1930 елда колхозга урта хәлле крестьяннар берләшә һәм 1933 елда авыл тулысынча коллективлаша. Колхозның беренче рәисе итеп Габделхәй Мусин билгеләнә. Колхоз дүрт бригадага бүленгән. Беренче бригаданың бригадиры булып Габдрахман Хөсәенов эшли. Икенчесенеке – Габдрахман Хәсәнов, өченчесенеке – Хаҗи Галиев, дүртенчесенеке Габдулла Кадыйров була. Колхоз «Күргәзмә» дип аталган.

1937 елның 15 апрелендә Мәчкәрә авылына беренче трактор кайта. Соңрак трактор бригадасы да оеша.

1941 елда башланган Ватан сугышы авыл халкына зур кайгылар һәм авырлыклар китерә. Авылдагы иң таза һәм яшь, эшкә сәләтле кешеләрдән 155 кеше фронтка китә. Алар арасында хатын-кызлардан Мәгъмүрә Фазылҗанова, Шәмсия Шакирҗанова, Дәрига Әмирхановалар була. Авылның 80 нән артык кешесе сугыш кырыннан кире әйләнеп кайтмый.

Авыл матур урынга утырган. Халык телендә Унике чишмә дип аталган чишмәләрдән агып чыккан су Тарым инешен хасил итә. Бу инеш авылның көнчыгышындагы таулар, чокырлар арасыннан борыла-борыла ага. Авыл басуында Мотыйга чишмәсе бар. Аны шул исемдәге авыл хатыны тапкан булган. Мәки тавы янында элек Мәки исемле кеше качып яшәгән, дип сөйлиләр.

Галимә Наҗия Борһанова мәгълүматларына караганда, Мәчкәрә, Күкшел, Тәмәй һәм Чуллы авыллары халкы июнь ае уртасында Күкшел җыенын бәйрәм иткән.

Авылда мәктәп, медпункт, кибет, мәдәният йорты, элемтә үзәге, китапханә эшли.

Авыл зираты рәшәткә белән әйләндереп алынган, чистартылып һәм чүп-чардан арындырылып тора.

Авылда зыялы нәселләр дә яшәгән. Мондый нәселне дәвам итүчеләрнең берсе – Мәскәү шәһәрендә яши торган Рөстәм Үтәмешев. Ул Мәскәүдән авылларына еш кайтып йөри. Фәнни-практик конференцияләр үткәрә. Халык, якташлары белән һәрдаим аралаша.

Мәчкәрәдә Чыңгыз Айтматовның әнисе Нәгыймә апа туып үскән.

## Өлге авылы

Өлге авылы район үзәге Кукмарадан 6 чакрым ераклыкта, җирле үзидарә советы үзәге Манзарастан – 2 чакрым, Нократ Аланы пристаненнан 15 чакрым ераклыкта урнашкан.

Өлге атамасы тарихи чыганакларда һәм белешмәләрдә урын алган. Казан ханлыгы чоры авыл атамаларын исәпкә алган тарихи чыганакта Өлге авылы да теркәлгән. Д.А. Корсаков мәгълүматларына (1908) караганда, Өлге авылында 134 йомышлы татар яшәгән. Авыл Өлге суы ярына утырган. А. Артемьев авылны болай сурәтли: «Оштарма суы ярына утырган Өлге авылындагы 156 хуҗалыкта 563 ир-ат һәм 548 хатын-кыз гомер кичергән, мәчет эшләгән» (1866). И.А. Износков мәгълүматлары буенча авылда 577 ир-ат һәм 570 хатын-кыз көн күргән. 1898 елда басылып чыккан белешмәдә, авылда татарлар яшәгән, дип күрсәтелә. К.П. Берстель җыеп чыгарган тарихи белешмәдән (1908) күренгәнчә, Өлге авылында 1126 татар кешесе яшәгән.

Нажия Борһанова мәгълүматларына караганда, Өлге авылы халкы күршедәге Татар Кукмарасы, Манзарас, Кәчимир, Киндеркүл, Ташлы Елга, Пычак, Арпаяз, Камышлы, Байлангар, Каенсар һәм Иске Пенәгәр авыллары белән июньнең соңгы декадасында Өлге җыены үткәрә торган булган.

Өлкәннәр сөйләвенә караганда, авыл урыны башта куе урман, сазлык булган һәм озак еллар буена шулай сакланган. Тау буеннан Пугачев гаскәре узып киткәндә, саз өстенә бүрәнәләр салып үтеп чыкканнар.

Нократ Аланы ягында Өлге дип аталган авыл булган. Авыл янындагы суда зур тегермән эшләгән. Анда яшәүче марилар хәзерге Өлге авылына килеп утырганнар. Аннары бирегә әкренләп татарлар да килеп урнаша башлаганнар. Татарлар белән марилар арасында еш кына ызгыш-сугышлар да килеп чыккан. Ахырда татарлар бу урынга үзләре хуҗа булып калганнар, дип сөйлиләр.

Авылда кием өлгеләре кисүчеләр күп яшәгән. Аларга башка авыл кешеләре кием өлгесенә килә торган булганнар. Шуның өчен авылга исемне дә Өлге дип биргәннәр имеш.

1930 елда авылда зур янгын чыккан һәм 70 ләп йорт янып беткән. Авыл оешу турындагы риваятьләр, күп кенә истәлекләр язылган дәфтәрләр шул вакытта юкка чыккан.

Авыл крестьяннары, сугышып, Өркеш, Комар һәм Камышлы арасындагы җирләрне яулап алганнар. Шул җирләргә барып иген чәчкәннәр. Бу чуалышларда Әбделгазим исемле кеше үзен батыр сугышчы итеп күрсәткән.

Өлге авылында байлар шактый булган. Аларның күбесе (аерым алганда, Әхмәтҗан, Саттар, Идият исемле һ.б. байлар) Казанга күчеп киткәннәр. Авылда Төхфәт, Хабулла, Җаббар, Гали һәм Сәпәх исемлеләре калган. Алар арасында иң бае Төхфәт булган. Ул биш тегермән тоткан. Байлар барысы да бер тирәдә яшәгәннәр. Алар яшәгән тыкрык Байлар тыкрыгы дип аталган.

Элек Өлге авылында Мәгәҗи келәте дип аталган урын булган. Бу Мәгәҗи келәтенә, ачлык була калса дип, халыктан ашлык җыйганнар. Уңыш яхшы булмаган елны икмәкне шуннан алганнар.

Авыл тирә-юнендә географик берәмлекләр шактый. Алар халыкка бик якын һәм үз.

Авылның нәкъ уртасыннан Оштарма суы ага. Элек аның суы мул булган, ярларыннан ташып аккан, хәзер исә бик саеккан инде.

Авыл башында зур гына бер күл бар. Халык аны Төхбәт күле дип йөртә. Чөнки элек бу күл Төхбәт байныкы саналган, ә халыкка күлдән балык тоту тыелган. Төхбәт бай шушы күлдән балык тотып сату иткән. Урлап балык тоткан кешегә бик каты җәза эләккән.

Югарыда күрсәтеп үтелгәнчә, авыл тирә-юне элек сазлыклы җир булган. Хәзер сазлык Төхбәт күле янында гына калган. Шунда ук Гали чишмәсе челтерәп ага. Хәзерге вакытта аны Салкын чишмә (яки Ерак чишмә) дип атыйлар. Чишмәне Гали атлы кеше карап һәм чис-тартып торган. Халык телендә шуңа ул күбрәк Гали чишмәсе дип йөртелә.

Таулар авылның тирә-ягын уратып алганнар. Бер тау исеме Чишмә сыңар дип атала. Бу тауда чишмәләр күп булган. Тора-бара чишмәләр кипкән һәм бер чокырда бары бер генә чишмә калган. Чишмә сыңар исеме шуннан килеп чыккан.

Авылда элек яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчасы булган. Халык бу бакчада күмәкләшеп эшләгән. Бакчаның хуҗасы, карап эшләтүчесе Бәдәр исемле хатын булган.

1921 елдан башлап дүрт сыйныфтан торган башлангыч белем бирү кертелә. Беренче мөгаллим Гобәй исемле кеше була.

1930 елда мәктәп волость идарәсе бинасына күчерелә. Бу бина, волостьлар бетерелеп, районнар оештырылгач, бушап калган. Аңа

зур үзгәрешләр кертелгән, бүлмәләрне сыйныф бүлмәләре итеп яраклаштырганнар. Ике сыйныф укучылары бер бүлмәдә укыган. Балаларны Зәки абый Гайнанов һәм Нәфисә апа Җиһаншина укыткан.

Урта мәктәп авылдан бер чакрым ераклыктагы Пычак авылында урнашкан. Авылда ике катлы балалар бакчасы төзелгән. Авылда мәдәният йорты бар. Өлгедә мәчет бар. Медпункт эшли. Авылга үзәкләштерелгән газ кергән. Юлларга асфальт түшәлгән.

Хәзерге вакытта Өлге авылында чама белән 131 хуҗалык исәпләнә. Яңа өйләр елдан-ел күбәя. Күп кешеләр, туган якларына кайтып, үзләренә нигез коралар.

Авыл урамнарының элекке исемнәре үзгәрмәгән. Тауга менеп карасаң, авыл биш почмак рәвешен хәтерләтә. Бер урам Кәчимир очы дип атала. Бу урамнан күршедәге Кәчимир авылына барырга җайлы. Завод очы урамыннан авыл халкы Кукмарага, заводка эшкә барган. Урамнан чыккач та, Кукмарага кадәр таш юл салынган булган. Камышлы очы урамыннан күршедәге Камышлы авылына барганнар. Дүртенче урам – Көек очы, бишенче урам Пычак очы дип атала. Бу урамнардан Көек һәм Пычак авылларына йөргәннәр.

Мәңгелек йорты – зират – койма белән тотып алынган. Аны елына бер чистартып, печәнен чабып, карап торалар. Каберләргә чардуган һәм ташлар куелган.

Өлге авылында элек-электән Зәрә бәйрәме үткәрелгән. Май ае керүгә бала-чагалар һәр өйгә кереп, чиләкләренә ярма, май, тоз һ.б. әйберләр җыеп йөргәннәр. Өйгә килеп керү белән такмаклар әйтеп, балаларча шаярып та алганнар.

Зәр, зәр зәрәки,
Иске, москы кәзәки,
Кәзәкигә ут капкан,
Бөтен авыл шаккаткан.

Яки:

Ай, диләр, вай, диләр,
Алма апаны «бай» диләр.

Бу такмакларны балаларга җор телле, шат күңелле Шәмсурый апа өйрәткән.

Ә икенче көнне балалар бәләкәй капчыклар тотып, кызарткан йомыркалар җыеп йөргәннәр.

Авыл халкы Каз өмәләрен, Сабантуй бәйрәмнәрен дә күңелле итеп үткәрә.

## Төркәш авылы

Төркәш авылы район үзәге Кукмара эшчеләр бистәсеннән 29 чакрым ераклыкта урнашкан.

Аның исеме тарихи чыганакларда һәм халык авыз иҗаты әсәрләрендә еш телгә алына.

XVIII йөзгә мөнәсәбәтле мәгълүматлар тупланган Д.А. Корсаков җыентыгында Төркәш авылында ясак түли торган 24 татар яшәве күрсәтелә. А. Артемьев Төркәш авылы турында түбәндәге мәгълүматларны китерә (1866): авылдагы 48 хуҗалыкта 169 ир-ат һәм 168 хатын-кыз көн күргән, бер мәчет һәм почта станциясе булган.

И.А. Износков Төркәш авылында (XIX йөздә) ислам динендәге 212 ир-ат һәм 227 хатын-кыз яшәгәнлеген күрсәтә. 1898 елгы китапта Төркәш авылында татарлар яшәгәнлеге искәртелә.

К.П. Берстель хезмәтендәге мәгълүматларга караганда (1908), Төркәш авылында барлыгы 758 татар исәпләнгән.

Диалектолог Нажия Борһанова мәгълүматлары күрсәтүенчә, Төркәш, Югары Арбаш, Түбән Арбаш, Шепшеңәр, Хәсән, Ямбулат авыллары халкы июнь ахырында Арбаш җыенын бәйрәм иткән.

Өлкәннәрнең кайберләре сөйләвенчә, бик борынгы заманнарда Юан елга дип аталган үзәннең очына берничә гаилә килеп урнашкан. Ләкин бу урында яшәү өчен иң кирәкле әйбер – су – таба алмаганнар. Бераздан алар үзәннең аскы өлешенә – елга буена – төшеп утырганнар. Авыл исемен Төркәш (теркәлү сүзеннән, дип уйлыйлар) дип атаганнар.

Икенчеләре исә болай сөйли: 1552 елда Мәскәү кенәзе Явыз Иван Казан ханлыгын яулап алганнан соң, күп халык, тынычлык эзләп, төрле төбәкләргә чыгып киткән. Төркәш авылы халкы да бу тирәләргә чукындыру сәясәтеннән качып килеп утырган һәм авыл оештырган. Дөрес, аларны монда да тапканнар, авыл халкы барыбер чукындырылган, ләкин барысы да яңадан исламга кире кайтканнар.

Төркәш сүзенең мәгънәсенә килгәндә, ул борынгы төрки кабилә-кавемнәре исеме «тюргеш»кә барып тоташа һәм ул авыл атамасы булып ныгып калган.

Авыл халкы иманлы, ислам диненә хас булган йола-кануннарны хөрмәт итә. Мондый традиция буыннан-буынга бирелә килгән.

Төркәш авылы ике тау арасына утырган. Бер як тау өстендә куе урман, ә икенче ягында Нырты авылы урнашкан.

Авылда һәм аның тирәсендә елга-инешләр, күлләр, сазлыклар, чишмә-кизләүләр, тау-калкулыклар һәм башка географик берәмлекләр шактый. Елгалардан Төркәш башы, Чәчкә, Шалкан асты, Юл кереше, Кабык юлы, Кызыл яр, Тегермән арты, Урта елга, Уракай, Биш имәнле, Кирәмәт, Мазар, Йөрәк, Йуан, Ташкискән, Чәкә куышы, Ялгыз чыршы исемен алганнарын атарга мөмкин.

Юан елганың киңәеп торган урта өлешен халык Уракай дип атый. Базар елгасын «серле елга» дип тә әйтәләр. Моннан бик күп еллар элек, халык сөйләвенә караганда, ачлыктан үлгән юлаучыларны шул елганың аскы өлеше ярына күмә торган булганнар. Ул кешеләрнең исемнәре дә, каян килеп кая барулары да билгеле булмаган. Шулай итеп, исемсез каберлекләр барлыкка килгән. Хәзер инде җирләр тигезләнгән, ләкин халык арасында әле дә, элек күмелгән кешеләрнең өрәкләре чыгып йөри, дигән сүзләр йөри. Әйтик, кышын да, җәен дә ап-ак сакаллы изге картның Базар елгасы яры буйлап менеп киткәнен күреп калучылар булгалый икән.

Авылның нәкъ уртасында, тау астыннан Насыйр бабай чишмәсе кайнап агып чыга. Аны Сәетгәрәй абзый карап һәм тәрбияләп торган. Чишмәне ул чын күңеленнән риза булып, моңлы тавыш белән җырлый-җырлый караган. Сәетгәрәй абзыйга бакый дөньяда да Кәүсәр, Зәгъфран чишмәләренең суларын эчәргә, шул чишмәләрне карап һәм тәрбияләп торырга насыйп булсын, дигән теләктә калабыз. Сәетгәрәй абзый вафат булганнан соң, чишмәне Әюп абзый тәрбияли башлаган. Туган ягына гашыйк булып яши торган Әюп абзый, гомумән, чишмәләрне аеруча яраткан.

Авылның түбән ягыннан Катыклы чишмә агып чыга. Элек кешеләр бу чишмә яныннан Тәкәнеш базарына катык сатарга йөри торган булганнар. Сусаганнары чишмә янына туктап, аның суын эчкәннәр, чөнки аның суы башка чишмәләрнеке белән чагыштырганда салкынрак булган.

Насыйр бабай чишмәсе яныннан тауга менеп китәсең. Бу тауны халык Кирәмәт тавы дип йөртә. Тау өстендәге урманның исеме Пуп урманы. Элек ул поп кулында булган. Урман буендагы басуны Кәрпи басуы дип йөртәләр. Бу басу кайчандыр Карпов фамилияле кеше милке булган икән.

Авылдан 4 чакрым ераклыкта зур буа бар. Кайбер урыннарда аның тирәнлеге 10 метрга җитә, дип сөйлиләр (анда су коенганда күрше Нырты авылыннан бер егет батып үлгән).

Авыл урманнарга бай, урман аркылы чыга торган юлларның да һәрберсенә исем кушылган. Кирәмәт үзәне тәмамланган урыннан урманга Кирәмәт сукмагы кереп китә. Аннан бирерәк килгәч, Тәмәке сукмагы, Каенлы юл һ.б.

Арт урам, Олы урам һәм Тау асты, Су буе урамнары халык күңеленә якын атамалар.

Авылда башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, балалар бакчасы бар. Юллар асфальтланган. Мәчет эшли.

## Уразай авылы

Уразай авылы район үзәге Кукмара эшчеләр бистәсеннән 26 чакрымда, җирле үзидарә советы үзәге Сәрдекбаш авылыннан – 2, Шәмәрдәннән – 19, Нократ Аланыннан 34 чакрым ераклыкта утырган.

Авылның тирә-ягында таулар, аларга менеп карасаң, авыл ярым ай рәвешендә күренеп тора. Аның икенче ягында зур иген басулары җәйрәп ята. Авыл уртасыннан Сәрдек суы ага. Ул Бөре елгасына килеп кушыла. Су буенда тал, зирек, шомырт агачлары үскән.

Олылар сөйләвенә караганда, Уразай авылына нигез салучы кеше Вилданов Ногман Вилдан улы булган. Ул 1889 елда гаиләсе белән монда килеп төпләнгән. Авыл әкренләп зурая башлаган.

Колхозлашу елларында башка авылларда булган хәлләр Уразайны да читләтеп үтмәгән. Соңыннан колхозлар эреләндерелгән һәм Уразай авылы колхозы күрше колхоз белән кушылган. Бу колхозга түбәндәге авыллар кергән: Уразай, Сәрдекбаш, Каенлык, Тырыш, Яңа Сәрдек, Бакчасарай, Кече Китәк, Югары Китәк. Дөньялар үзгәргәч, бу авыллар инвестор кулына күчкән («Бөре агрофермасы»на кергән). Идарәсе Зур Сәрдек авылында. Бу район авыллары «Татарстан-Вамин ААҖ» карамагында икән.

Уразай авылы халкы колхоз рәисе булып эшләгән Галимулла абзыйны бик сагынып искә ала. Ул үз эшен һәм халыкны да бик яратып эшләгән кеше була. Сәрдекбаш мәктәбенә аның исемен биргәннәр.

Элекке колхозның һәрбер авылына газ кергән, асфальт салынган. Авылларда яңа хуҗалык йортлары һәм җәмәгать корылмалары калкып чыккан. Болар исәбенә кибет, мәчет кебек корылмалар керә.

Авылда мәчет 1900 елда салынган була. Авылның мәчет манарасы киселмичә кала. Аны кисәргә кеше таба алмыйлар. Бер кеше дә

манара кисәргә риза булмый. 1987 елда авыл халкы мәчетне яңарта. Һәр җомга саен мәчеттән азан тавышлары ишетелеп тора.

Элек авылда мәдрәсә дә булган. Мулла дин сабагы укыткан. Соңрак Харрас абзый гарәп графикасын өйрәткән.

Авыл яныннан бик матур бер чишмә ага. Суыннан авыз итсәң, бөтен кайгы-хәсрәтләрең, сагыш һәм моңнарың бетә, диләр. Шул чишмәгә багышлап Уразай авылында яшәүче Наилә ханым мондый шигырь язган:

Авылымның тау битеннән
Чишмә ага җырлый-җырлый.
Сабый чаклар шунда үтте
Шул җырларны тыңлый-тыңлый.

Чишмәләрем, сездә минем
Яшьлегемнең үткән юлы.
Туган җирем яме сездә,
Әй, Сәрдекбаш чишмәләре,
Ялгыз гына бер моңланып
Яныгыздан үтәм әле…

Һәр яз саен авыл халкы, җыелып, зиратта өмә үткәрә. Корыган агачларны читкә чыгарып ягалар, иске яфракларны себереп, йә күмәләр, йә яндыралар. Мәрхүмнәрне күмү әсбаплары тәртиптә тотыла, алар чиста һәм пакь.

Авыл кешеләре урамнарны да чиста тоталар. Йортлар, каралты-куралар төзек, аларны гел яңартып торалар.

Йомгаклап шуны әйтергә мөмкин, Кукмара Республикабызның зур районы. Анда сәнәгать шактый алга киткән, традицияләр тирән катламнардан үсеп чыккан. Анда рухи дөньяга да зур игътибар бирелә. Төрле милләт халыклары яшәүгә карамастан, кукмаралылар бердәм гаилә булып, уртак максат куеп хезмәт итәләр. Алар эш сөючән, уңган һәм булган халык.

Районның матур яшәве хакимият, инвестор һәм халыкның дустанә, кулга-кул тотынып көн итүләре нәтиҗәсе. Кукмара шулай гомер итә.

## ТАРИХЫБЫЗ ТЕЛГӘ КИЛСӘ...

*Дария Рамазанова,*
*Миңнира Булатова*

Дөрес юлны табу өчен, безгә үзебезнең үткәнебезне, халыкның гүзәл йолаларын, гореф-гадәтләрен өйрәнергә кирәк. Фәкать алар гына безгә дөрес юлны табарга, халкыбызга нахак бәла ягучыларга дөрес җавап бирергә ярдәм итәчәк.

*Г. Бәширов*

Татарстанның Кукмара районы җиләк-җимешкә бай урман-болыннары, инеше, салкын сулы, челтерәп аккан чишмәләре булган гүзәл табигатьле җирдә урнашкан. Анда тел, рухи-мәдәни яктан та бай күңелле кешеләр яши. Әби-бабалары тапшырып калдырган йолаларны, гореф-гадәтләрне, безгә дә бик теләп сөйләделәр алар. Сәфәребезне нәтиҗәле башкарып чыгуда хуҗалык җитәкчеләренең, укытучыларның һәм мәдәният хезмәткәрләренең ярдәме аеруча зур булды.

Күпне күргән, күпне белгән информантлардан тыш, һәр авылның гади генә эшчәннәре да туган яклары турында әллә никадәр мәгълүмат җиткерделәр, сораганны көтеп тормыйча, белгәннәрен сөйләп бирделәр. Купка авылында зирәк, тырыш, гектарлап суган үстерүче Гыйльметдинов Илфат безне авыл белән таныштырып йөрде, үз төбәгенең кыскача тарихын аңлатты.

Экспедициядә катнашучыларга максатларын үтәүдә ярдәм иткән Насыйбуллина Фәридә, Насыйрова Гөлүсә, Галиева Нурия,

Гыйльфанова Рузия, Шәмсетдинов Заһидлар да авыллары тарихы, анда туган риваятьләр белән бәйле вакыйгалар турында бәйнә-бәйнә сөйләп бирделәр. Ерактан ук һәрбер авылны күркәмләндереп торган мәчетләрдән тыш, шушы якның табигатен җанландырып җибәргән чишмәләр белән таныштырдылар.

Кукмара районы изге тарихлы, шифалы сулы чишмәләргә аеруча бай икән. Изгеләр чишмәсе, Насыйр чишмәсе, Күз чишмәсе, Тау чишмәсе, Таңач, Чура тау асты чишмәсе һ.б. Тәннәргә дәрт, җаннарга сихәт, күңелгә дәва да бирә торган чишмәләренең суын татып карарга да насыйп булды. «Суыбыз тәмле дә, шифалы да безнең!» – диләр алар, бигрәк тә Күз чишмәсенә карата. Аның атамасы да күрмәгән күзләрнең ярыларын ачтырудан, якты нур кертүдән, диләр авыл халкы. Чишмәләр, матурлап, агач, йә таш коймалар белән уратып алынганнар. Бу чишмәләр халык тормышының истәлек-хатирәләре һәм олы тарихының шаһитләре дә булып торалар.

Кукмара ягының шушы изге чишмәләрдән су эчеп үскән кешеләре дә бик ягымлы. Шундыйлардан Кукмарада чыга торган «Хезмәт даны» газетасының баш мөхәррире Ризванов Рәсим Газиз улын әйтеп үтәргә кирәк. Көтмәгән авырлык килеп туган чакта, ул безгә дә тиз арада ярдәм кулын сузды. Кыска гына очрашу вакытында күп кенә темаларны кузгатты, әһәмиятле мәгълүматләр биреп өлгерде. Аның татар халкы, телебез, мәдәниятебез өчен җан атып йөрүчеләрнең берсе икәнен күрдек. Рәсим Газиз улы кызыксынучан, киң карашлы булу белән бергә, үзенең олы җанлы, изге күңелле зат икәнлегенә дә инандырды.

Кукмара төбәгендә туган ягының гүзәллеген шигырьләрендә, әсәрләрендә чагылдыра белгән үз язучылары да бар икән. Шуларның берсе – Ядегәр авылыннан Хәсәнова Сания Хәсән кызы – үзенең гаять бай һәм эчтәлекле хезмәт юлы узган ветеран-укытучы истәлекләрен «Гомерләр заяга узмаган» хезмәтендә яктырткан. С. Хәсәнова күренекле әдип Мөхәммәт Мәһдиев белән фикердәш, дус булган, аралашып яшәгән. Бу авыл халкы безне ипи-тоз белән каршы алып, гыйлем дөньясына аеруча игътибарлы булуын да раслады.

Кайбер авылларда безнең килүебезнең максаты, эшчәнлегебез белән аеруча нык кызыксындылар. Мәсәлән, Быжа авылында авылның бөтен әбиләре диярлек, безнең янга җыелып, авыл тормышының төрле яклары, күңел ачу төрләре һәм җирле йолалар ту-

рында түкми-чәчми сөйләделәр. Гарипова Факиябану борынгы ата-бабаларыбыз язмышын, мәдәниятен сөйләсә, Гыйльметдинова Әлфия, Усманова Наҗия, Гайнанова Разия «Авыл», «Урам», «Солдат», «Чимек», «Алмагач» көйләрен бергәләп җырлап яздырдылар, арада үткәннәрен дә искә төшереп алдылар. «Өздереп җырлыйдырыйк яшь чакта», диләр алар.

Зур Сәрдек мәктәбе директоры урынбасары Горохов Васил Ганс улы безгә яшәү мәсьәләләре буенча кулыннан килгәнчә ярдәм күрсәтте. Көн дә килеп, эшебезнең ничек баруы белән кызыксынды, үзенең нәсел шәҗәрәсе белән таныштырды, мәктәп, авыл тарихы турында әңгәмәләште, музеен күрсәтте.

Инде кукмаралыларның тел үзенчәлекләренә тукталып узыйк.

Кукмара төбәгенә хас сөйләшнең төп үзенчәлеге шунда, ул Казан артындагы балтач һәм мамадыш сөйләшләрен тоташтырып тора. Шуңа күрә андагы сөйләшләрдә, сирәк кенә булса да, аларның икесенә дә хас үзенчәлекләр табыла. Кукмара төбәге сөйләше үзе әдәби телгә бик якын.

## Фонетик үзенчәлекләр

Сузык авазлар кулланышында биредә түбәндәге күренешләр теркәлде:

*ә* авазы *и* сузыгына тәңгәлләшә: *әнкәй* – әни, *әтәй* – әти; *бәк* – бик.

Киресенчә, *и* авазы әдәби *ә* сузыгына тәңгәл килә: *пирәмәч* – пәрәмәч, *җийәү* – җәяү;

*э ~ и*: печ – мич; *чекләwек* – чикләвек;

*ә* төшеп калу: *тәрзә* – тәрәзә;

*ы/оу ~ у*: *йыwан* – юан, *соу* – су.

Аваз өстәлү: *эшәп* – шәп.

Тартык авазлар белән бәйле диалекталь күренешләр ешрак табыла.

Тартыкларның әйтелешләре әдәби телдәгечә. Шуның белән бергә, күпчелек татар сөйләшләренә хас булганча, алынма сүзләрдәге ят авазлар татар теленең үз авазлары белән алыштырылалар. Бу аеруча *х* һәм *ф* тартыкларына карый.

Мәсәлән, *ķ ~ х* күренеше түбәндәге сүзләрдә теркәлгән: *Ķәйрулла // Хәйрулла* – әд. Хәйрулла, *Ķәдичә* – Хәдичә, *Исķаķ* – Исхак, *ķәтле* – хәтле.

*п ~ ф*: *нәпселе* – әд. нәфселе, *Сапи* – Сафи, *Тайба* – Таифә, *Кәшипәттәй* – Кәшифә апа, *Пәтихәттәй* – Фатихә апа, *Апар* – Габделгаффар.

Кукмара төбәге сөйләшендә аерым сүзләрдә генә түбәндәге тәңгәллекләр очрый:

*п ~ м: пич* // *мич* – мич;

*й ~ л: чайқан* – чалкан;

*н ~ ң: күресен* – күрерсең, *беләсен* – беләсең; *белер ийен* – белер идең;

*т ~ ч; тишелү* – чишелү;

*ч ~ с: чийиршық* – сыерчык;

*х ~ қ: хиссә* – кыйсса;

*з ~ д: Изел* – Идел, *қазау* – кадау;

*к ~ т: уқмурт* – удмурт.

Аваз яки авазлар төшүнең мондый очраклары бар:

*р* авазы төшү төрле фигыль формаларында күзәтелә: *барысың* – барырсың, *урегә* – үрергә, *күресен* – күрерсең;

*н: асат* – ансат*; белә* // *белән* – белән;

*те: ишелә* – ишетелә;

*һ* (күбесенчә кеше исемнәрендә, сүз уртасында): *Җийанша* – Җиһанша, *Мийәчтин* – Минһаҗетдин.

Борынгы *г (> к)* саклану: *ыруқ* – ыру, нәсел.

*Г* авазы өстәлү күренеше теркәлгән: *җаңға* – яңа, *иңгелек* – иң элек, *берсеңгә* – берсенә;

*л* өстәлү: *хәсилтә* – хәситә;

*җ*-ләштерү: *дөнҗа* – дөнья, *Мәрҗәмбикә* – Мәрьямбикә; *җуборған* – юрган.

Түбәндәге очракларда авазлар охшашлана:

*ңл > ңн: сеңне < сеңле* – әд. сеңел;

*нб > мб: умбер* – унбер, *умбиш* – унбиш;

*нм > мб/мм: уқығамбыз* – укыганбыз, *төшөргәммен* – төшергәнмен, *туғаммын* – туганмын һ.б.;

*нг > ңг: урмаңға* – урманга, *белмәңгә* – белмәгәнгә;

*ч, с, ш* тартык авазына охшашлану түбәндәге сүзләрдә теркәлде: *шишмә* – әд. чишмә, *шыршы* – чыршы, *шишен* – чишен, *баршау* – чаршау; *шуғыш* – сугыш, *шүшилкә* – сушилка; *шишәмбе* – сишәмбе һ.б.

Охшашсызлану (диссимиляция): *алдапқыч* – алъяпкыч, *андары* – аннан ары (әд. – *аннан соң*).

## Грамматик үзенчәлекләр

Исемнәр. Кеше исемнәрен кыскартып сөйләү күренеше берникадәр саклана әле: *Сафи* – Сафиулла, *Ғәптри* – Габдрахман, *Ғыймади* – Гыймадулла, *Муллый* – Мулләхмәт, *Ғайфи* – Гайфетдин, *Ғати* – Гатиятулла һ.б.

Тартымлы исемнәрнең төшем килеше *-ы/-е* кушымчалары белән ясала: *эшләгәнеме* – эшләгәнемне, *күлмәгеңе* – күлмәгеңне.

Алмашлыкларның составы һәм төрләнешләре Кукмара төбәгендә, нигездә, әдәби телдәгечә. Алмашлыкларга икешәр тартым кушымчасы ялгану актив күзәтелә: *ансысы* – анысы, *монсосы* – монысы, *қайсысы* – кайсы. Мәсәлән: *Қыз сорарга қайсысы терерәк, йөрәклерәк, шул бара. Ансысы – Шүрәле җылғасы.*

Юнәлеш килешендә *мийә* – миңа, *аңар* – аңа формалары да бар.

Фигыльләрдә -*ган*/-*гән* кушымчалы үткән заман формасын тартымлы кушымчалар белән төрләндерү дә күзәтелә:

Мин *килгәнем* (әд. *килгәнмен*)
Син *килгәнең* (әд. *килгәнсең*)
Ул *килгән*
Без *килгәнебез (килгәнбез)*
Сез *килгәнегез (килгәнсез)*
Алар *килгәннәр*

*Да-дә, та-тә* ярдәмлек сүзләрен, мамадыш сөйләшенә хас булганча, *дағын–дәген, тағын–тәген* рәвешендә әйтү: *Без соң тордоқ тағын барып тормадық. Үзе дәген белмичә тора бит.*

Кукмара төбәгенең характерлы үзенчәлекләреннән берсе – -*кы*/ -*ке* кушымчасының сыйфат ясауда актив кулланылышы. Мәсәлән: Ғәдәтләрнең теге waхытқысын (вакыттагысын, вакытныкын) әйтәм мин. Төрткө (төрттерә торган) җырлар җырлый торған ийек. Мондый үзенчәлек пермь сөйләшендә дә билгеләнгән.

## Лексик үзенчәлекләр

Һәр төбәкнең үзенчәлекле сүзләре була. Тикшерә торган төбәктә дә андыйлар табылды. Сүзләрне тормыш-көнкүрешнең төрле тармаклары белән бәйләп карасаң, төбәккә хас үзенчәлекләр дә аерылып чыга.

Борынгы катлам булып санала торган туганлык, кан кардәшлек атамаларына кыскача тукталып үтик. Аларның сүзлек составы ягыннан Кукмара төбәге Казан артында таралган башка сөйләшләрдән

аерылмый, әдәби тел белән дә уртаклык күрсәтә: *әти, әни, әби, бабай, абый, эне, сеңел, апа, бажҗа, бийем, бийата, килен, килендәш, кода, каенсеңне, каене, җизни, җиңги* һ.б.

Кукмара төбәгендә *әни, әти* атамаларын киң вариантта *әнәй, әтәй* дип әйтү очраклары еш очрый. Шулай итеп, Татарстанның көнчыгыш районнарында актив кулланылышлы *әнә(й), әтә(й)* вариантларының изоглоссасы Кукмара төбәгендә үк башлана икән. *Әти, әни* атамаларын *әттә, нәнә* дип әйтү очраклары да теркәлде.

Төбәктә традицион атамалар да сакланып килә: *тәтә*. Бу атама әти-әнинең сеңелләрен дә белдерә. Әгәр берничә булсалар, аларны *бал тәтә, тәти апа, чәчәг апа, Мәликә тәтә / Асма тәтә* дип аералар. Әти-әнинең апалары исә *дәү тәтә, апай тәтә* дип зурлап аталалар, чөнки алар инде сөйләүченең икенче яки өченче буын туганнарына карыйлар. *Тәтә* сүзе бик борынгы сүз, һинд-европа телләрендә дә таралган, санскрит телләрендә дә бар.

Бертуган апаны белдерү өчен төбәктә *апа* сүзе дә актив кулланыла, ул әдәби норма булып тора. Җиңгигә даими рәвештә *туган апай* дип эндәшәләр, хатынга иренең яки иргә хатынының бертуган олы кыз туганы, нигездә, *апай* сүзе белән белдерелә. *Килен* сүзен тел белемендә *килү* фигыле белән бәйләп карау шактый нык урнашкан. Шулай да бу сүз бик борынгы (ностратик) чорлардан ук билгеле (*ностратик чор* дигәндә, һинд-европа, семит-хәмит, дравидий, алтай, картвель һәм башка телләрнең бер тел булып яшәгән чорын күздә тоталар).

Бөтен татар халкына хас булганча, тикшерә торган төбәктә дә килен «тел йәшергән», «бийатасыннан йөзен йәшереп йаулык йапкан», «бийағасы белән сөйләшмәгән», әдәп-итагать саклаган, йорттагы кагыйдәләргә буйсынып, тулы, матур тормыш алып барган. Өлкән туганнарны зурлау, хөрмәтләү төп кагыйдәләрнең берсе булган. Бу гадәтләр туганнарга мөрәҗәгать итү сүзләрендә чагылыш тапкан: *чибәр абыстай (< абыз тутай)* – олы килендәшкә эндәшү сүзе.

*Ике туган, туганнан тушышқан* – әд. *туганнан туган*.

Йолалар һәм аларның борынгыча әйтелешләре буенча шактый бай материал тупланып килә. Һәр экспедиция бу юнәлештә нәрсәдер өсти. Кукмара төбәгендә дә бу өлкәгә кагылышлы күренешләр күзәтелә.

Мәсәлән, *бирнә җийу* – сабан туена әйбер җыю. Бу очракта үзенчәлекле мәгънә күчеше чагыла. Әдәби телдәге кыз бирнәсе

белән сабан туена җыелган әйберләр үзара чагыштырылган булуы ихтимал.

Бу күренешнең икенче сәбәбе дә булырга мөмкин. *Бирнә* сүзенең мәгънәләре сөйләшләрдә шактый бай. Мәсәлән, борынгылыкны үзендә аеруча нык саклап килә торган нократ, подберезье керәшеннәре сөйләшләрендә бирнә – *бүләк* дигән сүз (мәсәлән: *Қызы Мәскәүдән бирнә йебәреп тора*).

Күп кенә сөйләшләрдә бирнә кыз биргәндә, малай өйләндергәндә кода-кодагыйларның кара-каршы бирешә торган бүләкләре. Әлеге сүз еш кына кыз тарафыннан егетнең эти-әниләренә бирелә торган бүләк мәгънәсендә дә актив кулланыла.

Урал артындагы сөйләшләрдә кызның әти-әнисе тарафыннан башкодага ризалык билгесе итеп бирелә торган бүләк тә *бирнә* дип атала.

Кеше тормышындагы бала туу, сөннәткә утырту кебек әһәмиятле вакыйгалар вакытында бирелгән бүләкләрне дә *бирнә* дип атаганнар.

Шулай итеп, *бирнә* сүзенең, мамадыш, дөбъяз сөйләшләрендәге кебек, Кукмара төбәгендә дә борынгы «бүләк» дигән мәгънәсе сакланып килә.

Кешеләрнең рухи дөньясында уеннар да зур урын алып тора. Аулак өйләрдә, су буендагы яисә таллыктагы уенлыкларда иң таралганы – наза уены, түгәрәк уеннар, капкалы (так каравыл) уеннары булган. Тычкан салышлы, кул сугышлы, качышлы, тышка чыгышлы (кәтер китешле), йолдыз санашлы, шешә тәгәрәтешле һ.б. уйнаганнар.

Бийәләй атыш: «*Моноң артыннан кем қайтты микән, дип бийәләйне аталар*». Усал сарықлы: «*Берәү тышта тора, чықсын дип әйткәндә, өйдә кем туры килә, шул чыга, көлөшәдер ийек*».

Балалар уеннары: такта тибеш (икенче башындагы чыралар төрле якка очып китә һәм *көтүче* аларны җыярга тиеш), күкәй тәгәрәтеш.

Язгы йолаларның исемнәре күрше төбәкләрнеке белән бертөсле: *чөмәрчек* – яңгыр боткасы пешерү һәм, аны ашагач, су сибешү (чагыштыр: чүмечлеки, чөмәлчек һ.б.).

Ышанулар белән бәйле кайбер сүзләр: *йорт ийәсе // йорт хуҗасы.*

Өйрәнелә торган төбәктә тормыш-көнкүреш, иген игү, терлек карау белән бәйле сүзләр дә теркәлде. Мәсәлән, *утар* – абзар,

тышкы абзар; *өй әйләндермәсе* – кашага; *пужҫым* – йорт урыны; *ҫортлоҫ* – умарталык; тумран умарта; *сиҫасы суғу* – киндер сугу.

Кешеләрнең күзәтүчән, табигать белән үзара берлектә яшәүләрен чагылдыра торган сүзләр дә игътибарны җәлеп итә. Мәсәлән, яңгыр төрләре белән бәйле сүзләр: *узгынчы болыт яки яңгыр, эре яңгыр, вак яңгыр, сибәләк яңгыр, җылы яңгыр, йомшаҫ яңғыр* һ.б. *Әлеге төбәктә өлешле яңгыр гыйбарәсе яши: «Җәйге йаңғыр өлөшлө, ул бер җирдә йаwа да, тағын китеп икенче җирдә йаwа».*

Белгәнебезчә, җир җиләге, каен җиләгеннән аермалы буларак, бөре канатчыклары өстендә утыра, ул канатчыкларны Минзәлә якларында *керфек* дип йөртәләр. Кукмара якларында исә аны, образлы итеп, *күлмәк* дип атыйлар: «*Минем ҫызым бигрәк тә тырыш инде, җиләкне сразу күлмәген салдырып җийа. Ҫайбер ҫатыннар күлмәге-нийе белән ҫайнаталар баринйысын*».

Үсемлек атамаларының килеп чыгышы төрле башка сәбәпләр белән дә бәйле булырга мөмкин. Мәсәлән, какы Дусай авылы басуында күп үсә торган булган, шуннан күрше Төркәш авылында аны «дусай печәне» дип йөртә башлаганнар.

Кием-салым белән бәйле сүзләр нигездә әдәби телдәгечә. Шулай да үзенчәлекләр дә күзәтелә. Кием-салымда да халыкның матурлыкны күрә белүе, нәзакәтле сиземләве, эстетик карашлары чагыла. Мәсәлән, бу якларда *айалка, дағa алка* киң таралган булган, алар эшләнеш рәвеше белән айны, даганы хәтерләтә.

Муенсаны күпчелек очракта *муен бавы* (муйым баwы, мийем баwы, мим баwы һ.б. вариантларда) дип атыйлар. Татарларда кул бавы да киң таралган бит: ул – мәрҗәннәрне тезеп, бер йә ике кат уратып эшләнгән беләзек.

Көмеш беләзекләр, ахак кашлы көмеш чулпылар хатын-кызларның яраткан бизәнү әйберләрен тәшкил иткән: *ҫаралтынны беләзек, тар беләзек, көмөш беләзек* һ.б.: «*Көмөш беләзек кийә-кийә йуҫа ғына ҫаладыр ийе, элек йегерме тийенне төйөп йөзөк йасап бирер ийе абый, безнең халык һөнәрле бит ул*», – дип сөйләп китәләр ак яулыклы, чал чәчле әбиләр.

Бу яклар өчен характерлы кием-салым атамаларыннан тагын түбәндәгеләрне күрсәтергә була: *фелүр җаулыҫ* – ефәк яулыкның бер төре, *әби итәк* – бөреп-бөреп тегелгән итәк; *кәртиңкәле* – балайтәкле, *чана шәле* – кышын ерак җиргә кунакка барганда ябынып утыра торган зур калын шәл.

Бу якларның яраткан ашы *коймак, дучмак* (пәрәмәчнең бер төре), *күзикмәк, җуқа* (затлы камырны җәеп, майда пешерелә торган ризык) булган, *балан дәwешләмәсе, кабаклы* яки *итле бәлешләр* һ.б.: «*Телләреңе йотарлық була бит ул бәлешләр*».

Борынгы ашлардан *җылғыр*ны атап үтәргә кирәк. Аны күбесенчә киндер орлыгыннан пешергәннәр, бу якларда исә эремчектән дә әзерлиләр икән. Кабартмалар, төче күмәчләр дә төрле-төрле итеп пешерелгән. Мәсәлән, аларның бер төрлесен *әнәчә* дип атаганнар, *wалма* (уалу сүзеннән) дигәнен күбрәк балаларга пешерә торган булганнар.

Кайбер башка сүзләр: *печашы* – мичтә пешерелгән камыр ашлары, *тәкә* – зур бөккән, *тура* – корт. *Туқмач ашы* – туйның икенче көнендә яшь килен кискән токмач белән һәм якын туганнар катнашлыгында уздырыла торган мәҗлес.

Гомумән, Кукмара төбәгендә дә безнең тугандашлар матур гореф-гадәтләребезне сакларга, әби-бабаларыбыз тарафыннан тапшырып калдырылган йолаларны, тәртип-кагыйдәләрне тотарга тырышып яшиләр, тырышлык, хезмәт сөю үрнәге күрсәтеп тормыш итәләр, үзебезнең саф татар телендә сөйләшәләр.

**Түбәндә җирле халыктан язып алынган кайбер материалларны тәкъдим итәбез.**

## Авыллар тарихы турында

Салтык Ерыклы авылы. «Тау йағыннан қайандыр, Қазан йағыннанмы, күчеп утырған мында халық, чуқындырудан қачып килгән кешеләр. Унсигез семйадан башланып киткән. Мында бик қуе урманнар булған. Кешеләр Султық йылғасының Йуғары Шөн йанына утырғаннар. Султық йылғасының башы бу төштә, арға таба. Ул йылғада зерә күп йыланнар булған, сыйырларны имә торған булғаннар алар. Халық шуңа изаланғач, йаңадан менә мында таба күченгән. Мындағы бөтөн ағачларны кисеп, шулардан йортлар салып, шулайтеп йәши башлағаннар, қачып. Менә шуның арқасында чуқындырылмыйча қалган. Элег-электән Салтық халқын «чиста нәселле» диләр. Бороңғо зират урынында арлар тора. Анда ашлық чәчмиләр ул урынға. Салтық – әнә шул Султық йылғасының йырықлы, гел йырғанақлы булғанға. Аwылның Салтық Йырықлы дип аталуы да шул Султық йылғасы буйына күчеп утырудан килеп чыққан. Аннан соң безнең икенче атамабыз бар – "Өшөн башы",

безне “өшөн башлар”, диләр. Менә монда Түбән Өшөн, аннан Урта Өшөн, аннан Түбән Өшөн китә. Түбән Өшөндә йомочқа ағып төшкән, шушы йылғада. Бу йылғада таш булған, һәм мында нинди дә булса кешеләр йәши, дип, шушы безнең аwылны эзләп менгән, үзенә иптәш итептер инде. Ул заманда кеше әз булған бит. Шуңа күрә безне “өшөн башы” дип қалдырғаннар. Ар Өшөн Башы һәм Татар Өшөн Башы (авыл исемнәре) була, диләр бездә. Арлар – удмуртлар алар.

Базарға безнең эти көл сатарға йөргән, бик матур базар булған. Бақыр тәңкәләр, ақчалар сатқаннар элек. Салтық атамасы (салтық – таза, нык бала) тәртип, йола сақлаучы дигәннән чыққан».

Ташлы Елга авылы. «Ташлы Йылға аwылына иң беренче килеп урнашқан кешеләр Зәнки, Аблай исемле булған, ди. Зәнки дигән кешенең хужалығы, жирләре күп булған, йылға йаныннан ағып, йуғары очқа қадәр сузылған. Килгән кешеләр, үзләренә житәрлек жир бүлеп алғаннар, айырым-айырым итеп урнашқаннар. Ташлы йылга буйына урнашқанға күрә бу аwыл “Ташлы Йылға” дип аталған, диләр әби-бабаларыбыз. Анда ташлық булған».

Бурсыкъелга авылы. «1700 йылларда бер төркөм мөсөлманнар ике-өч нәселдән, урман аланлықларына килеп ағачлар төпләп, үзләренә йорт-жир житкергәннәр. Ул wақытта әле Бурсық-Йылға аwылы қалқулықта урнаша. Аwылдан түбәнрәк урыннарда сазлық булған. Wақытлар узған саен урманнар, сазлықлар чигенгәннәр. Чәчүлек жирләре артқан. Шулай итеп аwыл халқы элекке урыныннан тигезерәк жирләргә, су буйынарақ күчеп урнашалар. Бу сулықларда бурсықлар күп булған. Шуңа дадыр аwыл Бурсық-Йылға дип аталған. Бу аwылда ике зират бар – татарнықы һәм керәшен зираты. Берwақыт аwылға отряд килеп, анда йәшәгән халықларны чуқындыра. Тик бу отряд йақын-тирә аwылларға күчә алмый, аларны қуып жибәрәләр.

Ғабдрахман Шәйех дигән кеше үлгән. Аны зиратқа күмгәннәр. Аны күмгәннән соң, зират астыннан шишмә ағып чыққан. Шуңа күрә аны “Изгеләр шишмәсе” дип атағаннар».

Кәркәвеч авылы. «Иң беренче аwылға Морадулла дигән кеше килеп утырған булған. Үзәндә сазлық булған. Кешеләр тау башында йәшәгәннәр, сазлықлар кипкәч, үзәнгә йылға буйына урнашқаннар.

Аwылға Потапов дигән рус кешесе килә. Ул, Шөн йылғасын будырып, тегермән салдыра. Бөйәдә керкә балықлары күчә-күчә

белән йөри торған булған. Аwыл башта Керкәкүч, ә соңыннан Кәркәwеч дип үзгәртелә. Потапов берничә шишмәне берләштереп шишмә ача. Бу шишмә аның исеме белән “Путап шишмәсе” дип йөртөлә башлый. Зират астында “Әхмәт шишмәсе” булған. Аны Әхмәт исемле кеше қазыған. Хәзер ул шишмә йуққа чыққан».

Сөйләүче: Насыйрова Гөлүсә
Мөхлисулла кызы (1972)

Чишмәбаш авылы. «Шишмәбаш үзәне аwылдан ике киламетр көнйақта урнашқан. Бу үзәннең башында шишмә чыға, аwылға “Чишмәбаш” дип исем бирелүе шушы үзән белән бәйле. Аwылның исеме 1939 йылға кадәр “Қоллар” дип аталған. Аның барлыққа килүwе Қазан ханлығы чорона туры килә. Элек Қазан ханлығында фиадализм ыстройы була.  Феодалга бәйле крестийаннарны “қол” дип йөрткәннәр. Қоллыққа төшерүчеләргә риза булмыйча, баш күтәргәннәр, йә қачып киткәннәр. Қачкан қоллар марилар, удмуртлар йәши торған җирләргә барып утыра башлағаннар. Безнең авылға да крепостнойлыктан қачып, өч қол килеп утырған. Қыр үзәненда элек йәшәгәннәр, қыр станы булған ул. Арғыйақ урамын хәзер дә «Биккол очы» дип йөртәләр, йәғни авылға килеп утырған қоллар бәк-кнәз қоллары булган. Авылға татарлар килгәнче безнең авыл тирәләрендә мари қабиләләре йәшәгән. Қоллар исемен алыштырғаннар. Бездә мари зираты бар, сыйыр аwырса-нитсә шуннан әйләндереп киләдер ийек.

Бу йарлы аwыл булған. Татарлар килгәч татарлашқаннар. 1834 йылгы пирепистәге йат фамилийәләр бар, соңоннан татарлашқаннар. Крестийаннар дип аталғаннар, йасақлы керәстийәннәр (документларда), Сарды речка дип күрсәтелгән».

Сөйләүче: Шәмсетдинов Заһид
Вахит улы (1955)

Купка авылы. «Бөтөнләй дә бай йақ бездә Қупқа. Итек баса, шәлен бәйли, суған үстерә гектарлап. Монда гел туп-турыға ғына барасы, тықырық йуқ. Бар, әммә кечкенә тықырық. Аwылның бер башы тегендә, бер башы мында. Бетте. Безнең аwылның урнашу рәwеше ат дағасы шикелле. Менә монсы Қуйан базы (чокор), Шалтырама йылғасы. Вәққас қойосы бар. Басулар номер белән генә. Айет қойосы бар. Қортлокта қорт та булмаған, ә исеме шулай. Хә (хәзер) бер малай бал қорто асрый башлады шунда. Элек авыл

Сәрдәк (авыл исеме) белән рәттә генә булған, кубып өскәрәк күчеп менгәннәр. Қупқан дигәннәр, аwыл шуннан Қупқа булып қалған».

Сөйләүче: Гыйльметдинов Илфат

Шепшеңәр авылы. «Аwыл тарихларын сөйли торғаннар ийе. Безнең бабайлар сөйләwенчә, шушы тирәләргә Қазан җағыннан килгәннәр дип тә әйтәләр. Ағачларны кискәннәр, чәчәргә җир кирәк бит. Элек йуwан-йуwан чыршылар үскән монда, аларны кискәннәр. Бысысы Чыршы йулы, әнә шуннан қалған, хәзер басу инде. Оло йул басуы дибез, ансысы Дусай аwылына бара торган җул.

Чыршы да булған, қуwақлық та булған, қуwақ чекләwеге җийа торған ийек.

Чекләwеккә дә салқын тийә. Чиләк белә дәген җийа торған ийек. И була торған ийе чекләwек, қура җиләге, қайын җиләге. Җир җиләге булмый торған ийе. Чәкчә җылғасына барып җийа торған ийек. Киптерәбез дә. Қошкөннәрдә чәй эчәргә әйбәт.

Бийыл шундый күп булды қар, тәрзәләрдән ийе, ишекне көчкә начылый (көч-хәл белән) көрәп чықтық. Қызларым икәү. Бысысы (монысы) шинний забут ысталаwайында эшли. Минем китәсем килми, қызларым чақыралар, бергә-бергә күңеллерәк булыр, дип. Қызым монда қайта, берсесе пинсийәгә чығып.

Насыйр бабай шишмәсе булған. Башта өч кеше генә килеб урнашқаннар, гел урман булған. Башта шушы тирәдәге аwылларға барғаннардыр инде. Арыш, арпа, соло чәчкәннәр күберәге, бәрәңге утыртқаннар, йасмықлар, борчақлар чәчкәннәр. Ағач суқа белә суқалағаннар, тырма җасағаннар, тырмалағаннар. Ағач табақлар бар ыйы әwәле».

Сөйләүче: Газизов Гаптелкаим
Газиз улы (1931)

Сәрдекбаш авылы. «Иван Грозный чуқындыра башлағач, чуқындырудан қурқып қача башлағаннар. Монда Масрадан, Кибәхуҗадан (ав. исемнәре) дүрт кеше килеб утырған булған. Монда урман булған, аларны кисеп бетергәннәр инде йаңа җир ачабыз дип. Чишмәләр бар ийе, өстәрәг ийе. Хөтләмәт чишмәсе, Тарлау җылғасы, Тәрҗемән чишмәсе, Әймәк чишмәсе. Зур Сәрдек элек үк булған. Элек ул Старый Бурец дигән җирдә булған, руслар килгәч мондарақ күчеп утырғаннар. Бабайларның балталары булған, йомочқалар ағып төшә, монда кеше бардыр дип менгәннәр. Безнең

этәйләр булған монда, шуннан Сәрдекбаш аwылы булған. Сәрдек суwы башында булған. Бүлиле керәшен булмыйча бүленеп қалған. Байлар Сәрдеге булған, хәзер Зур Сәрдек. Йаңа Сәрдек 1860 йылда Зур Сәрдектән күчкән. 1922 йылда Зур Сәрдектән Салқын Чишмә, 1929–1930 йылларда Зур Сәрдектән тағын аwыллар чыққан. Без элек Малмыж өйәзе Китәк вулысына қарағанбыз. Әби патша wақытында Малмыждан Эсфирлау йулы өстендә Китәк булған, шуңа күрә Китәк вулысына күчергәннәр безне.

Қырынды йақ басу бар, бурлар үтергән санау бар. Һәрбер участокқа санау ди торғаннар ийе. Қара йылга ул аwыл исеме, Өчөм йылға бар. Атау үзәне бар, анда су чықса, ташу ташый, ди торғаннар ийе. Ул иңкешерәк, қойашқа арқанырақ. Қыш көне қар күб утыручан була ул йақта. Шунда қар алаланса, ташу аға инде. Казаңка белән Бөр суwының арасы – урманнық. Бөрбаш аwылы Бөр суwының башында утыра.

Җөннө җәйә белә теттереп алалар. Башта түшиләр аны, зур була, аннан баса-баса эссе суда, эссе булмаса керешми ул. Бәләк белә дә бәләклисең аны. Син басқан итек бар әле минем. Анан сун басып йитте дигәченнән, йаңадан салып қайнатасың, қайнатасың да қалып қуйып басасың. Пичкә салып киптерәсең. Ташы була йиңел, шуның белә өстөн ышқыйсың. Қара итек кирәк булса, буйыйсың».

1994 елгы экспедиция вакытында
язып алынды

Я д е г ә р а в ы л ы. «Иван чишмәсе, диләр. Иван шушы шишмә йанында йатқан, чуқындырыға килгәч. Йәдегәр баба кертмәгән аны. Йәнилнең дә йартысы чуқынған булған, дип сөйлиләр. Йәдегәр 435 йыллар элек килеб урнашқан. Шушы тау итәген қарап, чишмәләрне күреп, суларны күреп, шушында утырғаннар. Сәрдекләр элек килгәннәр ахыры. Бабайлар судан йомычқалар ағып килгәнне күреп, су буйлап йуғарыға таба менеп қерағаннар, монда да кешеләр йәши икән дип.

Көшкәкнең йылғасының башын менеп қарадым, чишмә чығып тора. Бөйә бөйәйләр (буа буалар), тауны ишеп төшөрәләр дә монда бөйә бөйәйләр. Үлем алдыннан Сәрки суwын сорағаннар. Алып барғаннар. Икесе дә эчкәннәр дә бақый дөнйаға күчкәннәр. Чишмәләр су астына қала бит. Шишмәләрне ләм баса. Йәдегәр бабаның рухы сиңа риза булырмы?

М. Мәһдийев килгәч үзем уйнаған тау буйларын күрсәттем.
Әйа ағач, йәшең күпме?
Түгелгән җимешең күпме?»

Сөйләүчеләр: Хәсәнова Сания Хәсән кызы (1931),
Сафиуллина Фирдалия Хәлил кызы

Кенәбаш авылы. «Шушаwылның төп кешеләре без. Бабай әйтер ийе, кызым, син бу аwылның җиденче буwыны, дип.

Өч кеше килгән, дип әйтәләр: Зәбир, Балтач, өченчесе қушамат қына, ул Дусайдан (авыл исеме) килеп урнашқан. Йақлырақ булған өчөн аны Тубый қушаматы белән генә йөрткәннәр.

Бездән йырақ түгел Күз шишмәсе бар. Күз шишмәсе изге шишмә. Безнең апа әйтәдер ийе, Кенәбашның (авыл исеме) үзенең шишмәсе шифалырақ, Шүрәле шишмәсе. Аның йылғасын – Шүрәле йылғасы, дип йөртелгән. Шәрхи-мулла шул шишмәне рәтләп чығарған да, Шүрәле шишмәсе дип исем қушып, қарап тора, матурлап тора. Әлмәттә йәшәде ул, пинсийәгә чыққач монда йәши ул.

Бабайлар килгәч, өчесе бергә йәши башлағаннар. Җылғадан җомочқалар ағып төшкәнне күргәннәр. Элек монда чирмешләр торған. Монда бақыр чығарғаннар, куругум бақыр чоқорлары. Җаңғыр җауғач балалар саwыт тотып шунда баралар. Вәлиулла бабай қабул итеп торған, ақча биреп. Безнең аwылның исеме дә Кенә. Киндер, дип йазып чыққаннар, су башлары қырғый киндер белән қапланған була. Без самай бийек җирдә. Безгә читтән су керми. Бездән ағып китә».

Сөйләүче: Минһаҗев Миңнегали
Миячтин улы (1939)

Төркәш авылы. «Сөйләүләренчә, безнең бабалар шушы тирәләргә килеп урын сайлағаннар. Қазан йағыннан килгәннәр, дип тә әйтәләр. Монсо – сеңлем, монсо – түтәйем. Ағачлар кискәннәр, чәчәргә җир әзерләгәннәр. Бососы Чыршы йулы, оло йул Дусай аwылына бара торған. Қуwақ чекләwеге җийа торған ийек. Таудан менгәч қуwақлығ инде, қура җиләге, қайын җиләге. Бийыл шундый күп булды қар, ишекне көрәп, көчкә чыктық. Қызларым икәү. Минем читкә китәсем килми, қызым монда қайтасы килми.

Шуғыш чақларда күпне күрдек. Бер безне он апқайтырға җибәрделәр. Қайтып киләбез күтәренеп. Тамағ ачты, чабаталар да тишелде. Бақый абзый ийе бергадир. Умач балтушка да булмый, туқ-

мач та булмый. Он күп кермәсенгә балтушка ғына йасап эчәдер ийек. Игеннәр суғылмый қалған ыйы. Қош көнө ташып суқтырдық, чүмәләгә, кибәннәргә қуйғаннар ийе.

Безнеӊ бабайлар өч кеше генә килеп урнашқаннар. Насыйр бабай шишмәсе шулардан қалғандырмы. Ағач суқа белән суқалағаннар, ағач тырма белән тырмалағаннар. Ағач табақлар бар ыйы әле мим белгәндә дә. Шуғыш wахытларында ағач табақта қычытқанны чабып ашлар ашадық.

Қузғалақ, аныӊ төрлесе бар. Уртасыннан нийе чыға, аны әрчеб ашыйдырыйқ. Дусай печәне, дидер ийек, Дусай аwылында ғына булған бер үлән. Кәҗә сақалын иренгә тийермиче генә чәнәдек. Дусай печәненеӊ очонда сарғылтрақ чәчәге була, әчеб-әрчеб ашыйсыӊ, шундый тәмле ул, қақыныӊ бер сурты инде ул, әче қақы».

Сөйләүче: Сәләхиева Халисә
Закиҗан кызы (1924)

Кәркәвеч авылы. «Менә болай булған. Шөн җылғасыннан йомочқалар ағып төшә икән. Шуннан белгәннәр Шөм башын, укмурт белән қатнаш аwыл. Тирә-йүндә зирек күп булған. Йыланнар сыйырныӊ имийенә йабышып қайта икән. Йук. Монда йәшәп булмый, аwылны күчерик, дигәннәр. Күчерә башлагач, удмуртлар, аwылны әйдә без бу йаққа салыйқ, дип, өскәрәк айырым салыйқ, дигәннәр, чөнки зиратны да айырым салырга кирәк. Верхний Шом дигән удмурт аwылы бер. Аларны да Шом башы диләр, Верхний Шом, ә безнекен татар аwылы – Салтык Йырыклы, дип атала. Халық телендә Ар Шом Башы, Татар Ошом Башы, йазуда (докуминтларда) Салтық Йырықлы. Икегә бүленгәннәр, арлар – бер йаққа, безнекеләр – бер йаққа. Тегеләрнеӊ (арларныӊ) зиратлары уӊ йақта, суқаламыйлар бер участоқны, агачы-нийе йуқ, дигән иде әтийем. Менә, дийе, ул арларныӊ элекке зираты. Аны, дийе, хәзергә қадәр механизатрлар сақлап киләләр, ул җирне суқаламыйлар, дийе. Менә мин бер-ике йыл карадым, ул урын йуқ хәзер. Аны белмичә йәшләр суқалап бетергән. Ә безнеӊ авыл түбән төшөп салған. Кешеләр читкә киткәннәр – Себергә җир эзләп. Җәнәсәй йағында Бушуй дигән урыс аwылы йанында җир бар, дип, Өлгөдән (авыл исеме), тағын кайсыдыр аwылдан күчкәннәр. Безнеӊ нәселнекеләрнеӊ әниләре үлгән. Чирамша дигән үләнне ашағыз, ату си́нга була, дигәннәр. Анда төрлөсен эшләгәннәр. Сағыз ағызғаннар.

Йаулықны сузып йапқаннар, барысы татарча сөйләшәләр. Урыччa да беләләр. Гаделша абзыйның тутасы чат итеп урыччa белә. Тутасы дигәнем, безнең тәтә инде. Һәр өйдә өстәл уртасында тутырма.

XVI йөзнең икенче йартысында Шәндердән (Шүләңгердән) (авыл исеме) күчеп килгән безнең бабайлар. Керкә күче дигән сүздән Кәркәwеч (авыл исеме) булып қалған. Керкә балығ ул, wақ, бармақ зурлығында. Шом башында (авыл исеме) берничә фамилийәне чуқындырғаннар. Аларны гел тикшереп торғаннар. Митрофанның (Мөхәмәтрәхимнең) аталарын зиратқа күмдермәгәннәр, элек татар белән ар бергә wахыттағы зиратқа күмделәр.

Кама арйағындағы Салтықларның берсеннән күчеп килгәннәр, докумитларда хәзер Салтық Йырықлы».

Сөйләүче: Гыйльфанова Рузия
Рәхимулла кызы (1922)

## Җир-сулар

К ә р к ә в е ч  е л г а с ы. «Менә бу Керкәкүч йылғасы. Керкә балығы күчесе белән йөри торған булғач, керкәкүч булған инде. Менә хәзер балық йуқ анда. Узған йыл суы кибеп бетте. Бу йасалма бассейн хәзер. Элек чиста ийе, ди әни. Төбө чиста, ташлы, балықлар күренеп торадырыйы йөзгәндә, ди. Бассейн йасап үзгәрткәннәр инде менә. Бу бер йақтан файда, икенче йақтан зыйан булған инде.

Зәбир чөннигендә печән чабабыз, “зәбирәч”, дибез без аны. Зәбир чөнниге булган. Чөнник – җәйге қоро урын булған. Зәбир бай җәй көнө бөтөн мал-туары белән шунда күчеп китеп, җәйне шунда уздырған. Дөрөс эшләгән бай, башы эшләгән. Менә без хәзер анда печән чабабыз. Бик күп шишмәләр чыга, печән шундый әйбәт анда. Кортлоғо шунда булған, бөтөн малын қуып шунда җәйен чыға торған булған. Файдалы йақ булған. Безгә хәтле буын әйтә, “зәбирәч” диләр аны, хәзер безнең баланың теле аны “дәбирәч”, ди, “д” белән, җайлырақ бит, қатлатып әйтә.

“Таш үзән”, дибез. Ансы ташлы булганға “Таш үзәнлек” дибез. “Бақыр базы” менә, бақыр чыққан булған мында. Менә мында тау қуйынында бақырның ниенә формалашқан төстә қом бар анда, бер төрлө ақ та түгел, сорғылт та түгел ул. Бақыр чыға торған булған».

Сөйләүче: Насыйрова Гөлүсә
Мөхлисулла кызы (1972).
Салтык Ерыклы авылы

Ташлы Елга авылы. «Басудағы қайбер урыннар. “Йақый үзәне” – Йақый дигән кеше ул җирдә иген иққән. “Имай үзәне” – Имай дигән кешенең җире булған. “Бәшәр үзәне” дигән җирдә Бәшәр дигән кеше йәшәгән. Үзәнлекләр хәзер дә шулай йөртелә. “Қарлыған елгасы” исеме қарлыған ағачы күп үскәнгә куелған. Түбәтәй кебек түм-түгәрәк булганға микән, басуларның берсен “Түбәтәй басуы” дип атаганнар. “Йаласкин басуы” дип аталған басу да бар. Мында бер урыс йәшәгән, аны үтергәннәр икән, шуннан соң бу басу Йаласкин басуы дип аталған, дигәннәр икән. Аннары “Ирекле чоқыры” да бар, аның басуында сабантуй үткәргәннәр. Байлар әйберләр-нәрсәләр сатқаннар, күрәсең, кешеләр барысы да үзен ирекле хис иткән. Ирекле чоқоры шуннан килеп чыққандыр дип уйлағаннар».

Сөйләүче: Насыйрова Гөлүсә
Мөхлисулла кызы (1972)
Салтык Ерыклы авылы

Чишмәбаш авылы. «Фабрик үзәне – бу үзән Җон йылғасының (қоры үзән) төнйақ йүнәлешендәге дәwамы булып тора. Анда элек қытат фабриқасы булған. Төрлө сәбәпләр арқасында фабриқа эшләүдән туқтый, җимерелә, ә фабриқа йанындағы үзән “Фабрик үзәне” дип атала башлый. Бу үзәндәге күперне дә “Фабрик күпере” дип йөртәләр.

“Бай үзән” авылдан 2–2,5 киламетр төнйақ көнбатышта урнашқан үзән. Бу үзән печәнгә, җиләккә бай булған. Шуңа күрә аwыл халқы аны “Бай үзән” дип атаған.

“Артышлық” Батыр ышнасыннан көнчығышта урнашқан. Бу қалқулықны Батыр ышнасыннан йырғанақ айырып тора. Қалқулықта артыш қуақлары күп үскән. Бөйөк Wатан суғышы йылларында аwыл кешеләре бу қуақлықларны йағарға кисеп бетергәннәр, ә исеме “Артышлық“ булып қалған.

“Әпәй қайынлығы” бар. Бу җир аwылның төнйағында, аwылдан йөз метр йырақлықта урнашқан. Җир крестианнарға бүлеп бирелгәндә бу җир Әпәй Хәйрулласы (әпәй – қушамат) исемле кешенеке булған. Анда қайын ағачлары да үскән. Шуңа күрә шулай исем биргәннәр. Соңыннан қайыннар киселеп беткән, ә исеме қалған.

“Тегермән алды” аwыл йәнәшәсендә урнашқан. Элегрәк бу урында су тегермәне булган. Тегермән үзе бетсә дә, тегермән тирәсе булған җир халық телендә “тегермән алды” дип йөртелә.

“Торна күле” бу урында хәзер аwыл фермасы урнашқан. Йегерменче ғасыр башларында да әле монда зур булмаған күл булған. Анда торналар төшә торған булған. Шуңа күлгә “Торна күле” дип исем биргәннәр.

“Тау шишмә” – аwылның төнйақ-көнчығышында урнашқан шишмә. Қалқулықтан ағып чыққанға күрә “тау шишмә” дип атағаннар».

Сөйләүче: Шәмсетдинов Заһид
Вахит улы (1955)

Купка авылы. «Менә бер тарихи фото бар миндә. Қупқа белән Сәрдек арасында нарат булган. Бу наратны мин бик хәтерлим. Монда сиксәненче йылларда бик зур семинар үткәрелде. Обком секретаре Панин дигән кеше бар иде, шулар килә, дип. Бу иске зиратның башы, дөрөсөн әйткәндә. Бу Қупқа белән Сәрдек (авыл исеме) арасында. Аның урыны Сәрдек белән арада. Менә бу картада булған ореинтир кебек. Аннан соң йәшен суқтымы, йандырдылармы. Башта йәшен суқты, әйе, йәмсезләнгәч, йандырып қарадылар – йанмады. Ахырдан семинар була, дип, Панин була, дип, астына берничә ни қуйып, шартлаттылар мыны. Менә шул урынны без йаңарттық. Менә шушы фотодан қарап, без аны йақынча беләбез инде. Сәрдек аwылы, Қупқадан төшкәндә. Фотоны минем абыйым төшөрөп қалдырған. Шушы урынны билгеләп, шунда инде шуны әйләндереп алдық дағын, аwыл халқы йәшләре белән инде. Йул өстөндә генә ул. Шунда утырттық ағачлар, менә ул хәзер безнең иске зиратның, Қупқаның, элекке аwылның бер истәлеге».

Сөйләүче: Ризванов Рәсим Газиз улы (1955),
шәһәр тибындагы Кукмара поселогы

Ятмас Дусай. «Монда, безнең аwылны чыққач, Күз шишмәсе бар инде. Аның хикмәте дә шунда, күзнең йарыларын қаплағаннарны да ачты ул. Былтыр суы кипкән иде эссегә, хәзер бар. Қараwат астында тора өчөнчө йыл алғаны да. Ул бернинди әшәкеләнми икән бу су. Ничә йыл Фаруғ абый нигездә сақлаған шул суны. Анда безнең әбиләр дә төшәдерейе. “Баш очонда қайын үсәр, айақ очыннан су чығар”, дигән безнең әби. Менә шул Дусай бабайдан қалған ул, Дусай дигән кеше булған анда. Безнең әби шул суға барғанда, гел сөйләп барадырыйы. Шуны рәшәткәсен әйләндереп алғаннар. Әгәр дә йамғыр йаумаса, шул рәшәткәне сүтәләр

дә, кире қоралар или сынығы булса, шуңа қуйалар, йамғыр ѕwа. Бабайлар шунда төшөп уқыйлар инде».

Сөйләүче: Галәветдинова Зәкия
Фәйзрахман кызы (1926)

Оштырма Юмья. «Чәпшермә, дибез, монысы нурушур, дибез удмуртча. Сазлы йылға була инде ул. Шишмә бар ийе, бетте. Таңач шишмәсе ийе. Анда қазлар қойона. Күптән чыға торған шишмә болар, фамилийәгә қарап қушқаннар. Аларның бақча башында, шуңа Таңач шишмәсе. Бақа шишмәсе – ансы тоже бақалар турында булган ул. Су алғанда чиләккә дә төшә торған ийе. Қайwақытта. Базар ташы, дидек без. Менә мыннан менеп китә бит».

Сөйләүче: Васильева Анастасия
Архип кызы (1928)

### Тормыш-көнкүреш турында

Шепшеңәр авылы. «Бабай ул имам да булып тордо. Уқыййаза белгәчтен, шуwыш (*сугыш*) чағында хат-мазар килсә, барыбыз да шуңар җүгерәдер ийек. Читен, ди торған ийе бабай, үлгән хәбәрен әйтүе.

Безнең әнәй күпне күргән. Безнең әнәй этигә дүрт бала өстенә килгән. Ийәреп килгән қызы уналты йәшендә wафат булған. Әти кыладаwайда эшләгән. Шул чақны қырықбиш кила артық чыққан ашлыгы. Сез моно урларға алып қалғанығыз, диләр икән этигә, персидәтелгә. Әтине йапқаннар. Шунда уқ, әни барғач, сез хат алышып торасыз икән, дип, әнине дә утырта йазғаннар. Шуғыш wакытында элмә ағачын қайрысын салдырып, киптереп, тартып, шулай итеп тә ашадық. Атларны бүреләр алғалаған. Без үзебез тақта җардык ғөмөр буйына. Қайсысы мунчаладан арқалықлар, бәлүк баулары ишәдер ийе. Миңа уналты йәш тулғачтын әрмийәгә алдылар. Башта урман кистек. Йыwан-йыwан ағачлар ийе. Лисхуздан Иштуғанға (авыл исеме) тикле тақта җул салдылар. Андан алты ай уқыдық. Ипи кисеп ашамадық. Эшкә кергәч әзрәк бирә башладылар.

Аwыл безнең туксан өч хуҗалық ийе. Туқсанынчы җылдан керешкән ийек мәчет төзөргә. Инде аwылда җегерме хуҗалық қалды. Безнең бабайлар җәшәгәннәр урман эчендә. Берwахытны җомочқа агып төшкән. Монда да кеше бар микән әллә, дип, җылғанын башына менеп қарасалар, марилар җәшиләр икән. Марилар

китkәннәр. Безнең бабайлар шушында йәшәп қалғаннар. Монда биг эшәп Ақай дигән шишмә бар. Түбән өч шишмәсе, дибез, менә тегеләйрәк».

Сөйләүче: Газизов Габделкаим
Газиз улы (1931)

Купка авылы. «Моны Вәғыйз абый сөйләп қалдырды. “Вәғыйз абый, бу Вәққас байны ничек қудылар?” – дидем. Аны, ди, җибәрмәскә тырышқаннарийе, ди. Бөтөн түбән оч қатыннары “җибәрмибез” дип килгәннәр. Солдатлар киттеләр, ди, көндөз, таң атқач, хәзер икенче көннө сәғәт өчтә килеп төштөләр, ди. Андары күккә аталар, ди, пистәлит белән, бер кеше киләлми, ди. Қарт қарчықлар җибәрмибез, дип торғаннар. Хәзер төйәп апчығып киткәннәр. Бу кеше сөйләwе, бер бабай сөйләп қалдырды.

Вәққас байда алтын күп булған. Аны талағаннар. Вәққас байға Қазан байы алтын биргән. Йалт итеп мәчет эшләт таштан, тигән. Ике мәчет эшләткән, өй шикелле генә тақтадан эшләткән. Моны килгәннәр тикшерергә. Қупқада ике убырный, дип киткәннәр, ошатмағаннар. Алтынны җыеп, чийыершығ ойасына да қуйған, күмеп тә қуйған. Вәққас байны талап бетерделәр. Вәққас байлар қайтып җөрдөләр, қызлары. Алар қарап қына киткәннәр. Моңарчы сүтмичә тордолар, әллә қайтырлар, дийеп. Аларның тоқымнары исән, диләр. Вәққас байның бер қойосы бар, эчтә атлар қойосы. Монда канушный да булды, атлар да тордо. Моны кибет итеп тоттолар инде. Вәққас байны Ташкент йағына қудылар, җылы йаққа байларны элек қудылар бит. Тимер йул бездән үтәсе булған, ул шуны сатып алған.

Бездә өч бай булған. Хәтиф (*Фәтих*) бай, аның хиссәсен (*кыйсса, хикәя*) әйтә алмыйм. Андары Идрис бай, аның тегермәне дә бар ийе. Иң байы Вәққас иде. Мәшкәре байлары белән дус булғаннар. Бу байлар сату, сәүдә белән байығаннар, кибетләре күп булған. Қазанда да, Қуқмарада да кибете булған, авылларда да кибете булған. Ул ат белән йөргән. Вәққас абзый бай кешеләр белән сәүдә қылған инде.

Шишмәбашта безнең үзебезнең әниләр дә бай булған. Шуның өчөн, чөнқи ир малайлар күп булған, ир малайлар күп булғач, җир күп биргәннәр, иген иккәннәр. Аwыл халқына ипи, күмәч пешереп сатқаннар, ашлығын биргәннәр, аннан соң сатқаннар. Әни жумарт булған. Ни қылсаң да, жумартлық қыл, дийе. Ахыр заман алдын-

нан қырыс җилләр исәр, диде әни, атсыз арбалар җөрөр, дийер ийе. Андары, киноны ди өйдә қарап утырырсыз, ди. Андары, таулар ишелә, диде, йуллар қуырыла, кеше итен кеше ашар, диде. Ансы нәрсә микән аның? Кеше итен кеше ашау – алдалау микән? Иң элек кешенең хәтере бетә, андары миһербан бетә. Әни әйткән сүзләр, малай. Андары, муллаларның чалмасын алалар, тайағын алалар... хәзер тайақлары йуқмы? Аптыраған көлөр, җөдәгән җылар, дип сөйләп тә қуйам».

Сөйләүчеләр: Ризванова Банат Сабирҗан кызы (1923),
Хәсәнова Саимә Сабирҗан кызы (1928)

Купка авылы. «Аның йәнәшәсендә (Вәққас бай йорты) зур бер склад бар. Ул йанды. Бер йылны, сигезенче классларда уқыганмындыр, шунда бу җимерелеп төштө, бөтөн матчалары. Анда көмөшләр бик күп қойолдо. Қазындылар. Менә аның тарихы шул. Байлар алар утыз беренче йылда барысы да Ташкентка киттеләр. Биш баласы булған, биш малайы, нәсел үрчегән-үрчегән. Қазан байлары белән бик әйбәт дуслар булғаннар. Бик ақыллы, миһербанлы булған бай. Қазан мәчетен салырға бик булышқан, диләр. Қысқасы, аwылда кем бар, шуларға эш тә биргән, аш та биргән. Ураза тотқан, намазны қалдырмаған берwақытта да. Шунда басуға чығып, бергә намаз уқыған. Алтын дигәннән, аларның ике этажлы йортлары бар. Өске этажында хәттә үзе тормаған, монда бик зур қунақмы ғына, аның туғаннары килергә мөмкин, қунақ бүлмәсе булған. Ишеғалдында әнә сез күргән зур ғына склад бар. Астында подземный юл булған. Шунда әйткән бабай, онығы сөйләде (барыбер бернәрсә табалмыйсыз, ди). Шамилбәкнең әтисе әйткән булған, зур чүлмәкләр белән кирпеч белән қаплап. Онықлары қайтқан. Бер йегерме биш йыллар бардыр инде, кайтып шунда нәрсәдер эзләп киткән».

Сөйләүче: Ризванов Рәсим Газиз улы (1955),
шәһәр тибындагы Кукмара поселогы

Оштырма Юмья. «Түбән йақта удмуртлар, теге урамда керәшеннәр – бында да қатыш инде. Безнен күршеләр бар да удмуртлар, қатыннары керәшен. Шулай қатыш инде безен. Иптәшем дә удмурт. Үзем керәшен. Чын татарлар читкә киттеләр инде, булса да монда түгел. Бабай да шушында туып үскән инде безнен. Әтинен атасы шушыннан башка чығып зурайғаннар инде алар. Биш-алты хуҗа инде алар. Үлеп беттеләр инде, қайсы исән әле. Минем қорлар

күбесе йуғ инде хәзер, минем йәшләр. Умбиш чақрымнан мыннан, шуннан алып қайтты инде удмурт. Балалар да удмуртча, татарча да сөйләшәләр.

Унсигез йәштән утарға чығардылар безне. Ашлық арасыннан печән утаттылар безне. Аннары унике йәштән ат җигеп суқаладым, тырмаладым, чәчтем, урдым. Ат белән урдылар урақны.

Көндөз үземнен чабатаны кийеп, кичкә уйынга киндрәсен тартып, этинекен чабатасын кийәдерейем. Минем үземнен тузанлы була торганыйы, кәкрәйеп бетә балчықта йөрөп. Зур булса, этинекен тартып кийәдерейем. Ыштыр урыйдырыйық, киндрәсе белән бәйлидерийек.

Қычытқан белән аш ашадық. Аннары балтырғаннар. Урманға барадырыйық, тау төбөнә барадырыйық. Тоз булмады, бәрәңге булмады. Әнә шулай бер қазан пешереп, йөрөйдөрөйийе қорсақ су эчеп. Бер стақан йөз сум ийе тоз. Аны да чеметеп кенә сала торған ийе, тәм генә чықсын дип, шундый wахытлар. Қычытқанны табып булмағач, алабота йафрағы белән пешердек. Киптереп аны төйөп күмәчләр пешерә торған ийек. Аннары көз көнө қалған бәрәңгене суқалағанда балалар арттан йөрөйләр ийе. Эше күп булды. Печән wахытында, башта чаптық чалғы белән, аннары җыйдық, аннары кибән қуйдық.

Печәнне бөртөкләп җыйдық ашлық арасыннан, киптереп малларға. Балтырғаннар, шома көпшә ашадық. Ул шома көпшә зур була, қалын була, йуан. Анын белән су да сиптереп уйныйлар ийе қарты белән, ә йәшен ашадық.

Бездә чирмешләр дә, марийлар, хахлушкалар да барийе.

Ничек эш бетә авылда, ындырда, урманға озаттылар. Урман чығардық, ағачлар.

Үзебез суғып шакмақлап җитеннән күлмәк кийәдерейек. Җитен йомшақ, киндер қаты була. Киндере озон була. Күб итеп кисәсең дә, қапчыққа тегәсең».

Сөйләүче: Васильева Анастасия
Архип кызы (1928)

Я т м а с Д у с а й а в ы л ы. «Сикереп тороп қарадым, мин әйтәм, мунча булса, мондый төтөн чықмас ийе. Шатыр-шотор ата бу. Тықрыққа барыйм дим, чықсам, озон тау бар, күремми, уты ғына йалтыр-йолтор килә, уты күренә. Ата инде шушақлы, жанды инде. Озон булған инде ул, бозаулықлары булған, шифырдан былтыр

ғына эшләгәннәр, ремонтлап чыққан булғаннар. Тышка чығарған булған бозауларны фермадан. Бер бүлеме җаныб беткән.

Баланы суққан булған, бишектәге бала тыпырчынып җата, ди, җаны чықмаған. Шуны алып чығып, қызыл балчыққа күмгәннәр бишектәге баланы. Шақирҗан исемле абый, ди, ул. Шул йәшен суққан бала терелгән, ди, йуққа чықты, ди, аның ниләре. Балчыққа күмәргә бит аны. Дерелдәп йата, ди. Менә йоқлый дип йат син, име. Тәрәзәләре ачық булған, шуннан йәшен суққан. Терелә дип әйтәләр бит, шул балчыққа күмеп қуйдық, дип әйтә инде ул».

Сөйләүчеләр: Хәбибуллина Нурания Хәбибулла кызы (1935),
Галәветдинова Зәкия Фәйзрахман кызы (1926)

Кенәбаш авылы. «Үземнекеләр, Аллаға шөкөр, өч малай, бер қыз. Аларның да бала-чағасы бар. Улым Кукмарада. Аның бер қызы умберне бетерде, йеге дигәннәрен дә әйбәт бирде, алтын мидалға бетерде.

Без ирем белә бергә үстек. Миңа йегерме дүрт, моңа йегерме туғыз ийе. Монда Сабира әби торған, аның асрауға алған қызын Закир җизни аптөшеп киткән. Аның улы Заһирның қызы мин. Мин қырығ өченче йылғы. Әни әйтер ийе, син туғанда бер сынық ипи жуғ ийе, дип. Әти қызы барын белми китә әрмийәгә, ну очрашырға насыйп булмый. Әни мине җибәрмәде уқырға. Иптәшем әйбәт булды.

Без печәнне печәннеккә тутырабыз. Кибән қуйасың, чүмәләгә саласың, валкаwайт итәләр (*киштәләү*), күбәләп қуйа. Бу безнең йаңа қаралты, лапасқа қуйалар дә шуннан печәннеккә өйәләр. Бер чаоб алғач, икенче үскәнен қурпы дибез, чаоп булмый аны. Әле, Аллаға шөкөр, дип, шөкерана қылам, тихника бар. Әни әйтер ийе, «и қызым» дийер ийе, “бушқа эшләдек бит без”, дийер ийе.

Бәрәңге черде бит, качт'ор (үлән ис.) чәчтек.

Бәрәңге өйдөк, тырактыр белә дә йаралар, йә өйгөч белән, берсе тарта шул өйгөчне, суқа кебегрәг ул, берсе арттан этеп бара рулен тотып. Хәзер бар эш тә асат инде. Элек күзеңе жыртып торасың да, шишмәгә йүгерәдерийек.

Минем бабай әйтәдер ийе, “без биш малай, ике қыз үстек”, дип. Чырағачны телеп қуйа, монда шәйкә қуйа. Төннө буйы чыра жақтысында җеп җегерли. Аннары суқыр лампы чықты.

Минем әни әйтер ийе, киндерне талқыйлар, җегерлиләр. Ыштанның баwын үреп қуйалар ийе сигездән.

Минем үземнең әби йегерме бер йыл урын өстөндә йата. Әтинең абыйсы чығып китә, моны абыстайга алып бара. Абыстайға бирергә ақчаң бармы? – Өч тәңкә бар. – Китер, үзем бирим. Қызы әйткән: Йуқ, минем үземнең бирәсем килә.

Абыстайга керәләр. Элек Қозғончы (авыл исеме) әби бар ийе, бик шифалыйы.

Минҗамал әбинең дисбесе бар ийе. Хәйереңе бирәсең дә, ул дисбесен тарта да әйтә нәрсә булғанны. Сузан ғына малайы бар ийе. Шуны белергә мин дә бардым, суwық тигәнме, бозоқмы, дип. Суwық тигән, диде. Элек мулла абзыйға барғаннар. Безнең муллабзый бөтөнесен тәртипләп торған.

Безнең аwыл тыныч, үз кирәген генә эшләп җата, кеше дә нәпселе түгел. Безне “урман җағы” диләр, Кукмара, Сәрдек (авыл исеме) йақларын “қыр җағы” диләр».

Сөйләүчеләр: Минһаҗев Миннегали Миячтин улы (1939),
Нәбиуллина Галия Заһретдин кызы (1944)

С ә р д е к б а ш  а в ы л ы. «Чәчү wахытында тубалчыққа салып җиргә күкәй тәгәрәтеп җибәрәләр. Орлоқ чығарабыз, ди торғаннар ийе исемен. Орлоқ, күкәй, ипи аппара. Орлоқ белән ырғыта. Малайлар җийып ашыйлар ийе. Ашлықлар уңсын, дигән сүз булғандыр инде.

Базарлар да төрлө көннө буладырыйы: дүшәмбе – Кукмарада, пәнҗешәмбе – Китәктә, шимбә көннө – Йәнил базары, йәкшәмбе Чепийәдә базар була. Бөртамақ дигән аwылда базар 3–4 йөз җыл була инде.

Ағач утыртмалар белә басуға баралар. Җуқа тақтадан чиләк фурмасы итеп йасаған. Өстө, төбө була. Тутыру, ағызып алу өчөн тишек тишеп қуйған була бөкләп қуйа торған ғына. Тотқасы да шунда беркеткән буладыр ийе. Суны басуға туз чиләк белән аппаралар ийе, кушмалар белән алып барсаң, тәме чыға. Туз чиләктә тәме чықмыйдырыйы. Қушмада изеп ипи пешерәләр ийе, ағачның эчен алып йасаған була ул, төбө була, аwыз йағы шул көйө була. Ағач чиләкләр белән су китерүчеләрне дә беләм әле. Ансы wақ тақталардан беркетеп йасаған буладыр ийе. Қоршаулаған була тал чыбығы белән, йә тимер қалай белән.

Җылғыр тәкәсе пешерәбез. Киндер орлоғын киптерәсең, төйәсең, аның көйлөсө бар ийе. Уwып майын чығарасың. Қалғанын

сыйыклап қайнатасың, аны сөзәсең. Қуйыра ул, кибәге қалмый аның. Қамыр эченә тығасың пирук шикелле. Тәмне була ул жылғыр тәкәсе. Қамырны җәйәсең тоқмач басқан күк. Хәзер эремчек тәкәсе пешерәбез бит.

Ашлықны бороннаталар су сибеп, киптерәләр, тарталар, шуны изәләр он белән. Зор чүлмәкләр була пичкә сыйа торған ғына. Шуңар арыш саламының башағын шуңа туғып ул қамырны, шуны чүлмәккә салып тынын чықмаслық итеп, пичкә қуйалар, йоқлаталар. Иртәгесен чүлмәкне улаққа утыртасың да, бер тишеге була, ағызалар. Ул бик баллы, қуйысыман була. Чүлмәккә қайнатып тағын су саласың. Ул тағы ағып чыға, сыра була. Эсседә эчеп тоталар инде аны.

Қунақ сыйларға әче бал йасыйдырыйық берәр чиләкле ағач бүчкәләргә. Шуңар су қайнатып, писүкме бүчкәгә салып қуйасың. Қирәгенчә чүпрә саласың. Аны бер 15–20 көн томалап қуйасың әчеп утырырға. Җийыннарда қунақ сыйларға тотасың. Пәнҗешәмбе қунақ сыйларға тотасың. Пәнҗешәмбе қунақ килә торған көн була».

1994 елгы экспедиция вакытында
язып алынды

Купка авылы. «Иңгелек қул белә урдық, қойаш чыққанчы барасыйы, қойаш батқачтын қайтасыйы. Утын йуқ, кәҗә сақалы йағасыйы, әрем йағасыйы.

Чабата-йоқ кийәбез, элек кийем мамығыннан ийе ойоқ.

Көтү чығар ыйы иртүк, чығарығыз, чығарығыз, дип қычқыралар ийе, көтүче Хаматхан абзый бар ийе көтүче. Аны биг әйбәт ашаталар, печ ашы пешерә, чәйен қуйа, күкәй қуйа. Безнең Қупқа (авыл исеме) халқы биг әйбәт ийе.

Элек қапқа түбәләре дә салам ийе, тақтаға күчтек, хәзер буйау.

Хатын-қызның ун сүзе, ирләрнең бер сүзе. Әнинең әйткән сүзе: хатын-қыз жыйа инде күлмәк, ирләрнең бер күлмәк, бер чалбар.

Қара суғыш булды ил өстендә, монда дағын ачлық булды. Әтиәни белән без җиде симйә йе. Ирләрсез булмый. Кеше үлсә дә қәберне ирләр қазый. Қатын-қыз дисбе тартыб утыра.

Тормош бара, таулар өшәнә, жуллар қуwырыла. Иңгелек кешенең хәтере бетә, аптыраған – көләр, җөдәгән – жылар.

Тамақтан да тәмне нәрсә жуқ.

Бөтен донжаға бәрабәр тора өч нәрсә. Беренчесе: йөрәккә сеңешле аш. Икенчесе: күркәм холоқлы ир. Өченчесе: игелек күрсәткән бала. Шулар бөтөн донжаға бәрабәр тора.

Безнең әнинең нәселе биг оло, «апарнықылар» дип жөртәләр».

Сөйләүчеләр: Хәсәнова Саймә Сабирҗан кызы (1928),
Ризванова Банат Сабирҗан кызы (1923)

## Туйлар турында

Кара Елга авылы. «Әни сөйләр ийе, атасына қарап улын кийәү ит. Анасына қарап қызын килен ит, дип.

Безнең үзебезнең әтинең тәтәсе димнәб алған. Йаучы булып қатыннар килә инде.

Қыз инде әйберләр әзерли: өй әйләндермәсе (өйне әйләндереп эленә торган кашага), чаршау, чыбылдық чебен тимәсеңгә дип, сөлгөләр, чинийақ тастымалы, күкрәк шунда. Теге wахытқысын әйтәм инде мин.

Килен төшкәндә жыстық салалар айағ астына, жомошақ булсын дип».

Сөйләүче: Мөхәммәтҗанова Мәгъсүмә
Тимергали кызы (1936)

Адай авылы. «Килен төшергәндә шөлдөрле ызбыруй, хут арба – тарантас дигәне. Жөк чанасы – қыш булса, арба – жәй булса. Сиртмә дигәне жиңелчә генә, алабы ғына йуқ. Алабы булса, тырантас була. Бүрәнә арбасы була, озон арба, бүрәнә ташырға.

Кийәү йағыннан күлмәкләр, йефәк шәл, читекләр китерәләр. Камзул кийәләр, пелүш түгел, бәлхуттан (*бәрхеттән*) камзул булыр ийе. Қалфақ кийәрләр ийе энже тезгән, йә зәңгәрсу була, йә йәшмә була қалфак. Күкерәкчә булырыйы, қайсы муйынса ди аны, тәңкәләр, ахақлар теккән, ефәк тасмаларны бөрөп-бөрөп теккән читләренә. Қунаққа барғанда, күлмәк өстеннән алға кийеп қуйарлар ийе, муйынға бәйләп. Әле анда қор'ән саwыты була торған ийе, аны йә хәситәгә, йә муйынсаға уртаға тегеп қуйалар. Ул кечкенә генә тартма кебек була, қапқачлы. Өсләрендә, кырыйларында қашлар була йә ахақ, йә зәңгәр, йә шәмәхә қашлары. Мәржән, диләр бездә, муйынға тағалар, энже-мәржәннәр дә була. Гәрәбәсе ирерәк, мәр-

җәне wағрақ. Чым мәрҗәннәр дә була, қулбау итеп бәйләрләр ийе, нечкә қызылны. Гәрәбә бастырылмасқа файдалы, мин үзем бик бастырылам».

1982 елгы экспедиция вакытында Миңнегалиев
Корбаннан (1918) язып алынды

С ә р д е к б а ш  а в ы л ы. «Димче килер ийе, ир-ат буламы. Элек күреп сөйләшәсе түгел ийе, бирәләр дә, барсаң да барасың, бармасаң да барасың. Ақсақмы, туқсақмы, белмисең. Бер килгәч, әти бирмиче җибәрде. Wәгъдәгә сөлгөме, тастымалмы, бер нәстә биреп җибәрә қыз йағыннан. Туй билгелиләр, wәгъдә бүләге биреп җибәрә туй билгеләгәч. Тарту була, күпме бирә ала инде. Күпме сорый ақча қыз атасы. Қыз атасы-анасы күлмәк сала, җаулық саламы, қомған, эләгән. Қалын малы салалар ийе. Җегет җағыннан күлмәк, җаулық, қызға камзуллар, читекләр буладыр ийе, чиккән кәлүшләр мәһәр җазыладыр ийе, қыз белә җегет айырылса, җегет җағы түләсе. Туйға килгәндә апкиләләр туйға. Сондоқ белән аш саwыты килгәндә, қалын малы да апкиләләр. Чәлпәк ти торғаннар ийе, күкәйгә генә басалар да төчөгә, йуқа ғына итеп җәйеп таба зурлығында итеп, майда пешерәсең, сондоққа тутырырлар ийе, аш саwыты булып аталадыр ийе. Төп қода әпкилер ийе ашны. Қода апкилгән ашқа ничә ат бара, қодалар, қодағыйлар була барысы да. Төп қода була, пар ат җигеп, қынғырау тағып тезелеп киләләр ийе. Тегесе төп қода булып санала, балалары, қодалар, қодачалар. Җийылалар, ашый-эчәләр, никийах уқыйлар. Шуннан суң қода ашлары чыға башлый. Қыз җағыннан килгәннәре аш белән киләләр ийе. Элекке көнне бетмәс ийе. Аш чығып, икенче көнгә қалыр ийе. Туй қыж җағында булыр ыйы бит.

Қодалар киткәч, кийәү килә. Қызны бүген туй, бүген апкитмиләр. Ата-анасы тигез булған кеше җәйеп қуйа урынны. Аңар бүләк була. Кийәү икенче көнне иртән мунчаға барғач бүләкләр қуйып чыға, сабын, җаулық. Безнең тәтә уналты йәш булмаған ийе, унҗидегә чығарыб уқыдылар.

Аннары сөйләшкән көнне ат белә килә дәген, төйәп китә. Бер атта кийәү бара, бер атта әйбер бара. Әйбер илтүче була инде. Қыз малы хәленә күрә инде. Аттан төшә торған җиренә “йомшақ булсын” дип мендәргә бастыралар, өйгә кергәндә инде анысы, тупсада. Су йулы күрсәтәбез, дип йөргәнне хәтерләмим инде. Бирнәсе, дип

әйтәләр, әйбер инде қара-қаршы, син дә бирәсең, мин дә бирәм. Туйдан соң бирәләр иде аны қодалар алдында».

1994 елгы экспедиция вакытында
язып алынды

Кенәбаш авылы. «Туйлар үткәч, қызны қунаққа чақырасың. Ике кич қуна. Әйберен, бүләккә бирәсесен дә алып китә. Мал да биреп җибәрә қайсысы. Бабайның апасына бозау биргәннәр. Таwық қушмағаннар, таwық кеwек тырманып йатыр, дип».

Сөйләүче: Нәбиуллина Галия
Заһретдин кызы (1944)

Ядегәр авылы. «Димче килә, хәзер инде әтисе белән әнисе бара, йанында тағын бер йақын туғаны бара. Әwәле димче йөргән, димче диңгез кичерер, диләр. Йегет йағыннан аның туғанымы килә. Бик төпченгәннәр әwәле, атасы кем, кем нәселе. Атасызны кийәү итмә, анасызны килен итмә, дигәннәр бит әwәле.

Мәһәре күпме, дип сөйләшә башлыйлар. Без чыққанда мәһәр җөз тәңкә ийе. Хәзер инде җегетнең кесәсенә қарап. Чылбырмы? Куwартирына қәдәр бирә. Тағын әле, тартуwы күпме, дип сорағаннар, ақча булған ул, җегет җағы бирә инде аны. Мәһәрне аны йазып қына қуйғаннар.

Бирнә, дип, қыз бирнәсен дә әйтәләр.
Килен бүләге, кийәү бүләге бар инде.

Киленне қаршы алалар баллар-майлар қаптырып, теле йомшақ булсын дип. Айағастына мендәр салалар, йомшак булсын, дип. “Әйдә, балақайым, төклө айағың белән, килгән җиреңдә таш бул” дип».

Сөйләүче: Хәсәнова Сания
Хәсән кызы (1931)

## Туганлык атамалары

Олыяз авылы. «Әнинең сеңелләре – түти, бер туган апа – тәтә, дибез. Апа дип сирәк. Абый, тәтә, энем, сеңлем, әби, бабай, дидек. Кечкенә малайны “дәү әни” дип өйрәтәбез. Миңа “әбекәй” дип эндәшә, әбекә, дип. Үзләре әби. Олы әбиләрен, әниләрен – нәнә дип эндәшүчеләр бар. Әни дә диләр, нәнә дә диләр. Әти – әттә, киленнәр “әнкәй” диләр. Үз әниләрен – әнеки. Әткәй, этеки – ирнең әтисен».

Сөйләүче: Якупова Нажия
Җамалетдин кызы (1943)

Оштырма Юмья. «Әнинен энисен “йырақ әби” дидем, этисен – йырақ бабай. Сәрдәүешләр (авыл исеме) тәтә, диләр, ә без “түти” дибез. Абыйлар – дәдәй. Бу оныҡ, аннан кече – оныҡчык. Энем, сеңлем, дип әйтәбез. Йырақ әби, йырақ бабай. Дәди – этинен туғаннары. Нәнә, дип, энисен әйтәләр. Әттә, эннә/нәннә – әле әйтүчеләр дә бар. Иркәләп әйткәннәр инде “эннә, тәттә/эттә” дип. Без үзебез “әни”, “эти” дидек. Хәзер балалар “мама/папа” диләр. Мин – бабу, әби, димиләр».

Сөйләүче: Васильева Анастасия
Архип кызы (1928)

Быжа авылы. «Менә шушы җортым минем. Ике ҡыз үстек, гел үлеп барғаннар. Рәттән дүртәү үлгән, мин бишенче булып туғаным. Әтиләр, әниләр эштә булыр ыйы. Аwыр җыллар. Алдыпҡычны җәйеп, бер wалчыҡны төшөрмичә ашап ҡуйар ыйым, әзерәг ипи ҡалдырып китәрләр ийе дә. Хәзер анда буш пуҗым (*йорт урыны*) тора.

Ирсез кешенең тормышы бик аwыр була бит. Ҡул көчө белән бер үзем торам. Апам бар ийе. Җырак тәтә бар ийе, ире җизни тийә миңа, Җаңа Ҡомарда (авыл исеме). Тәтә, диләр бездә, тәтәби, диләр балалар. Бездә түтәй диб әйткәннәр. Җырақ тәтә, дип әнинең сеңлесенә дә әйтәләр, ире тужы җизни була.

Безнең туған апа гел җырлар ийе дә, җылар ийе, үзе тегеб утырыр ийе. Аның анасы белән минем бийемем ике туған ғынайы, туганнан туwышҡан. Җырақ бабай (әнисенең этисе) озаҡ җәшәмәгән минем».

Сөйләүче: Гарипова Факиһәбану
Галим кызы (1917)

Ядегәр авылы. «Хәдичә җиңгәм бар ийе, әнинең туғаннары тәтәләр бар. Әнинең апасы булғач “дәү тәтә” була, “апай тәтә” ди ҡайсысы, әнинең сеңнеләренә “бал тәтә”, “тәти апа” дисең. Туғаннан туwышҡаннар да була әле ул. Киленне инде “туғаный апай” дидек без.

Ирeңнекеләрне “әткәй”, “әңкәй” дидек, ололар бит алар, читләр бийеме, бийатайы диләр. Иремнең тәтәсен “апа” дидек, ул да минекен шулай әйтә, сеңнемне “балдыз” ди бит инде, миңа аныҡы кайынсеңне була».

Сөйләүче: Хәсәнова Сания
Хәсән кызы (1931)

Кенәбаш. «Абыйсының хатынына йақынына “йақын абыстай” диләр бездә, “чибәр абыстай” дип тә әйтәләр».

Сөйләүче: Нәбиуллина Галия
Заһретдин кызы (1944)

Үрәсбаш авылы. «Суғыш чыққачыннан түтәйне Элүбийән (авыл исеме) урманы кисәргә җибәрделәр. Түтәйне озатқанда бәк читен булды. Нәнәй (*әни*) дә җылады. Җегерме алтынчы йылғы ағайны (*бертуган абый*) камиссийәгә алып киттеләр.

Анасы Минкәш исемне. Әби урман эченә кергәченнән, күпмедер wахыт барғач пуйызға утыртты. Апайларымны әрмийәгә алдылар, тәтәйнең (*әтинең*) үлгән хәбәре килде. Шуннан күпмедер көннәр үткәчтен төннә берәү тәрәзә қаға. И қодайым, бурлар микән, дим, әллә эндәшийем микән, дим. Тәрәзәдән, «Мин атағыз, Макчим», – ди.

– Пишкә дәдәй (*абый*), ни җәмош?

Тәңкә апылыныкы минем нәнәй. Нәнәйнең (*әнинең*) энесе җырақ дәдәй, җырак җиңгейләргә қунаққа барадыр ыйым. Ағай дип бездә тәтәйнең (*әтинең*) энесенә әйтәләр бит, үземнең ағай, җиңгей дә була. Җырақ түтей, җырақ җизни була, минем алар җуқ. Монда килен булып килгәндә бийатай белә бийем, бийағай да, җанағай да бар ыйы».

Сөйләүче: Гаврилова Анастасия
Максим кызы (1930)

## Кеше исемнәре

«Озын Микула (*озын буйлы Николай*); Анасы Минкәш исемне, аш бушатты. Макчим; Питкә (*Петя*) дәдәй (*абый*); Дарҗый (*Дарья*); Нәчтей (*Анастасия*); Симун ағай (*Семен абый*); Гәwи/Гәwерлә (*Гаврила*); Әнрей ағай; Бирай (*Вера*)».

Сөйләүче: Гаврилова Анастасия
Максим кызы (1930). Үрәсбаш авылы

## Өмәләр

Салтык Ерыклы авылы. «Өмәләр буладырыйы. Қаз өмәләре булыр ыйы, қызлар тезелешеп төшөп китәрләр ийе қазларны көйәнтәгә асып. Кичен қаз қоймақлары ашап, чәйләр эчеп қунақ булырлар ыйы қызлар.

Ашлық суғу өмәләренә җөридер ийек. Сүс җегерләү өмәләре буладырыйы. Тула да бастылар өмә итеп, без йәш ийек, ансысы миңа ләкмәде».

Сөйләүче: Нуруллина Нурия
Гыймади кызы (1939)

Кенәбаш авылы. «Қаз өмәсе инде буздә, қызларны җыйасың, бик күңелле ийе шул чақлар. Қазны күршеләрең белә бергәләшеп эшлиләр.

Өй өмәсе дә була. Өй җиткерәсең булса, өмә булған; күтәрәсең булса, өмә булған.

Тула өмәсе була, зур эш инде ул, қызлар йанына җегетләрне дә чақырасың әле, аwыр бит ул тула басуwы».

Сөйләүче: Нәбиуллина Галия
Заһретдин кызы (1944). Кенәбаш авылы

**Бизәнү әйберләре, кием-салым**

Кенәбаш авылы. «Чәчтәңкәсе бар ийе, “талир тәңкә” диб әйткәннәр, көмөш тәңкә ул.

Бөти итеп таққаннар, доға язып. Йаза белүче кеше йаза, аннан су тигезми торған әйбергә төрөп, чүпрәк белән тышлап, тағып қуйалар муйынға, чәч толомы астынарақ. Безнең әни бөтийен чәчүргеченә тағып җөридер ийе.

Айалқа дигәнне җаратып тақтым мин үзем. Һөнәрле кешеләр күб ийе элек, җасатып аладырыйық, қырықтартмачылар да күб ийе, йөриләр ийе, алардан да сатыб алғаннар.

Элек, җегерме тийенне төйөп, йөзөк йасап бирер ийе һөнәрен белгәннәр.

Беләзекләр дә төрлө-төрлө булған. Көмөш беләзек кийә-кийә йуп-йуқа ғына қаладырийе.

Чулпы да бар ийе әле ул мин бәләкәй чағында әбиләрдә. Чәчнең очонда озон чәчүргече, тасма белән. Очона чулпыны тағып қуйа, уртасында ахақ булыр ыйы.

Муйым баулары әллә ничә төрлө йе. Сап-сары гәрәбәдән тезгән муйым баwым бар ийе. Печән җийғанда өзөлөп китеп чәчелде дә әле ул. Мәрҗәннәрдән дә тезгәннәр, хәзер алар җуқ бит инде».

Сөйләүче: Нәбиуллина Галия
Заһретдин кызы (1944)

Быжа авылы. «Беләзекләр төрлө-төрлә, қаралтынны беләзеге бар ийе әнинең, көмөш, мин дә кидем әле.

Күлмәкләрне элекке беләсездер инде, икитәкле, күкрәк турысына ышлапырлар (тар балайтәк) қуйып тектерәдер ийек. Балайтәкне қайберләре җиде қат, уникешәр қат салдырырлар ыйы. Туған апам тегүче ийе, билгә хәтле балайтәк салып текте бер күлмәген. Мин үзем гармун итәклене кидем, зәңгәр атластан тегеп кидем».

Сөйләүче: Гарипова Факиһәбану
Галим кызы (1917)

Сәрдекбаш авылы. «Гөрәңкәле чулпы артқа тағa торғаннар ийе, башта ун тийеннек, аннан ары җегерме тийен, андары илле тийеннекне ике йаққа тезеп төшәләр, очта гөрәңкәле тәңкә, бер тәңкәлекне тағып қуйалар. Чөңкә қалфақ кийәрләр ийе қаз ашына барғанда, wақ сәйлән белән эшләгән була ул. Хәзер инде ул тәңкәләр бездә йуқ, арларда (удмуртларның халык арасындагы исеме), әкәйләрдә (мари хатын-кызларын шулай атаганнар) генә. Чәч тезмәсе дип қапчық шикелле йасап толомны шуның эченә тығып қуйғаннар, очона гөрәңкәле чулпыларны тағып, шалтыр-шолтор йөргәннәр, аңа чәчләр ничек чыдағандыр».

1994 елгы экспедиция вакытында
язып алынды

Үрәсбаш авылы. «Элеке өститәк саладыр ыйық, аның өстендә балитәк, очтағысы турыға ғына, мондый әйләндермә түгел. Җаңыш кештәкне салырға онотқан, инеч салып теккән.

Ситсы җаулықлар, эшәлҗаулықлар төрлөсен бәйләдек. Җон җаулықны затлы диб әйтәбез.

Мин бер матур күлмәк кидем, путалы, балитәкле, алда қыса турында ышлапыр ийе. Түтәй бер арқалы алҗапкыч бүләк иткән ийе миңа. Қанатлы (киң атламага балитәк тотылган) алҗапқычым бар ийе, зерә җаратадырыйым, қунаққа барсам гел шуны кийә торған ийем. Эшәл җақшыны бәйлисең қыш булса, чана эшәле».

Сөйләүче: Гаврилова Анастасия
Максим кызы (1930)

Салтык Ерыклы авылы. «Кийертеп-кийертеп қарыйсың, типчеп-типчеп чыққач тағын. Өчәр итәкле, дүртәр итәкле, алтышар итәкле дә булыр ийе күлмәкләр. Қысалы итеп тегәрләр ийе.

“Инеч салып бир әле”, – дип әйтерләр ийе, қысаның арқа йағы ике қатлы булыр ийе тиз тузмасынңға. Тар җакайы мим белгәндә инде, соңрақ түгәрәк җақалар чықты. Очло йақа бит хәзер, очпочмақлы.

Фелүр йаулық, үзе төрлө-төрлө төстә, үзе йомшақ, кәшимир йаулықлар, ситсы йаулықлар бәйләдек, ширыс йаулық та була. Қош көнө җон шәл инде үзләре бәйләгән, җә шақмақлы шәл.

Ирләр, берәр җары барса, толоп кийәрләр ийе.

Тулайоқ чабата белән, тулайоқ қалын бит ул, җылы булыр ыйы, олторақ җомшақ тиредән салыр ыйық чабатаға.

Үзеннән чыққан бизәкле тастымаллар булган. Үзеннән чыққан бизәкле киндердән айақ чолғауларын чигеп кийәүгә бүләк итәрләр ийе».

Сөйләүче: Нуруллина Нурия
Гыймади казы (1939)

Кара Елга авылы. «Алҗапқычлар төрлө-төрле була бит, аллы-артлы алҗапқыч, түгәрәг алйапқыч. Хәситәне күз тимәсеңгә тағалар. Миләшне дә шулай. Миләшне җиде йул чатыннан алып қайтып бирдем, аны беләккә хәситә йасап тағабыз».

Сөйләүче: Мөхәммәтҗанова Мәгъсүмә
Тимергали кызы (1939)

Кәркәвеч авылы. «Чулпы, беләзекләр була торған ийе, қызыл қашлы ул чулпы, уртасында җә ахағ инде; челтәрләп йасаған. Эчтән күкрәкчә кигәннәр. Хәситәне балаларға йахшы сүз йазып, қарындыққа төрөп, мендәрсымағ итеп эләләр.

Баштан кийешле алҗапқыч, әби итәкле күлмәкләр, әби итәк тиләр бөрөп-бөреп теккәнне. Қайсы күкрәктән бөрмәчләп (бөреп) теккән. Электә кәртиңкәле (балитәкнең бер төре) күлмәкләр булған. Келүшләр, балайтәкләр жуғ инде, бетте алар. Киндердән суққан күлмәкләр, җуwа башласаң берсе-берсе бер чиләк. Кийү өчөн әле киндерне җолқыйлар, булдыралар. Анар суң киндерне қуйалар мунчаға, кипкәч талқыйлар, көйлөдә төйәләр, аннан суң тәрәшле йасыйлар, җегерлиләр, нәрсә кирәк, шуны суғалар».

Сөйләүче: Якупова Хәдичә
Мансур кызы (1922)

## Аш-сулар турында

Починок-Кучук авылы. «Беленне төчөгә пешерер ийек, йомшаҡ була ул, эреп китәр ийе аwызда. Бәрәңге күзикмәген гел дә пешерәсен, тышы барыбер төчөгә, эченә тары ботҡалары йағар ыйыҡ, бәрәңге болмыгы да тәмне була. Пәрәмәчне пешерәсен wаҡ-wаҡ итеп, пичтә табада пешкәнне дучмаҡ тибез, аның да өстөндә бәрәңге төйөп, эремчек тә ҡушасың, көндәлек ашарға бәг әйбәт ул. Киндер орлоғыннан җә дучмаҡлар, җә пирашки пешерер ийек, аның тәмнелеген белсәң әле син. Хәзер җуғ инде алар. Мин үзем җылғыр йасыйдырыййым эремчектән. Җылғыр дип бездә эремчек пилмәнен әйтәләр. Уwалма пешерәдер ийек, аны бигрәк тә балалар җарата инде, майда пешерәдер ийек, төчөгә була ул, уwалып тора ашағанда.

Элек бер дә иренмәгәннәр. Арпаны бүрттереп, киптереп, тегермәндә тартыр ыйыҡ, чират буладыр ыйы әле анда. Бер-ике көн генә тартырлар ийе талҡан онон. Талҡаннар пешерәләр ийе әниләр ҡазанда, майда ҡыздырып пешерәләр, туҡлыҡлы бит әле ул.

Кесәллег ононнан кесәл пешерәләр. Аны гел пешермиләр. Сөт белән ашыйсың. Соло ононнан пешерәсең аны. Мин үзем кичтән изеп ҡуйам, иртән пешерәм, җә төшкә. Әче кергән була аңа».

Сөйләүче: Кәримова Таһира
Бәдегытдин кызы (1937)

Салтык Ерыклы авылы. «Көндәлек ашлар дип, балан дәwешләмәсе (пирогы), ҡабаҡ бәлешләре салыр ыйыҡ, күзикмәк пешереб аласың. Белен пешерәсен асат ҡына. Күмәчләр элек бик йуғ ыйы бит инде.

Минем әни борчаҡ wалмасы (юка төче күмәч) пешерер ийе, и йаратадырыйым. Ашамныҡлар күб ул, дучмаҡ, бөккән пешерерләр ийе, киндер орлоғыннан, җылғыр бик тәмне буладыр ыйы йаратҡан кешегә, шул эремчек пилмәне ул. Ипи салғандә табада көлчә пешерер ийек, майың булса манчып-манчып та ашасаң бигрәк әйбәт инде. Уразада сәхәргә әлбә пешергәннәр, үзе тәмне, үзе туҡлыҡлы. Баwырсағ инде йахшы ҡамырдан, көрпәчәткә ононнан.

Көлчәне өй күтәргән wахытта пешерергә кирәк. Ботҡа да, нигез ботҡасы да булыр ыйы. Салам үрегә килерләр ийе, әбизәтелни көлчә булыр ийе, хәзер ҡабартма инде. Боткасы өйнө күтәреп бетергәченнән, көлчәне йарты күтәреп бетергәченнән булыр ийе.

Матчаны ағачтан тәгәрәтеп меңгерерләр ийе. Астына доғалар йазалар да, тығып қалдыралар. Өстә – қоро қолоқса, өрлөк аста бездә, аңар идән сайғаклары җәйәсең. Димче йортқа доға қылғанда теге йағына, түр йағына утырыға қушалар инде».

Сөйләүче: Нуруллина Нурия
Гыймади кызы (1939)

Үрәсбаш авылы. «Бейем қабыртма пешерде дә киштәгә қуйды, ди. Дурычмақ (пәрәмәч) пешерәбез без. Ит суйсаң, пирмәнкә йасыйбыз. Ашығыч булса тәбә (белен) итәм дә салам.

Элке күмәч-ипей саладыр ыйы нәнәй, соло ононнан булыр ыйы. Қалачны җә базардан, җә җәрминкәдән алып қайтырлар ыйы. Қыссаң, бер учқа сыйып бетәдерийе.

Баwырсақ әчедән була, чишарадан олорақ була ул. Чишараны майда ғына пешерәләр».

Сөйләүче: Гаврилова Анастасия
Максим кызы (1930)

## Үсемлекләр турында

Купка авылы. «Җийабыз қычытқан, ақбаш, кәҗә сақалы, күшә, бабай күшәсе, җонно күшә, аның төбө бәрәңгеле. Қақы ашыйдырыйық, әчкелтем, сары чәчәкле. Қарлығаннар үсәр ийе, җийар ийек».

Сөйләүче: Хәсәнова Саимә
Сабирҗан кызы (1928)

Кәркәвеч авылы. «Дусайны (какыны) йаратам мин, әчкелтем. Җәй башларында эзләп ашап җөрим. Қузғалақ өч төрлө бит ул, қуйан қузғалағы, ат кузғалағы, кеше қузғалағы. Сандуғач гөлө бар ыйы аларда, wақ-wақ җапрақлы, wақ қына ал чәчәк ата, тәрәзәнең башына элеп қуйалар ийе. Кәҗә сақалы да әчкелтем. Аның сабағын ашасаң, ирен қабарып чыға, иренгә тигезмичә генә ашарға аны. Җуwа да бар бездә. Черег аланда үсә, гел сарымсағ инде ул».

Сөйләүче: Гыйльфанова Рузия
Рәхимулла кызы (1938)

## Гореф-гадәт, йолалар

Кәркәвеч авылы. «Элек бала туғач қына йазылышу булған. Бөтөн кешенеке шулай булған, бала туғач қына йазылышқаннар. Никах уқытқаннар да қыз бер йыл өйөндә тора, кийәү кийәүләп йөри булған.

Қайсысы йабышып чыққан. Безнең нәнәйне (әнине) этәй тәрәзәдән урлап чыққан. Пуп малайына чығам, дип қурқытқан Заһидә әби, безнең әби белән бабай шулай өйләнешкәннәр.

Килен төшкәндә бийем қаршы ала, төклө айағың белән, дип. Тәмне телле булсын дип, бал белән май қаптыралар. Қызны «мунчалаң кипмәсен, қолғадан кереӊ төшмәсен» дип өйрәткәннәр. Төшү белән килен туқмачы кистергәннәр. Икенче көннө туқмач ашы уздыралар.

Сорап килә булғаннар қызны, атасы, анасы килә сорап. Қызның ата-аналары да сораштыралар, бийемен сорыйлар: Җортоңда быздың бармы? Теге йақлар да сораша, қызның әниләре бармы? дип.

Бирнәне қыз әзерли күб итеп. Җегетнең анасы никахқа 2000 сум ақча, җеборған (юрган) алып барды, бусы бүләккә керми әле.

Туйда бүләк бирешү бар.

Бөтөн өстендәге кийемен салдырып алып қалалар, өр йаңа баштан кийендерәләр. Ишек қатыннан үткәрмиләр, җаза бирәләр қыз йағы туғаннары.

Йаучы элек булған, димче шул түгелме соң ул.

Йәш килен йаулық йапқан (тел яшергән), ирләр белә сөйләшмәгән, хәзер андый жуғ инде.

Ибәтел-җул мулла булған. Хатыны үлә, дүрт бала белән қала. Икенче бер мулланың қызын сорый, Зәйтүнә апаны. Килешкәннәр. Зәйтүнә апа белмәгән балалары барын. Дүрт бала җийылышып кергән. Апа шулар белән чана шуwып йөргән. Ибәтел-җул үлгән. Бикләннән йәш мулла җибәргәннәр. Шул Нуруллаены йортқа керткәннәнәр Зәйтүнә апаға.

Киленнең кижеле башлы сөлгөләре була. Килен сөлгө бирергә тийешле сабан туйына.

Сөлгө җийу була бит сабан туйға. Иртәгә сабан туйы дигән көннө була ул. Аннан алда дәрә була әле. Күкәй җийалар, тағын нәрсәләр шунда.

Дәр-дәр дәрәки,
Иске-москө кәзәки.
Кәзәкигә ут қапқан,
Бөтөн аwыл шаққатқан.

Ай, диләр, wай, диләр,
Хәдичә әбине бай, диләр.
Ике қадақ май, диләр.

Дәрәләрен (биргән әйберләрен) алып чығып китәләр. Кичтән дәрә ботқасын пешерәләр, анда борчаған да була. Бер тапқыр йоморқасын кибеткә ыздайт иткәннәр ийе. Дәрә җийғанда йармалар, майлар бирәләр. Ботқаны пешерәләр зур қазаннар асып. Аның пешерүчесе айырым була. Балалар килеб ашый. Беренче майда була ул дәрәки.

Сабан туйға йаулық җыйғанда хәзер мулла ачып җибәрә.

Җаңгырлар җаумыйрақ торса да, ботқа пешереп сорыйлар. Бездә пасаткыға намаз уқырға баралар. Сорыйлар уқый-уқый. Ботқа да йуқ, йалварып сорыйлар.

Җаңгыр җау, җау,
Алла бабай, ипи бир,
Безнең сарық абзарда
Тәти қашық базарда, –

дип тақмақлап та китәләр. Су сибешәләр урамға чығып. Үткән бөтөн кешегә тоталар да бәрәләр суны чиләкләп. Уйын бит инде ул, берсе дә ачуланмый да. Қайсы wақыт йаңғыры да йаwып китә шунда.

Бездә тағы күрингә бару дийер ийек. Йәшләр гармун асып урманға баралар, уйыннар уйныйлар. Қызлар қайсы сөйләшеб утыралар, җегетләр белән дә сөйләшеб утыралар. Түгәрәг уйыннар уйнап, бийеп, җырлап күңел ачалар ыйы. Назалы уйнайдырыйық».

Сөйләүче: Якупова Хәдичә
Мансур кызы (1922)

А д а й  а в ы л ы. «Иңгелек сарықтан қубарасың җонно. Тетәсең, машинасы бар аның. Анан әwәлисең, айаққа килешле итек була, тукмағы бар суға торған. Баш қалыбы айырым, қуныч қалыбы айырым. Пичкә тығасың басқач. Кипкәч тартыб аласың қалыпларын.

Ул тауда қап-қара урман булған. Берәүнең қызы йуғалған Зөhрә исемне. Әйткән: тапсам, ботқа ашатырыйым. Шуннан Dәрә тау булып қалған Зөhрә ботқасы. Ботқа дигәннең пачуты зур булған. Туй йасасы булса да ботқа пешерерләр ийе. Аны қапқа төбөнә малайларға апчығып таратырлар ыйы. Элек сабан туйы булыр ыйы. Йаз чығу белән малайлар күкәй җыйарлар ыйы. Малайлар күкәй җыйып қайтқач, сөрән чығыр ийе. Узышқа чабышып сөрәнгә чығалар. Иртән торуға без қычқырыр ыйық. Қызыл башлы тастымалдан қапчық тегеп бирерләр ийе. Дәрә (Зөhрә инде) ботқа пешә дә икенче көннө малайлар күкәй җыйа. Шул көннө ат чабышы була. Унар

ат барыр ыйы. Күкәй җыйған көннө әйбер җыйалар ийе. Өйләнешкәннәр сыра қуйарлар ыйы. Килен қызыл башлы, киҗеле башлы сөлгө бирә торғаннар ийе.

Җыйында қунақлар килә. Аш-су итәсең. Йәшләр-қызлар уйынныққа баралар, мәҗлес ийе. 22–23 ләрендә Йансыбы җыйыны, аннан Адайда, Күкшел, Йәнил, анан соң Мәмәширдә. Туйымбашлар тәкә атнасы дийер ийе. Мим малай wахытта бара торған ийем, әни минем Туйымбашныққыйы. Қайтадырыйық та печәнгә чығадырыйық, печәнгә төшәрләр ийе. Мәмәшир белән бер атнаны булыр ыйы Туйымбашта. Dаманы шундый булған, без аны белмибез дә сөйләргә дәген. Сабан бетте, чәчеп бетердек – қаты суқа, арыш чәчәргә җир әdерли. Элек фәләнчә җир дип сөйләшкәннәр. Бер җир була буйға ике йөз митер, иңе дүрт митер бер кешегә. Бу басудан ике җир, теге басудан ике җир тийә тар ғына. Син печәнең миңа биресең, мин синең қаты суқаны суқалыйм, дип килешеп қуйасың. Җирне бүлгәндә җирәбә салалар. Элек ишле булған бит. Менә без ун симийә тордоқ, әйбәт тордық, тауыш-қауға булмады».

Сөйләүче: Минегалиев Корбан (1918).
1982 елда язып алынды

Төркәш авылы. «Сөрәнгә, сөрәнгә, дип күкәй җийулар бар ыйы. Хәзер жуқ. Балалар да әз инде хәзер.

Кеше сайын жөрөп, суқаға чыққанда да жыйа торғаннар ийе. Суқачыларға да пешергәннәрдер, чәчкән wахытта җиргә дә чәчеп җибәргәннәр, йоморқалар күк тәгәрәб эшләгез, игеннәр туқ булсын, диптер инде. Бергә җийылыб ашыйлар суқачылар да шунда. Ничә ат, ничә кеше эшләгәннәр.

Дәрә-дәрә әйтү бездә йуғ ул.

Сабан туйы эшләр беткәч, сөлгө җийалар, сөлгө җийу, диләр. Гармун белән үзебездә җырлана торған җырларны җырлыйлар.

Гармуннар белән чығалар инде. Элек бар ыйы, су быйына төшөп уйныйлар ыйы кичке йақта.

Мәйдан, диләр, сабан туйының көрәш бара торған җире мәйдан. Хәзер синтырда барамы көрәш, шунда. Сабан туйы элек монда су буйында булған, көрәш тә булды, герләр күтәреп тә йарышалар, ирләр, хатын-қызлар йөгерешләре. Мин қорсақлы көйөнчә өченче урынны алдым әле мин».

Сөйләүче: Сәләхиева Хәдичә
Зәкиҗан кызы (1924)

Оштырма Юмья. «Олы көн (пасха) апрель айында була, қаз пешерәләр, бутка пешерәләр, кем нинди йарма апкилә. Без үзебез плаw пешерәбез. Борай йармасыннан пешердек. Үзенен туғаннары белән қунаққа йөрөшә инде. Ипи пешерәләр. Энекәшләр, сеңлекәшләр, балалар килә. Сездә доға қылалар, ә бездә чукыналар. Алла бабайдан, Ходайдан сорыйсың. Искесен ашыйсың, йаңасын тағы бир, дип. Йәш wахытта йомырқа тәгәрәтеп уйныйдырыйық. Ничә кеше уйный, шунча чоқор йасыйлар ийе. Кечкенә генә, йоморқа сыйарлық қына. Бала-чаға күкәйне җыйа, ашыйлар ийе, ә уйнарға да қалдыралар ийе.

Башта пасхада түбәнтеннән җуғары менәләр, ә аннары була инде, қартлар бәйрәме була. Ансында өстән бу йақтан те йаққа төшәләр инде. Зиратқа таба дип. Ансы қартлар бәйрәме инде, пасхадан соң. Бонда җыйылдық, тағын икенчесенә барабыз җыйылып, өчөнчөсенә, дүртенчесенә барабыз. Пасхада сөйләшеп утыралар, ашыйлар, йоморқа, ботқа ашыйлар бар да бала-чағасы белән.

Мине чуқындырғаннар өйдә генә, утызынчы йылны бетергәннәр инде чиркәүне монда. Әле менә тағын ачабыз, дип маташалар. Бер-ике йәштән күбрәк чуқындыралар. Мине өчөнчө йәшемдә чуқындырғаннар. Бабай, поп бабайы килгән. Чиркәүне йапкач, қушмағаннар, ди, чуқындырырға. Кешедән йәшереп кенә, безнен өйдә дүрт кеше чукынған менә. Кирос таққаннар, бирәләр ийе.

Аwыз ачу баштарақ, қашмару соңыннан була. Пасхага хәтле булса, аwыз ачу, уразаны аwыз ачалар инде аннары, ашыйлар. Итле әйбер ашамыйлар инде. Аwыз ачу – әнә шул итле әйберләр ашый башлыйлар инде. Татарлар кич соң ашыйлар, безнен ит, май, сөт ашамыйлар, шундый ураза.

Өй бөренча йөрөп нардуған йөрдөләр. Бабайға чығу, диләр безен монда. Үрәсбаш йақлары «нардуған» диделәр, ә безен «бабайга чығасыңмы», диләр. Кеше төрлөчә кийенә – бабай булып та, қыз булып та. Өч-дүрт кеше өйгә кереп йөри. Берсе сатучы була, берсе бийүче була, берсе җырлаучы була, берсе сату итә. Йоласы булғач, сатып аласың инде. Бабайга чығасыңмы, дип сөйлиләр».

Сөйләүче: Васильева Анастасия
Архип кызы (1928)

Ятмас Дусай авылы. «Сөрән тақмағын берне беләдер ийем әле.

Абыстайлар, түтәйләр,
Чығарығыз күкәйләр.
Ак чүперәк, күк чүперәк,
Чығарығыз күберәк.

Сөрән иртәгә мәйдан дигән көннө булған ул».

Сөйләүче: Галәветдинова Зәкия
Фәйзерахман кызы (1926)

Шепшеңәр авылы. «Безнең әней жырлый торған ийе:

Балаларым, ғәзизләрем,
Қаласыз бит бик йәш сез.
Әнекәгез искә төшкәч,
Белмим, ничек түзәрсез.

Аwадағы асыл қошно
Тотойм дисәң, тотоп булмый;
Қара жир астына кергәч,
Сағынсаң да, күрешеп булмый.

Әнкәйем исән чақта
Эрәхәтләнеп жөрдөм микән.
Әллә берәр хаталықтан
Жәтимнәрдән көлдөм микән.

Қәберемне тирән қазығыз,
Ақ таш қуйып йазу йазығыз».

Жырлаучы: Газизов Гаптелкаим
Газиз улы (1931)

Сәрдекбаш авылы. «Сабан туйны элек сабан чәчәргә чыққанчы йасый торғаннар ийе. Тирәсе-тирәсе белә, бу аwылда бер көнне, бу аwылда бер көннө йасыйлар ийе қунаққа йөрөр өчөн. Туйымбаш жийыны – печән житәр-житмәстә генә, ураққа төшкәнче. Иң беренче жийын. Мәмәшир жийыныннан қайтқач, ураққа төшә торғаннар ийе. Безнең аwылда ийүннең азақларындарақ була торған ийе. Беренче безнең жийын, икенчесе Сәрдек, Чишмәбашлар, аннары Йансыбыда (авыл исеме) була торған ийе. Андары Мәмәширнеке иң азақтан. Атна кич, жомға көн була торған ийе ул жийыннар. Сабан туйы белә жийынның айырмасы шул: халықтан жаулық жийып йөриләр, ә жийынның ике көн, өч көнгә дә бара торған ийе. Жийында қунақ чақыралар, йәшләр су буйында була торғаннар ийе. Жийында эш булмый. Иртән ашағач, йал иткәч, менеп китәдер ийе, су буйында икенче башқа. Кичен – кичке уйынға. Түлке мулла рөхсәт итми торған ийе.

Сабан туйы иртәгә дигән көнне кичкесен дәрә итәләр ийе, дәрә ботқасы була. Дәрә қычқыралар: “Дәр-дәр дәрәгә, иртә торсаң күкәйгә, берсекөңгә сөрәнгә. Йә дәр-дәр дәрәгә, иртә килгән ботқаға, суңа қалғанға жуғ ыйы”. Жарма жыйып жөриләр ийе, дәрә

қычқырасы көннө йәшләр үзләре җийылып пешерәләр ийе қазан қуйып. Ир-ат җегетләр бер җиргә утырырлар ыйы, хатын-қыз, бала-чаға бер җирдә. Ашарға күкәй җийасың, қайсы чикләwек, қайсы қызыл билле перәннек, қайсы қызылға буйаған күкәйне. Қызыл билле перәннекне әниләр белән җийынға бара алып торғаннар ийе. Қайда қызы бар – шунда. Басу қапқасы була торған ийе. Шунда қапқа ачучы малайларға ташлап китә торғаннар ийе. Сөрәндә атларға атланып, сумка кийеп, күкәй җийып йөриләр ийе. Җийып бетерер алдыннан, жыйғаны качарға чамалый торғаннар ийе, аны қуwып китә торғаннар ийе. Аны бүлгәннәр, ашағаннар, таба алмағаны шул көйө қайта. Сабан туйы көннө иртүк жыйа торғаннар ийе күкәйне. Үзенә тийешлерәгенә генә күкәй бирә торғаннар ийе, пешергәнне майға салып».

1994 елда язып алынды

Ш е п ш е ң ә р  а в ы л ы. «Сабан туйлары алдыннан башта малайлар күкәй җийарлар ийе. Аның тақмағы да бар ийе бит әле. Элек қапчықлар тегәрләр ийе җә сөлгөдән, җә нәрсәдән шунда. Шуны тотоп өй борончa җөрөрләр ийе.

Абыстайлар, түтәйләр,
Чығарығыз күкәйләр.
Ақ чүпрәк, күк чүпрәк
Чығарығыз тизерәк.

Әзерләнә инде халық. Йоморкасын буйап қуйа шунда, күкәйе булмаса, шишара булса да пешереп қуйа. Шуннан аны алып қайтып бала-чаға җә утырып ашар ийе, җә уйнарлар ийе шунда.

Дәрәсе аның җаз көнө қар бетү белән буладыр ийе. Бала-чағалар урам буйынча сөттөр, җармадыр җийарлар ийе, онмы шунда, шулардан ботқа пешерер ийе бер оло кеше. Ботқа пешә торған ийе дә балалар андан суң җөгөреп қайтып саwыт апкитә торғаннар ийе. Шулай итеп бүлеб ашый торғаннар ийе. Аны безнең ише оло кешеләргә, йаңғыз карт-қарчықларға, әбиләргә дә китереп бирә торғаннар ийе. Иртүк тороп шунда балалар дәрә қычқыралар ийе.

Дәрә-дәрә дәрәгә,
Иртә торсаң сөрәнгә,
Берсе көнгә сабанға, –

дип қычқыралар ийе.

Ботқа пешә-пешә
Қазан төбө төшә-төшә.

Андан ары тағы йаңғыр җаумий башласа:

Җаңгыр җау, җаңгыр җау,
Сөтлө сийыр абзарда,
Ботқа пешә қазанда,
Тәти қашық базарда, – диләр.

Болар элек инде, без бәләкәй чақларда».

Сөйләүче: Газизов Гаптелкаим
Газиз улы (1931)

Ядегәр авылы. «Қарға ботқасы йаз көнө тау буйында буладырыйы. Һәркем йарма әпкилә, итенме, күкәйенме. Бөтөнесен җийып қайталар да кич белән халықны җийып, тау буйында пешереп ашый торған ийек.

Зәрә боткасы ул йазгы қыр эшләре алдыннан була.

Бирнә җийу, дибез без. Сабантуйға бер өч көн қала җийылышып, кешеләрне чақырып бирнәне җийадыр ийек. Элек бик күңелле ийе ул бирнә җийу. Хәзер қартлар да сүлпән. Хәзер мин җәшләрне апчығам. Башқа, иң алға бабайлар баса, гармунчы уйнап, бабайлар җырлап бара. Аннары қолға тотоп баручылар. Иң башына чиккән матур сөлге. Қулйаулықларны гармунға бәйлибез. Арттан хатын-қызлар тезелешеп баралар. Иң арттан малайлар килә канфит җийып. Җомортқа бик җиймыйлар. Алдарак, әнә шул дәрәдәме, алдарақмы булған йомырка җийу».

Сөйләүче: Хәсәнова Сания
Хәсән кызы (1931)

Кенәбаш авылы. «Йаучы, диләр, электер инде ул. Безнең заманда туй да йуқ.

Элек сөйлиләр ийе, кече қызын сорап килә дә йаучы, аталары “менә олосы бар, анысын ал” дип тә әйтә. Шундый хәлләр дә булған.

Безнең әни қунаққа килә. Әти күршедә генә. Ул инде әрмийәдән қайтқан була. Ул әнине күреп қала да бик ошата. Шул килгәннән әти әнине ала да қала. Аннан соң “кызыгыз бездә” дип атасы җә туғаны бара. Қайсысы терерәк, йөрәклерәк, шул бара. Аннары никах уқыталар. Қайсы кеше қыз өйөндә, қайсы кеше малай өйөндә уқыта.

Оло малайының хатыны бийатасы белән сөйләшмидер ийе. Тел йәшерә, диләр ийе».

Сөйләүче: Нәбиуллина Галия
Заһретдин кызы (1944)

**Зәрә такмаклары**

«Зәр-зәр зәрәки,
Иске-мосқо кәзәки.
Мин бай, диләр, бай, диләр,
Бер гөрәңкә май, диләр.
Зәр-зәр зәрәгә
Иртә тороп зәрәгә
Берсе көнгә сабанга, –

дип, балалар қычқырышып күкәй җийарлар ийе».

Сөйләүчеләр: Минһаҗов
Миңнегали Миячтин улы (1939),
Нәбиуллина Галия Заһретдин кызы (1944).
Кенәбаш авылы

**Дәрә**

«Йаз көнө иң башта балаларныкы була торған ийе сабан туйы. Дәрәләр пешерделәр. “Дәр-дәр...” дип җийып җөриләр балалар күкәйен, җармасын. Аны пешерәләр. Бәк күңелле бит ул. Балалар күкәй тәгәрәтеп уйнарлар ийе».

Сөйләүче: Нуруллина
Нурия Гыймади кызы (1939).
Салтык Ерыклы авылы

**Аулак өйләр, уеннар турында**

С а л т ы к  Е р ы к л ы  а в ы л ы. «Аулағыйлар булды. Пилмәннәр пешерер ийек, җегетләрне кертмидер ийек. Ачу белән қапқаларына берәр нәрсә сөртеп киткәннәре дәген буладыр ийе.

Төрлө уйыннар уйнар ыйық. Тычқан салыр ыйық, жырлар ийық. Йазаңы үти алмасаң, қайыш белән сuқтырыш ыйы. Мин үзем бер дә суқтырмадым. Жырға да остайым.

Алма қойолған жиргә.
Жырламый да булмас инде
Дуслар жыйылған жирдә.

Җегет кылупқа чыға икән, айағында ақ итек.

Сабан туйлары булыр ыйы. Күршеләрдән калуш алып китәр ийек сабан туйға. Әйләнешле уйныйдырыйық, җырлыйдырыйық аwыл көйләрен. Бер турны (чорда) бетте бит ул, хәзер тағын башладылар сабан туйын.

Қапқалы уйнар ыйық, берсен аласың да астан чығып китәсең».

Сөйләүче: Нуруллина Нурия
Гыймади кызы (1939)

Быжа авылы. «Әйләнеб уйныйдырыйық уйында, җырлар җырлый-җырлый:

Сиблә чәчем, сиблә чәчем,
Сиблә чәчем сул йаққа;
Озақламый үзем китәм
Чәчем сибелгән йаққа.

Аулағыйда тычқан салу уйныйдыр ыйық, табышмақ әйтү булыр ыйы, онотылып беткән инде табышмақлары да. Өй түбәсендә җарты қалач, тип.

Тағы түшәм санашалар ийе, түшәмне санаталар ийе, җолдыз санаталар, җиңнән қарап санаталар. Бер шайанрағы, берсе китереп су сала торған ийе.

Җырларны онотоп бетергәммен шул.

Эчиг әле балларны,
Бал бетерми малларны;
Анадан туwа бер бәхетсез,
Шул бетерә малларны.

Алма бақчасына элдем
Алмалы паласымны.
Өзөлөп сөйдөм, белеп сөйдөм
Йатларға қаласымны.

Исемнәре Әхәттер;
Кеше йарын айрыб алып
Сөйүләре рәхәттер».

Сөйләүче: Гарипова Факиһәбану
Галим кызы (1917)

Камышлы авылы. «Бездә Чимек буладырыйы, уйыннар уйныйдырыйық. Җәшләр, қызлар күңел ачадырыйық.

Кич белә уйынныкта җырлап уйнар ыйық.

Наза дигән қыз баланың
Бөрлөгәне түгелгән;
Көн дә наза уйнағанға,
Наза чықмый күңелдән.

Җырлыйғ әле иптәшләр.
Иптәшләр үзебезнеке,
Бәлки ғайеб итмәсләр.
Җырлыйғ әле, җырлыйғ әле

Уникегә тулғанчы;
Уникеләргә тулғанчы,
Дуслар күңеле булғанчы.

Бездә атнакич зиратқа баралар келәү итәргә, нәсел-ыруқлары белән аралашып қайталар.

Бездә бит ике төрлө халық. Чуқынғаннар белән чуқынмағаннар бергә йәши дә, чуқынмағаннарнықы күмүләре мөсөлманча».

Камышлы авылында
2011 елда язып алынды

Кара Елга авылы. «Аулағыйлар булыр ыйы, бер аулақ өйгә җийылалар да қызлар, йәшләр, уеннар булыр ыйы. Қул суғышлары уйнап ис китәдер ийе.

Бийәләй атышлы. Монoң артыннан кем қайтты микән, дип, бийәләйне аталар.

Бармақлы уйын уйнар ыйық. Бер кулны бармақларын җәйеп өстәлгә қуйасың да икенче қулның имән бармағын өстәлдәге қулның бармак араларына төртеп-төртеп чығадырыйың. Аннары икешәрләп қуйасың бармакларны. Аның җыруwы да бар әле:

Челтәрле күпер астында
Алмалы патнус йудым.
Ал қулыңа, сал қуйныңа,
Мин синең өчөн тудым.

Шешә тәгәрәтешле бар ыйы, сездә дә булғандыр ул.

Усал сарықлы: өйалдына чығып йегет тик тора. Өйдән “бу чықсынмы? бу чықсынмы?” дийеп әйтәсең, бу эндәшми. Чықсын дисә, йегет тыпырдый. Туры килгән берәү чығып керә. Усал сарық тышта торғаны, чықсын дип тыпырдап тора бит».

Сөйләүче: Мөхәммәтҗанова Мәгъсүмә
Тимергали кызы (1936)

Оштырма Юмья. «Без йәш wақытта керәшеннәр үз алдына җыйылып җырлыйдырыйық. Садта уйныйдырыйық. Кибет артында ағач киртә белән әйләндереп алынған бақча, күңелледерийе. Кич белән күп чығалар ийе қатыннар, ирләр, йаңа өйләнгәннәр, безне күрергә, қызларны. Керәшенне белеп буладырыйы. Керәшенчә киенделәр. Хәзер бар да: керәшен дә, удмурт та рус күлмәге кийә инде. Урам көйө дип, әйләнеп бийеп җырлый торған ийек. Наза

уйыны уйныйдырыйық, гармун белән җырлап, әйләнеп. Бик зур буладырыйы, ике қат».

Сөйләүче: Васильева Анастасия
Архип кызы (1928)

Починок-Кучук авылы. «Аулағыйлар буладыр ыйы. Қызлар җыйылышадырыйқ. Кем нәрсә алып килә, аларны пешерәдер ийек, күберәген ит бәлеше инде. Җегетләрне кертмидерийек башта. Анда төрле-төрле уйыннар уйнар ыйық: қул сугышлары, назалы, качышлы, тышқа чығышлы. Төртке җырларны җырлый торған ийек.

Бала wакытта чебенне уйнар ыйық. Бер қазық қағасың, башына бәләкәй генә әйбер қуйасың беркетеп, чебен инде ул. Қаққан қазыққа бер әйбер белән атасың. Чебен оча әллә қайларға. Барып ала да чебенгә тағы бәрә.

Такта башы. Бәләкәй-бәләкәй чыраны бер унны қуйасың тақта башына. Тақтаның икенче башы күтәрелеп тора. Берәү тақта башына тибә. Теге чыралар очоп китәләр. Син җийасын, син җыйып бетергәнче теге тағын килеп тибә.

Шәртләки уены. Шәрә қалағы җә туп, җә җоннан йасыйсын. Қалақ белән тупқа бәрәсен.

Урман буйына төшәрләр ийе җегетләр, гармун уйнап, җырлар җырлап. Алар артыннан без – қызлар төшәр ийек. Чулпылар челдер-челдер, беләзекләр кийеп қара көмөштән. Чулпының уртасында ахақлар йалық-йолоқ итеп торор ийе».

Сөйләүче: Кәримева Таһира
Бәдеғытдин кызы (1937)

## Риваятьләр, бәетләр

Купка авылы. «Бер бабай әйткән: элек биш митырлы кешеләр булған. Урманны қамыл дигәннәр, қамыл дийеп җөргәннәр. Аннары без җаралғамбыз. Бездән соң тез хәтле генә кешеләр чыға, дигән. Ахыр заман алдыннан Истамбул халқы җиңә, диде. Мин сорадым, Истамбул бармы? Кемнәр алар дип. Алар төрөкләр, диде. Қойаш боролса, икенче йақтан чықса, донжа бетә, диде.

Дөнжа қуған михнәтә,
Һәр мәшәқәт dәхмәтә,
Төрлө-төрлө ғазапта,
Аллаһ, диген бадуwам.

Дөнйаны сез қумағыз,
Күп малларны җиймағыз.
Барын қуйып китәрсез,
Аллаһ, дигел бадуwам.

Бер фәқыйр қарт булған. Балтасын кыстыра да чығып китә. Үзегезне атағыз күк тамуқ утына салмағыз. Бәйете мондый.

Иртә тордо, битен җуды,
Балта тотто қулина.
Балтасына бер қарады,
Чығып китте җулына.

И балалар, белмисез бит,
Туйа күрмәде күзләрем,
Сөйләп битмәде сүзләрем,
Айырылам ки сезләрдән...

Менә бу зур өй, хуҗасы ташлады да китте, җенле урын, дип. Җеннедер инде. Өйөн салды чүплег урынында, малайы афғанда үлде. Хатыны белән айырылдылар. Икенчегә йортқа барып керде. Өйдән чығарып өйә балчықны, башқа җирдән алып қайтып тутыра. Өйөн сатмый да, сорап та қарадылар».

Сөйләүче: Хәсәнова Саимә
Сабирҗан кызы (1927)

## Ышанулар, ырымнар

Кара Елга авылы. «Қарға ботқасы укмуртларда. Ботқа пешереп Алладан сорыйлар, үзләренчә теләкләр телиләр. Бездә йуқ бит ул.

Бездә қырға чығып намаз уқығаннар қороға китсә.

Чөмәрчеккә чығалар, кем булса да су сибәсен. Йаwа ул йаңғыр, туры киләме. Суны, кем туры килсә дә, сибәсен.

Сабан туйына йаулық җийғанда бер тақмақны беләдер ийем әле:

Исәнлектин, саулыктин,
Тазалықтин, байлықтин.
Бер бәйләрлек йаулықтин, –

дип җырлашалармы шунда.

Балалары туwа барған, үлә барған, бишәү үлгән. Тимер үлмәс тийеп, Тимерғали дип қушқаннар минем әтигә.

Балаға күз тимәскә булафканы сул йақ күкрәк турына башы белән асқа қаратып қазарға, ди торған ийе әнинең тәтәсе.

Арпаны нәрсә белә имниләр, менә шулай төртөп-төртеп.

Очқолоқ тотқанда нахақ бәла йағалар, нахақ сүз әйтеп ачуwын чығаралар».

Сөйләүче: Мөхәммәтҗанова Мәгъсүмә
Тимергали кызы (1936)

Кәркәвеч авылы. «Йорт хуҗасы бар ул. Ул йорт ийәсенең йәрдәм итүләре шундый күп. Шулай мәктәптә эшлим. Йырақтарақ кәҗә бәкәйе таwышы килә. Мин әйтәм, қара, кәҗә бәкәйе чыққан бит сарайдан, дим. Бу тавыш йақынрақ ишетелә, ишеғалдына чыққандыр инде, дием. Хә, һаман да чықмыйм, борылмыйм. Арт йағымда қычқырды бу, өйнең түрендә бу. Сарайлар әллә қайда безең.

Арт йағымда чырр иттереп кәҗә бәкәйе қычқырды. Кисәк кенә боролып қарадым, бер җирдә бәкәй йуқ. Җөгереп чықсам, сарайда кәҗә бәкәйе муйыны белән асылынған, йарыққа башын тыққан, үлмәгән. Йорт хуҗасы хәбәр бирде, әйтте.

Истихара намазын уқырға кирәк. Сорап йатарға кирәк. Төшөңә ақ йә йәшел төс керсә, шуны эшлә, қара төс керсә, эшләмә.

Төш күрәм: ақ йоморқа җыйам.

Икенче төш күрәм: ирләр күлмәге, йәшел. Үзебезнең бақча башында җиләк. Ничег итсә итеп чықтым, уртасында йәшел әрем.

Йорт хуҗасы. Мине йыш қына намазға уйаталар, төрлө таwыш белән: йә шық итә, йә әтәч қычқыра. Кәҗә булып қычқырғаны абзар хуҗасыдыр.

Иске өйөгездә қалған йорт хуҗағыз, диделәр, күчерегә қуштылар».

Сөйләүчеләр: Якупова Хәдичә Мансур кызы (1922),
Гыйльфанова Рузия Рәхимулла кызы (1938)

Салтык Ерыклы авылы. «Йорт ийәсен мин үзем белән апмендем. Табағачқа атландым дағын, “әйдә, минем белән”, дип алып қайттым. Пич йақсам, йоқлап китсәм, уйаталар. Уйансам, пич йанып беткән, күмере әле өйөлөп тора.

Арпа чықса, имниләр аны, қайсы арпа белән, қайсы қукиш күрсәтеп. Бер, ике өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, туғыз, туғызда тузып китсен. Туғыздан башлыйлар, бергә тикле баралар: җидедә җилгә очсон, биштә бизеп бетсен, өчтә очоп китсен, бердә берлексез булсын. Минем қулым түгел, Ғәйшә-Фатыйма кулы, дип төкөрәләр дә, бетә ул.

Элек таң суwы алучылар бар ийе. Таң алдыннан ипләп кенә төшәсең дә шишмәгә, таwышсыз ғына алып қайтасың, аны өшкөрәсең, йә берәрсеннән, белүче қарчықлардан өшкөртәсең. Аннары шуның белән қойонасың. Балаға күз тисә дә, шуның белән қойондыралар, җә битләренә сөртәләр. Пайдасы тийә торғандыр инде, тимәсә эшләмәсләр ийе».

Сөйләүче: Нуруллина Нурия
Гыймади кызы (1939)

«Энем булған ийе. Күз тийереп үтерделәр. Ах, бу минем шундый улым бар ийе дип, йаратып-йаратып сөйде. Шуннан алып кердем энемне, үзен-үзе атып тәгәри башлады. Шулай итеп үлде ул энем. Шаққатмыш бит бу».

Үрәсбаш авылы. «Қурықса қурқылық қойдоралар.

Икарада ағач бар. Анда беленә диләр. Өлү түтәй әйтә, килеп чықты, ди тәгәрәп ут, қурыққан ыйы.

Кеше үлгәченнән қырық бер күмәч wақ қына итеп пешерәләр, шуны сарықларға ашаталар, үле қырық бер бачқыч менә икән, кешедән алып ашап тора. Қырығы тулған көннө өләшкән белән бурычын түли.

Үле чығуда хәйер бирәсе, эссе сала, қоймақ пешерәсе. П'аска алдында үле чығу буласы, шулай эшләмәсәм төшкә керә.

Берсесендә мунчам тартылып китте. Йаттым ғына, тәтәйем мунчаң сыwығ ыйы, ди.

Өй өwәсе йаратмаса, мантымыйсың, ди. Килен бетереб үләм, син қара, дигән. Нигезне җаңартмыйм, ди. Сабый әби бик килде, әтейемә эш эшләтергә. Зерәге эшетмәс булды, қаршы қарады. Түбән өйгә төштем дә бутқа пешердем. Нигез бутқасы пешереп алып төшөп, нишәтәләрдер.

Өй салғач, өй өйәсен чақыралар, почмақ сайын чақырып кертәләр келәү итеп.

Элек ат асырыйлар. Өй өйәсе җаратмаса, мал мантымый, ди. Күргән кешеләр булған аны: атның җалын тарап торадырыйы, мин чыққач җуққа чықты».

Сөйләүче: Гаврилова Анастасия
Максим кызы (1930)

Олыяз авылы. «Әнийем сөйләгәне буйынча. Әни әйтә күрше Сабираға кердем, өй аллары буш. Элек өй эче буш булған – урындық та, эскәмийә, өстәл, сәке булған. Өй аллары буш ыйы, ди. Килеп керсәм, почмақта бер хатын-кыз утыра, чәч тарап утыра, ди. Шуңа күрә ишекне ачқанда, һәрвақытта тамақны қһм-қһм дип қырырга кирәк, ди. Сабира дип эндәшмәкче булдым да, ди, кылт итеп исемә төштө – эндәшергә йарамый. Йорт хуҗасы Сабирәттә булған бит, шуңа, Сабирәттәй, нишләп утырасың, дип эндәшергә уйладым, ди. Эндәшмичә ишекне яптым, ди. Йаңадан ачсам, бер кеше йуқ, ди».

«Күршеләрдә тыныч булмаған, әти сөйләве буенча. Бер килеп суларын, сөтләрен түгепме, бутап бетергән күршенең, суға сөт салғанмы. Бабай күргән дә, қуып йөри икән, күзенә күренгән, хәзер чығып чапкан. Бабай яңадан керсә, теге зур авыр чүмеч тотоп тора

икән. Күрше хатыны керә икән, бабай күрше хатынына суғып, башын йарған, бичураға суғам дип».

Сөйләүче: Якупова Нажия
Җамалетдин кызы (1943)

## Им-томнар

Сәрдекбаш авылы. «Қурқылық қойалар қурықса. Минем үземнең қойғаным да йуқ. Шул қурыққан кешене утырталар да, өстөнә ақ җәймә йаwып қуйалар. Қурғашынны эретәләр дә, суға салалар. Нәрсәдән қурыққан, шуның сурәте төшә. Шул қурыққан кешенең йанына таѓып қуйалар қурғашынны, қурыққаны бетсен, дип. Таң суwы алалар. Өч мәртәбә алып йуwындыралар кемгә күз тийә, ана шул аwыртқан кешене».

1994 елда язып алынды

Кенәбаш авылы. «Арпаны әбиләр имниләр ийе дә, бетәдерийе ул, Ходайның рәхмәте. Қызымның күзенә арпа чыққан, бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, туғыз, тузып китсен, ди. Аннары тағын саный, бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, җилгә китсен. Бер, ике, өч, дүрт, биш – бизеп китсен. Бер, ике, өч – очоп китсен, бер – берлексез булсын.

Күршедә Маһинурттай бар ыйы, арпа чықса, хыйбырут күрсәтеб имнидер ийе, менә сиңа хыйбырут, дип, күрсәтеп-күрсәтеп аладырыйы. Бетәдер ийе.

Бизгәк булса, қайсы өшкөрөп шунда, қайсы имнәп, Сабирә әбиләр, Кәшибәттәйләр өшкөрәләр ийе.

Мине әни сатыб алған, сөлгө биреп, Күчкән Көйөкнеке (авыл исеме) ул Марзийа апай. Менә шул Марзийә апа шулай дийер ийе, сатыб алды сине анаң, дидер ийе».

Сөйләүче: Нәбиуллина Галия
Заһретдин кызы (1944)

## Мәзәк

Сәрдекбаш авылы. Ике татар, бер чирмеш ауға чыққаннар. Бер тартар, бер үрдәк атқаннар, мылтықлары бер генә булған. Өч кешегә бер үрдәк, бер тартарны бүлә алмағач, муллаға барғаннар. Бүлгән өчөн бер үрдәк үземә, дигән мулла, ике татарға бер тартар, чирмешнең мылтыгы бар, ул таѓы атар, дигән».

1994 елда Сәрдекбаш авылында
язып алынды

# КЫҢГЫРАУЛЫ ПАР АТЛАРДА ГОМЕРЛӘР УЗЫП БАРА

*Флера Баязитова*

Кукмара төбәгенең сөйләше – әдәби телгә бик якын сөйләш. Халык телендә саклана торган җирле үзенчәлекләре белән ул урта диалектның казан арты сөйләшенә керә. Биредә күрше Балтач төбәге сөйләше белән уртак күренешләр булуы да игътибарга лаек.

Экспедиция вакытында без авылларда яшәүче халыктан сорашып, өлкән буын кешеләре белән сөйләшеп, бик күп этнолин-гвистик материал тупладык. Тематик яктан алар нигездә гаилә-көнкүреш йолаларына, бәйрәмнәр һәм борынгы ышануларга карый. Мәгълүматларны диктофон тасмасына яздырып җыйнап бардык, аларның күпчелеге рухи һәм матди культура үзенчәлекләрен чагылдыру ягыннан әһәмиятле.

Бу басмада Кукмара ягының рухи хәзинәләре үрнәкләре белән халкыбыз лексикасы сәхифәләрен тагын да тулыландыру бурычы куелды.

## Туй йолалары

Туй атлары, кияү белән киленне урам әйләндереп йөртү йоласы турында халыкта әле хәзер дә бик матур истәлекләр саклана. Бөтен авыл халкы туй килгәнне, килен төшергәнне карарга чыккан, шушы вакыйга өчен махсус әзерләнеп куелган әйберләр, туй бизәкләре булган.

*Кыңгыраулы пар атлар, чигүле ак мендәрләр, ястыклар, кызыл җурғаннар һ.б.*

– Атларны бизәп, кыңгыраулар тагып, кияү белән киленне урам җөртөрләр ийе. Кызыл журғаннар җабып, чигүле ак мендәрләр, җастықлар куйып. Тарантасқа утыртып җегет белән кызны урам әйләндерерләр ийе қыңгыраулы атлар белән.

«Туй килә, туй килә» дип урам тулы кеше булыр ыйы. Күңгелле булыр ыйы ул (*Чишмәбаш*).

– Тырантаска утырып, йастықлар, мендәрләр салып урам әйләнәләр ийе. Тырантаслары бик матур қараwы. Қыш көне булса, артлы чаналар булыр ыйы. Суықта қызыл җурған булган. Менә хәзер җыры да бар ич инде, үзегез дә беләсездер:

Мамық җурғаннарға төренеп,
Килен төшә бүген аwылға.
Борынғыдан қалған гадәт ул,
Аwыл чыққан қаршы алырға,
Йәш кәләшне күреп қалырға, – дип.

[Шагыйрь Р. Миңнуллин язган бу сүзләрнең халык җыры булып, халык йолалары истәлеге булып калуы бик шатлыклы күренеш, әлбәттә].

**Туй ашларына карата ырым**

– Туй аты җулда туwарылса, начар була, дийерләр ийе. Менә безнең ат ишек алдында, ишек алдына килеп кергәч кенә туwарылды қуйды. Қапқадан кергәч кенә туwарылды. Ирем үлгәнгә йегерме ел менә (*Ташлы Елга*).

**Килен әйберсе, өй киендерү, өй бизәү**

*Қашағалар, қызыл башлы сөлгеләр, өлөңгеләр* (пәрдәләр) элеп куелган.

– Килен әйберсе белән өй кийендергәннәр. Кашағалар, өлөңгеләр, кызыл башлы киҗеле сөлгеләрне тәрәзә йаңағына элеп куйғаннар (*Сәрдекбаш*).

**Түшәк-ястык**

– Кийәүгә китә торған кыз йағыннан түшәген-ястығын бирерләр ийе (*Адай*).

**Кияү яғыннан кызға әйбер китерү**

– Хәлле кешеләр кызға кием-салымнар, күлмәкләр, җаулықлар китерерләр ийе (*Тырыш*).

**Килен тел яшерә**

– Элгәре киленнәр бийата, бийана белән сөйләшмәсләр ийе, тел йәшерерләр ийе (*Адай*).

### Кодалар килү

– Атқа журғаннар, түшәкләр салып кодалар килер ийе матур итеп, бөтен аwылны шаулатып (*Сәрдекбаш*).

### Кода күчтәнәчләре

– Кода күчтәнәчләрен туйга барганда һәрвакыт парлап алып барганнар. Тигезлек белән гомер итсеннәр, дип.

### Ике күмәч, пич күмәче, пар каз, пар гөбәдийә, пар чәкчәк, пар пәштит була, чәй тоқмачлары

– Ике күмәчне, пич күмәчләрен, зур итеп, күчтәнәч итеп, патнуска салып алып киләләр ийе. Аннары пар каз, пар пәштит булыр ыйы. Шулай парлы буладырыйы әйберләре (*Адай*).

[Кода күчтәнәчләрен гадәттә табында утырган кунаклар алдына чыгарып күрсәткәннәр. Шуннан соң, берәрсен кисеп, өлешләп, кунаклар алдына куйганнар, ә берсен кодаларның үзләренә кире биреп җибәргәннәр. Бу гадәт әле дә саклана икән].

– Туйга барсаң – туйып бар,

Ата казың суйып бар, – диеп, туйға *пар каз* алып барғаннар.

– Дәү түгәрәк күмәчләр алып барғаннар. Ул күчтәнәчләрне алып чығып күрсәткәннәр. «Менә шуның күчтәнәче, менә моның күчтәнәче» дип. Шулай күрсәткәннәр дә, алып бүлгәләп, табаклыкка куйғаннар. Зур туйлар булған әwәле, күп кеше чакырып (*Кара Елга*).

– Туйға барғанда пар каз, пар пәштит, пар күмәч алып барырлар ыйе. Ул казның берсен турарлар ыйы, берсен кире биреп җибәрерләр ийе.

– Ризык өзөлмәсен ике арада.

Ике пәштитнең берсен, ике күмәчнең берсен кире биреп җибәрерләр ийе. Ике йак та ризыклы булырға (*Олыяз*).

– Туйда шул алып килгән әйберләрнең берәрсен кисәләр ийе. «Кода күчтәнәче, аwыз итегез», – дип. Ә берәрсен кодаларның үзләренә кире биреп җибәрерләр ийе:

– Аралар өзөлмәсен,

Ризыклар өзөлмәсен ике арада, – дип (*Зур Сәрдек*).

– Пар каз алып барадырыйе казы булған кеше. Үрдәк алып барса, дүртне алып бара. Ике каз алып барса, берсе үзеңә кире кайта. Инде үрдәкләр алып барса, дүрт үрдәкнең икесен кире алып

қайтырға тиеш. Шулай биреп җибәрәләр қодалар. Пар күмәч, пар каз, пар гөбәдийә булса, берсе үзеңә кире қайта (*Ядегәр*).

### Аш сандыгы

*Аш сондоғы* – туй күчтәнәчләре тутырылган сандык.

– Аш сондоғы да була туйда. Ул туй атында килә. Анда шул пар күмәчләр, пар қазлар була ыйе шул аш сандығында (*Адай*).

### Туй қодаларын ашка алу

– Син ашқа аласыңмы?

– Хатын-кызларнымы, ирләрнеме?

Кыз йортонда туй иткәннән соң әттәнең (әтинең) энеләре қатын-қызларны ашқа алғаннар, икенчеләре ирләрне алғаннар. Туйға керүчеләр унике кеше булған.

– Пәтәч, парлап алмағаннар микәнни?

– Менә бер кодалар төп йортта да чәй эчкәннәр, икәүләп ашқа да килгәннәр.

Чәй эчәбез шикәрләп,
Без киләбез икәүләп, –

дигәннәр.

– Кода, тагын бер җырлагыз эле, – дигәннәр икән, тегеләр:

– Тәмне нәстә күп булмый ул, – дигәннәр (*Адай*).

### Килен токмачы

*Килен туқмачы* – килен төшкәч, кияү йортында үткәрелә торган мәҗлес.

– Ашка чакырырлар ыйы килен килгәч. Килен тукмачы дийерләр ийе, аш үткәрәләр (*Ядегәр*).

### Кукмара керәшеннәрендә туй йолалары

– Кыз җәрәшү булған. Ақлыққа килгәннәр. Ақлыққа кыз сорарга килгәч, *чинақ тастымалы* белән сөлге биргәннәр. Өстенә ике ипи қуйып биргәннәр. *Ақлық бирү* булган.

«Тигез җәшәсеннәр» дигән сүз булған. Кийәү җағыннан күпмедер ақча биргәннәр (*Чура*).

### Кәбен қойу

*Кәбен койу* – өйләнешкәндә чиркәүдә христиан дине йоласын башкару [*Кәбен* – фарсы теленнән кергән сүз, «никах» дигәнне аңлата].

– Ике җақ та, керәшен булсалар, кәбен қойдыралар. Мөсел_ман-ны алса, башта чумылдыра, аннары кәбен койалар.

Кәбенсез булса, бик зур йазық дип санала инде. Қодай закуны-на кермәгән була.

Айақ асларына *ару бистәр* җәйеп, шул *бистәргә* бастыралар.

Башларына икесенә дә бинис (*венец*) кигертәләр. Бик матур була инде ул, қодай закунында була.

– Кәбен қойу ул үз гумерендә бер генә була кешенең. Икенчеләй өйләнсә инде, аңғар кәбен қоймыйлар. Кәбен қойу икенчеләй бул-са, ул җазық эш булған (*Чура*).

## Килен каршылау

– Капка төбенә туй килеп җиткәндә ипийеңне тотып чыгасың. Аны тәлиңкәгә кисәсең. Саwытта майың, балың була. Кергән бер кешегә шул ипи белән майны, балны каптыралар, киленгә дә кап-тырып каршы алалар.

Килен май күк җомышақ булсын,
Бал кебек татлы булсын (*Сәрдәүч*).

## Туй атлары

– Туй атларына қыңгыраулар, сөлгеләр тағып бардылар, чаңғыр-чоңғыр, зерә матур булыр ыйы туй атлары килү (*Үрәсбаш*).

## Туйчылар

*Туйчылар* – туйга катнашучылар.

– Туйчыларны күрергә бик күп кеше керәдерийе.

«И матур кийенгәннәр, тәңкәләр белән киләләр». Күрергә ке-рәләр (*Чура*).

## Сандык сатулашу

– Кара-каршы сандык сатулашу булды. Кызның әйберсен са-тып алу була. Әңки булган кеше күбрәк сатулаша. Менә кечти генә қапчық тоткан да:

Дыңғыр-дыңғыр дыңғырчак.
Ат өстөндә ыңғырчақ.
Сандық сатып алу өчен
Китердек бер қапчық борчақ, –

дип, шул кечти қапчық белән борчақны күрсәтә. Сандықны шуңға ғына биреп булмый бит инде, кертмиләр қапқадан (*Чура*).

## Туй қодалары

*Кода булып килүчеләр* – туйга кунакка килүчеләр.

– Қода булып килүчеләр өстәл артына утырган була. Қыз йағында ничә қода, кийәү яғында ничә қода, қырықлап қода булыр ыйы (*Үрәсбаш*).

*Төп қода белән қодагый* – кияүнең яки киленнең ата-аналары.

– Түрдә өстәл башында төп қода белән қодағый була. Өстәлнең бер жағында хуҗаның үзенең туғаннары тезелеп утыра.

## Қода сыйлаучылар

*Қода сайлаучылар* – туйда кунакларны сыйлау, табынны алып бару өчен махсус билгеләп куелган кешеләр.

– Қода булған кешеләргә «қода сыйлаучылар» дип билгеләп қуйарлар ыйы. Қода сыйлаучылар айағурә басып қода сыйларлар ыйы. Ул қырық қодаға күпме қода сыйлаучы кирәк.

Дөңгер-дөңгер, дөңгер чақ,
Ат өстөндә ыңгырчақ.
Бу ди сыйларны, бу хөрмәтне
Қайтарырбыз бер-бер чақ (*Чура*).

– Қода сыйлаучылар өстәл янына утырмыйлар, айақ өсте торып қунакларны хөрмәтләп, җырлап, сыйлап торалар. Туй барғанда сыйлаучының өстәл янына утырғанын ғайеп итәләр ийе қодалар. Утырасы түгел ийе қода сыйлаучыларға.

Қодаларны қунақ итеп озатқач қына утырырлар ыйы өстәл янына қода сыйлаучылар.

Ары да чабыт булдық,
Бире дә чабыт булдық
Инде шөкер бер Ходайға
Қодалардан котылдық, –

дип, бийешеп, җырлашып утыралар ыйы (*Чура*).

## Қода озату

– Қодалар китәр алдыннан қыңгыраулар чылтырата башлыйлар.

Ипи белән қаршы алдық,
Ипи белән озатабыз, –

дип, күчтәнәч ипиләр биреп җибәрәләр ийе (*Чура*).

## Тел йәшерү

Керәшеннәр дә, татар халкының башка төркемнәре кебек үк, ирнең атасыннан һәм өлкән агасыннан тел яшергәннәр, ягъни сөйләшмәгәннәр.

– Ирeңнең атасы бар икән, бийата инде ул, сөйләшәсе түгел. Бийагадан да тел йәшергән, сөйләшмәгән (*Үрәсбаш*).

## Килен сөйләштерү

– Менә мин килен булып килгәч тә, җизни сөйләштерде. Менә мин бәлешләрне эчлеккә (чормага) меңгереп қуйарга дип, өскә менеп киттем.

«Килен, син анда дөбер-шатыр җөреп мәтәлеп төшмә тағын», – ди җизни әйтә.

«Җуғ, ул қалын, сына торган түгел», – дим.

Эчлектән (чормадан) төшкәч:

«Килен, бу чаршаwыңны қайан алдың, шундый матур», – ди.

«Җулда җөри торгач очрағандыр инде», – дим.

Өйдә кунакларга әйтә җизни:

«Җарар, минем эш бетте, киленнең телен ачтым», – ди. Ул мине җүри сөйләштергән икән (*Чура*).

## Аш-су традицияләре

### *Табаклык*

**Сәке табаклык**

– Элек сәкедәйе табаклық. Күп кешедә зур сәкеләр булған. Түр сәке, йанк сәкеләр булган. Түр сәкедә табаклык ясап, айақ бөкләп утырганнар (*Кара Елга*).

**Изән табаклык**

– Элек эстәлләр булмаған. Идәнгә дәү ашаулық җәйәләр ийе дәген, шунда тезелеп утыралар ыйы ашқа килгән кешеләр. Ашны идәндә үткәрәләр ийе. Қарчықлар идәндә айакларын бөкләп утыралар ыйы (*Кара Елга*).

**Ашаулык, палас, көрпә**

– Ашаулық астында палас булыр ыйы. Қырыйда көрпәләргә утырырлар ыйы. Шулай изәнгә табақлық җасап, айак бөкләп утырырлар ыйы элгәре көрпә салып (*Адай*).

**Зур табак белән аш**

– Ашны зур табаққа бушатырлар ыйы дағын, табақлық уртасына утыртырлар ыйы. Шуннан тәлиңкәләргә бүлеп салырлар ыйе (*Тырыш*).

**Зур тәлиңкә белән ипи**

– Табаклыкның ике башына зур тәлиңкә белән ипи кисеп куйарлар ийе, пичтә пешкән түгәрәк ипи булыр ыйе, кара ипи, арыш ипийе. Пич төбендә күпереп пешкән ипиләр булды шулай бик тәмле (*Сәрдәүч*).

***Бәлешләр***

**Зур бәлеш**

– Зур таба белән бәлеш. Уртаға куйарлар ыйы дағын, шуннан қашық белән алып ашарлар ыйы.

Бәлешен шул зур көйөнчә қуйалар ыйы табақлыққа. Шуннан үрелеп ашау ыйы, туң майны чыкылдатып салып. Шуннан да шәп май жуғыйы (*Төркәш*).

– Элек бик зур таба белән бәлешләр пешереп қуйғаннар қунақларға. Абыстайлар сорыйлар икән:

«Бәлешнең атасы-анасы, баласы бармы?» – дип. Җәнә, моно ашап бетерсәк, балаларға қаламы, дип. Ише булса, қурықмый ашағаннар инде. Булмаса, әзрәк қалдырғаннар (*Чишмәбаш*).

**Бодай белән қабақ бәлеше**

– Коръән багышлаган көнне бодай бәлеше пешереп, чәйләр қуйып, шунда табақлық җасап утыралар ыйы.

– Бодай ярмасы белән қабақ турап бәлеш пешерәбез. Данлықлы бәлеш булыр ыйы ул бодай белән қабақ бәлеше.

Бодайны ташқа салып, қул тегермәне ташына, шуны әйләндереп, җарма җасар ыйық (*Адай*).

**Бодай бәлеше**

– Бодай җармалары белән дә пешердек бәлешне. Бик җаратып ашарлар ыйы (*Олыяз*).

**Күкәй бәлеше, гөбәдийә**

– Күкәй бәлешенә элек унике-унөч күкәй салалар ыйы. Хәзер биш күкәй дә җитә. Йука ғына итәләр хәзер. Төбөнә корт җәйәбез. Кипкән кортны көйлөдә төйөп, май салып, дөгө белән күкәйне катнаштырып салабыз.

– Күкәй бәлешен хәзер «гөбәдийә» дип әйтәләр, элек күкәй бәлеше дийәрләр ийе (*Кара Елга*).

**Бәлеш төбе**

– Элек бәлеш төбөн дә кискәннәр. Аны ич ашасы булған, йә алып киткәннәр.

«Бәлеш төбөн ашамасаң җокоң кермәс», – диләр ийе.

Бәлеш төбөн кисеп, аш салып чыгаралар ыйы. Ашамыйчы кайтмыйдыр ыйың бәлеш төбөн (*Салтык Ерыклы*).

– Бәлеш күркәм инде ул өстәл өстендә.

Менә хәзер гөбәдийә пешереп утырталар да, табаның төбе буш қала. Кайсы кешегә бер дә ошамый.

«Болай җарамый, бәлеш пешерегез, бәлеш күңгелле. Таба төбендә бәлеш төбө қалмағач, ашның җәме китә», – дигән берәү табақлыққа утырғанда, бөтөн кеше килешкән. «Шулай шул», дигәннәр (*Адай*).

**Бәлеш барнағы** – бәлешнең өске капкачын бөреп-бөреп бәлеш төбе белән тоташтырылган урын. Аны вак-вак итеп кисеп, өлешләп куйганнар.

– Бәлеш барнағын да өйгә дә алып кайтыр ыйың, балалар көтөп торалар ич, әби аштан кайта, дип. Күчтәнәч булыр ыйы ул бәлеш барнағы ул заманда (*Сәрдекбаш*).

**Җорт бодай оны**

– Бодайны җуып, зур җәймәләргә җәйеп киптерерләр ийе дә, шул киптергән бодайны тегермәндә тартып, җорт бодай оны җасарлар ыйы. Җорт бодай оны қамырыннан пешкән әйберләр бигрәк тәмле булыр ыйы (*Зур Сәрдек*).

**Кабартма**

– Җорт бодай ононнан қабартма пешерер ийек. Җаман тәмле була җорт бодай оно қабартмасы. Каз суйғанда қабартмалар пешерер ийек, сақлап қына тотар ыйық ул онно (*Ядегәр*).

**Дучмақ, бәрәңге дучмағы**

– «Дучмақ» дип әйтерләр ийе. Элек аны төче камыр өстөнә соло онын туғылап, шуны җәйеп пешерерләр ийе.

Бәрәңге дучмағы да була. Кабартма шикелле қамыр өстөнә бәрәңгене пешереп төйөп, шуны йағып пешерәләр. Дучмақны таба зурлық итеп, оло итеп саласың (*Яңа Сәрдек*).

**Күзикмәк**

– Күзикмәк пешерәбез, тары йармасы белән. Йуқа гына итеп җәйеп, җәймәсен пешерәбез дә, тары ярмасын пешереп салабыз, урталай бөклибез (*Кара Елга*).

**Пирәмәч**

– Пирәмәчне wақ итеп пешерәбез. Бәрәңге пирәмәче, эремчек пирәмәче була. Сыйер бозаулагач, сөт күп булғачыннан эремчек пирәмәчләре пешерер ийек (*Сәрдекбаш*).

**Тәкә**

– Таба тәкәсе пешерәбез. Wак итеп пешергән бөккәнне таба тәкәсе дибез.

Қабақ тәкәләре пешерер ийек.

Җылғыр тәкәләрен дә күп пешердек элгәре (*Кара Елга*).

**Җылғыр**

– Киндер орлоғыннан җылғыр пешерә торған ыйык. Киндер орлоғын төйәсең киледә, менә болай басасың қамыр шикелле иттереп. Аның майы чыға. Шуны бәләкәй-бәләкәй иттереп, пилмән шикелле итеп, қамыр эченә салып, қазанға салып пешерә торған ыйық. Менә шуны җылғыр дип әйткәннәр (*Кара Елга*).

***Ипи пешерү***

– Пичнең көлен пумала белән себереп, пич төбенә салып пешерә торған ыйық. Җидешәр ипи салыр ыйық. Кайнап пешәр ийе мич төбендә. Шулай пумала булыр ыйы мунчаладан җасалған. Ул ару пумала, пич пумаласы була. Шуны әзрәк суландырып, пич төбөн себереп алыр ыйық та, көрәк белән, ипи көрәге белән тығар ыйық пичкә. Шулай ағач көрәк, ипи көрәге була торған ыйы. Ипигә аңға көл дә йоқмады. Шул хәтле тәмле пешәр ийе (*Салтык Ерыклы*).

**Ипи башы қалдыру**

– Ипи пешергәндә қамыр қалдырадырыйық он эченә салып, «ипи башы» дип. Шуны җылы суға изеп куйадырыйық кичтән, ул әчи. Иртә белән басадырыйық он салып. Күәс чиләгендә әйбәтләп басып қабартадыр ыйык ипине (*Салтык Ерыклы*).

**Көлчә**

– Көлчә дийер ийек. Бармақ қалынлыгы итеп йасап, аны да пич төбендә пешерер ийек. Ул кабарып пешәр ийе пичтә. Аны да көрәк белән алған, шулай пич төбендә пешергән.

Ипи салғанда көлчә дә пешергәннәр шулай.

«Әйдә көлчә белән чәй эчик әле дигәннәр» (*Яңа Сәрдек*).

**Тәбикмәк**

– Ипи әwәләгәндә қамырны бармақ қалынлығында ғына итеп, табаға салабыз, табаны майлыйбыз. Ул анда қабарып утыра. Пич қаршысында, йалқында пешереп алабыз. Аннан да тәмле бер нәрсә жуктыр дөнҗада. Ул тәбикмәк була (*Сәрдәүч*).

**Чәкчәк**

– Чәкчәкне қунақ киләсе булғанда, туйларға пешерделәр. Ике патнус чәкчәк булыр ыйы кодалар килгәндә (*Ядегәр*).

**Чәй токмачы**

Чәй токмачы – кош теле формасындагы камыр ашы.

### *Корт қайнату, қортлы май ясау*

– Көннәр буйы, қазан астына сыйыр буғын йағып, қорт қайнатқаннар.

Сыйыры булған кешеләр сөтне қар базында җыйып, қазанға салып җылытып, калхуз сипаратына алып барып айырталар ыйы. Ул айыртқан сөтне әчетеп, қорт қайнаталар ыйы болғата-болғата.

Эремчекне, сөт қушып, қызарғанчы қайнатасын дағын ул қорт була. Ул қортқа май саласың, сары май, бал салып болғатасың да қортлы май була инде ул (*Кара Елга*).

### *Қаймақлы сөт*

– Қаймақлы сөт йасарлар ыйы. Сауған сөтне озақлап қайнатып, суытырға қуйарлар ыйы. Өстөнә қалын булып қаймагы утырыр ыйы. Шуны қунакларға қуйар ыйық (*Тырыш*).

### *Боламық болғату*

– Бер қат кеше килеп кергән икән, менә чәй җанына қуйарға ипиләре булмый. Әзрәк кенә су сала қазан төбенә дә, элек бит кәстрүлләр-фәләннәр жуғыйы, қазан асып пешерү ийе.

Қазанга су салып, шуңғар тоз салып, он салып болғатырлар ыйы. Кечкенә табаққа, җә тәлиңкәләргә бушатып, уртасына күз җасап май салырлар ыйы. Боламық була ул, қашык белән ашый торған (*Чишмәбаш*).

### *Талқан болғату*

– Талқанны да шулай болғатырлар ыйы. Күп ашадық талканны. Анысы умач шикелле, уwалып торыр ыйы, қоро булыр ыйы ул. Талқан белән чәй эчтек, дип қайтырлар ыйы андарысын. Кисәргә ипи жуғында шулай боламық, талқан болғаталар ыйы (*Ядегәр*).

### *Солы кесәле*

– Кесәл пешерә торған ыйық солодан. Әле дә пешерәм гирку_листән. Суға салып әзерәк әчетәм дә қазанға салып пешерәм. Аны гел болғатып торасың. Болғатып тормасаң ул ойошоп чыга, болай-болай булып. Сөт белән ашасы.

– Зур табакта кесәл булыр ыйы. Шуны үзеңнең турыдан китеп кенә ашыйсың. Әти әйтер ийе, «табақ қырыйыннан ғына алып ашағыз, үз турығыздан», – дийер ийе.

«Соло кесәлен үз турығыздан ғына алып ашамасаң, чүпле булыр икенче жылға солоғыз, үз турығызны ғына чистартып ашағыз», – дийер ийе әни. Солы кесәлен шулай ашар ыйық (*Кара Елга*).

### *Өшегән бәрәңге уалмасы*

– Өшегән бәрәңге уалмасы пешерер ийек, и тәмне булыр ыйы ул.

– Уалма пешерер ийек өшегән бәрәңгедән. Йаз көнне қарлар эрегәч басудан шул өшөгән бәрәңгене жыйып алыр ыйық жирне қазып. Шуны қабығыннан чистартып, қамыр шикелле басып, үзләндереп, табаға салып пешереп кенә торор ыйы әни. И, чәй әчәргә тәмне була инде ул ***уалма***. Ул әле бетә, бақча кипкәч, басулар кипкәч ул қортлый башлый өшөгән бәрәңге.

Ул өшөгән бәрәңге бик тәмне күк тийәр ийе, йат тәм килми аннан. Аның ақ жирен генә алабыз, ул он шикелле ақ булыр ыйы. Аннан уалма пешереп чәй эчәр ийек рәхәтләнеп (*Адай*).

### *Өшегән бәрәңге тәбикмәге*

– Мин бер қоштабақ чергән бәрәңге алып қайттым қазып, жазға чыққач шулай басудан бәрәңге қазыр ыйық. Ап-ак крахмал бәрәңге. Берәр таба тәбикмәк пешереп бирде әби өшөгән бәрәңгедән (*Төркәш*).

### *Көмөшке*

Көмөшке – арыштан ясалган эчемлек, хәмер.

– Көмөшкене элек арыштан йасадылар. Арлар ғына йасады аны. Безнең мөселман кешесе йасамады. Хәзер арышны җәшелли уралар бит, көмөшке чықмый, диләр. Элек чичти өлгөреп җиткәч кенә уралар ыйы (*Олыяз*).

## Бала тууга караган йолалар

### Кендек әбисе, әбилек

– Әбилек бик белеп торган ул үз эшен. Кендеген кискән, бәйләгән, бәбәйне кулына алган.

– Гумер буйе доға кылмаға қушқаннар әбилеккә, шуңға доға қыл, дигәннәр.

### Битлекле бала

Битлекле балалар туадыр ыйы. Ул битлекне ышкафта ғына тотадырыйқ қадерләп.

«Битлекле бала мәхәббәтле, әйбәт бала була, җөзе нурлы була», – диделәр (*Ядегәр*).

### Бәби биләү, бәби чүпрәкләрен киптерү

– Иске күлмәк итәкләрен җыртып чүперәк җасаганнар бәбәйне төрергә.

Ару, чичта чүпрәккә төрөп, бәбәйне биләп қуйғаннар. Таралып, туңып җатмый, җылынып җоқлый бәбәй, биләгәч.

Элек шулай қайда иске күлмәкләр, әтисенекеме, әнисенекеме, шуңға төреп үстерделәр инде бәбәйне, балам (*Адай*).

[Бәбәй чүпрәкләрен җилгә чығарып эләргә кушмаганнар]:

– Ул wакытта бәбәй чүпрәкләрен җилгә чығарып элмиләр ийе. Җилгә чығарып элергә қушмыйлар ийе әбилекләр.

– Чүпрәкләрне җилгә чығарып эләргә қушмыйлар ыйы үтүкләмәгән өчен. Хәзер үтүклиләр ич. Җилгә чығарып эләргә дә ярый, дияләр (*Сәрдекбаш*).

– Элек бәбкә чүпрәкләрен өйдә генә, мич башында, янә мунчада элеп киптерергә қушалар ыйы. Элек үтүк булмаған. Аннан күмер үтүкләре чыға башлады, хәзер инде иликтер үтүкләре беләп үтүклибез (*Чишмәбаш*).

### Бәби ашы китерү

– Бәбәй ашы китерәләр бәбәй туғач та. Менә мин қош теле пешереп төштем. Тәйекмәк пешереп кертәләр (*Ядегәр*).

**Қабык бишек**

– Җүкә қабығыннан җасаған қабық бишек булды элгәре. Ул қабық бишек бик җиңгел булыр ыйы, бәбәйгә җылы булыр ыйы ул.

– Бишек әйбәт ийе ул бәбәй тирбәтергә.

«Бишек ул – җарты ана», – дийерләр ийе.

Тирбәнеп кенә җоқлый бәбәй қабық бишектә. Җүкәнең қабығын төшереп, шуннан бишек җасағаннар. Җылы була ул қабық бишек, исе дә әйбәт була (*Сәрдекбаш*).

**Миләш сиртмә**

– Бүлмә тақтасына миләш сиртмә қуйып, әкерен генә тирбәтеп утырырлар ыйы шул қабык бишекне.

Қайын сиртмә қуймаслар ыйы элек.

«Қайын – қайғылы була», – диерләр ийе (*Төркәш*).

**Бәби арбасы**

– Әрҗәле бәбәй арбасы булды. Аны да қабықтан җасадылар. Тәкермәчле булды.

Без оло балалар ул бәбәй арбасын гел тартып җөрөр ийек инде бәбәй қарағанда. Уйнарға чықсақ та, чиратлап бәбәй арбасын тартып җөрөр идек.

– Қабық бәбәй арбасын тартып қырға ураққа барырлар ыйы әниләр (*Ядегәр*).

**Бәбине сөннәткә утырту**

– Кендек әбиләр дә сөннәтләгән. Бәбәй туғач та, мәлмийенең очын кисеп алыр ыйы кендек әби.

«Кендек белән бергә төзәлә ул», – дип, ағач черege сибәр ийе, миллек сулары (*Тырыш*).

**Бәбигә исем қушу**

– Бәбәйгә исемне өч көннән ары тормый қушасы, диләр. Аннан соң пәри-җен қуша дийәрләр ийе (*Салтык Ерыклы*).

**Миң чыкканда исем алыштыру:**

– Туғач та миңа Шәмсенаһар исеме қушканнар. Шуннан миңа миң чыққан да Миңсылу қушқаннар. Миңсылу булып җөрим. Миң беткән. Ул күп чыққан муйыннарға. Күп чықмаса, қушмаган булырлар ыйы. Шулай исемне алыштыралар, миң бетә (*Адай*).

– Чормадан, морҗа башыннан қашық төшерәләр исемне алыштырғанда (*Адай*).

– Менә ике күзеннән йәш қоела, күзе аwырта. Бабасы икенче исемне қушты, рәтләнде күзләре Ходайның рәхмәте. Минниса исеме қуштылар. Бик аwырта башласа, шулай «мин» сүзе кергән исем кушалар ыйы.

**Баланың қырығы тулу**

– Қырығы тулғанча йалгыз қалдырмаска дийәрләр ийе (*Чишмәбәш*).

**«Пәри алыштыру»дан саклау**

– Пәри алыштыра, дигән сүз бар. Баланың баш астына *йақшы йазу* куйарлар ыйы.

Йак-ягына тимер әйбер куйарлар ыйы, кайчылар (*Чишмәбаш*).

**Күз тиюдән саклау**

– Миләш ағачыннан күз тими бәбәйләргә дә, дәү кешегә дә. Миләш ағачын бәйләп қуйалар беләгенә.

– Тағын қаз күтиге мамыгын қуйалар ыйы қалфагына матур иттереп, төрле-төрле буйауга манып (*Ядегәр*).

### Төрле им-томнар

– Бәбәйнең эче аwыртса, сула булган дип, мамық мөндәрнең почмагы белән төртеп имләрләр ийе.

Сула булган, сула булган,
Бер-ике-өч, очоп китсен...

**Күз тиюдән имләү**

– Ләгән белән су қуйа дағын, қурғашны эретә дәген, шуны суға сала. Нинди тамға төшә. Кеше тамғасымы... Кеше сурәте төшсә, ызначит кеше күзе тигән.

Күз тигәнгә дә, қурыкқанга да қургаш қойалар ыйы (*Олыяз*).

– Чәршәмбе көнне таң суы алалар ыйы. Күз тигән баланы жуарлар ыйы шул су белән, эчертерләр ийе ул таң суын (*Сәрдекбаш*).

– Андары қырық бер агач башыннан жапрақ алып, шуны қайнатып қоендырырлар ыйы күз тигән балаларны (*Тырыш*).

**«Су тотканда» имләү**

– Су тотқан, дип, суга жеп саласыйы. Жепне төйенләп салалар.

«Име-томы шул булсын».

– Менә ике бала берсен-берсе йаратмаса, икесен бергә утыртып, икесен йәнәшә төснәрләр ийе артыш белән. Шулай тийеш, дийерләр ийе (*Олыяз*).

## Чумылдыру

***Чумылдыру*** – баланы чиркәүгә алып барып, христиан дине йолаларын үтәү, исем кушу.

– Қабық арбалар белән чумылдырырға алып барғаннар чиркәүгә. Чумылдырғанда кечкенә малайларны суға салып алалар, зурларның башына ғына салалар суны.

Шул көнне нинди изге исеме белән бәйрәм, ата-анасы нинди исемне ошата, шул исемне сайлап алалар.

Чумылдырғанда шул исем белән чумылдыра.

## «Урыс әни», «урыс әти»

Урыс әни, урыс әти – баланы чумылдырғанда «әти», «әни» итеп билгеләп қуелган кешеләр (русча – «крестный отец», «крестная мать»).

– Шулай урыс әни, урыс әти була чумылдырғанда. Өч буынға кадәр үз туғаның җарамый, ди. Урыс әни булган кешегә иманнарны белергә кирәк, теге баланы өйрәтергә тийеш. Аның өстөндә ул бала. «Чумылдырылған бала үз баласыннан җарма бөртеге тикле генә ким була», – дигәннәр. Ул бала өчен җавап бирәсең инде, дөрес җулдан җөриме ул. Эндәшкәндә аларга «урыс әти», «урыс әни» дип әндәшә инде.

«Әйбәт җулдан җөр, җақшы җулдан җөр», – дисең инде. Алар гел сине генә тыңлап тормыйлар. Тыңласалар, бик шәп тә. Аның өчөн теләк итәргә кирәк.

Чумылдырып қайткач, утырып чәй эчәләр (*Оштырма Юмья*).

ӨЙРӘНЕЛГӘН АВЫЛЛАРДАГЫ ИНФОРМАНТЛАР

**Зур Сәрдек:**
Галимҗанов Газинур
Галимҗанова Дамира
Хәбибуллина Фәния
Хантимерова Фирүзә
Шәйхетдинова Бибикамилә

**Адай**:
Мөхәммәтшина Диннәваз
Ханафин Габделнур
Ханафина Миңсылу

**Кара Елга:**
Фазлыев Хуҗиәхмәт
Фазлыева Мәрьямбикә

**Чишмәбаш:**
Абдуллина Язилә
Әхмәтҗанова Финзия
Билалова Рабига
Ганиева Маһинур
Хәйруллина Разия
Хәкимҗанова Минзилә
Хәкимҗанова Мөслимә

**Сәрдекбаш**:
Баһавиева Фәүзия
Гафиева Илһамия
Исрафилова Җәмлиха
Мостафина Маһинур
Шәфигуллин Буста
Шәфигуллина Әлфия

**Яңа Сәрдек:**
Галимова Фәридә

**Тырыш**:
Гыйниятуллина Флера
Юнысова Гөлмаһура

**Сәрдәүч**:
Андреева Елизавета (83 яшь)
Николаев Александр
Николаева Александра
Федоров Василий (73 яшь)

**Югары Чура:**
Азина Галина
Алексеев Геннадий
Алексеева Анна
Антипов Семен
Афанасьев Андрей
Дмитриева Елизавета
Егорова Зоя
Тарасова Оксана

**Оштырма Юмья:**
Архипова Анастасья
Баһавиева Сәвия
Васильева Анастасья
Васильева Елизавета
Егорова Мария
Николаева Федосья
Петрова Анна
Рамазанов Анатолий
Родионова Зоя

**Ядегәр**:
Галиева Нәфига
Камалова Разия
Кашипов Наил
Сабитова Сәкинә
Хәсәнова Сания

**Мултан (Починок-Кучук):**
Исхаков Леонид
Йосыпова Тәгъзимә
Лиллобаева Александра
Музаффарова Маргарита
Ямбулатов Моисей

**Ташлы Елга:**
Газизуллина Әлфия
Газизуллина Миңлебикә
Гыйниятуллина Гөлфинур
Мөхәммәдиева Нәзирә

**Салтык Ерыклы (Өшембашы):**
Зәйнетдинова Алия
Фаттахова Сәгыйдә

**Важашур (Быжа):**
Әхмәтгалиева Вәсига
Михайлов Леонид
Шәрәфиева Гөлйөзем
**Үрәсбаш**:
Андреева Анна
Иванова Елизавета
Мусина Анна

**Төркәш**:
Зәкиева Нурия
Мөшарапова Суфия
Рәкыйпова Рәйсә
Сәетгәрәева Сания
Хәбибуллина Нәсимә

**Ятмас Дусай:**
Зиннәтуллина Фәния
Таҗиева Гайшә
Таҗмиева Фирая

**Шепшеңәр**:
Газизов Каим
Гайнетдинова Зәлия
Гайнетдинова Фәүзия

**Олыяз**:
Закирова Зәкия
Нигъмәтҗанова Әминә
Хәкимуллина Дания
Хәкимуллина Мәликә
Якупова Зөлхәбирә

## ЕРАККА КИТЕП КАРАСАҢ...

*Айсылу Садыйкова*

Минем дә Кукмарага бәйле җылы хатирәләремне яңартасым килә. Бу якларда мин 1985 елның июнь аенда булдым. Экспедицияләр хәзер комплекслы булып, галимнәрнең зур төркеме катнашында үтә, ә ул елларда бер-ике генә кеше булсак та, чыга идек. Әлбәттә, бу бик җайлы түгел. Район җитәкчеләре ярдәменә өмет итәсең. Мине Кукмара районы белән ул чактагы район мәгариф бүлеге мөдире Әнвәр Садыйк улы Садыйков таныштырды, машина белән үзе озатып, укытучылар, авыл кешеләре белән очраштырды. Берничә көн үз өендә яшәү мөмкинлеге булдырды, хатыны – укытучы Нәкыя апа да – җылы кабул итте. Күп еллар мәктәп директоры, РОНО мөдире булган Әнвәр ага бик ярдәмчел, гади, уен-көлкеле кеше иде. Рухы шат булсын... Ни кызганыч, бу язмамда телгә алыначак кешеләрнең күбесе олы яшьтә иде. Инде күбесе вафаттыр. Догаларым барып ирешсен.

Сөйләгәндә, «Кукмара» дигән сүзнең мәгънәсен «ике мари» диеп тәрҗемә итәләр иде. Бу авылга иң элек ике мари кешесе килеп урнашкан, дип сөйлиләр. Шуннан соң башка кешеләр дә килә башлаган, авыл зурайган.

Зур Кукмара авылында пенсионер-укытучы, 5 бала анасы Мәрьям апа Фәйзрахманова сөйләгән истәлекләр аеруча гыйбрәтле. Ул авылдашларының колхоз кырларындагы, киез итек фабрикасындагы фидакарь хезмәте турында горурланып сөйләде. Мәрьям апа колхоз төзелеше елларында укытучылар әзерләгән спектакльләр, агитконцертлар турында искә төшерде. Ул вакытта яшелчә культураларын үстерүне пропагандалап, үзләре җырлаган ярым шаян, ярым җитди такмакларны әйтеп күрсәтте:

Ашны тәмләндерим дисәң,
Күб(е)рәк утырт кишер.
Кишер утырткан кешеләр
Зур уңышка ирешер.

Бәрәңгене яраталар
Картлары һәм яшьләре.
Тәмеңне белгән агайлар
Күп утырта башлады.

Фольклор экспедициясе вакытында очрашкан агайларның күбесе авыр сугыш юлларын үткән иде. Шуларның берсе – 77 яшьлек Фаруша абый Курамшин (Сәрдекбаш авылы), тальян гармунда «Герман көе»н уйнады.

Кукмара поселогында яшәүче Мидхәт абый Мөхетдинов, сугышта һәлак булган әтисенең истәлеге итеп, аның соңгы хатын саклый, еш кына анда язылган җырларны искә ала.

Су буенда ике каен,
Берсен кисәргә кирәк.
Берсен киссәң, ялгыз кала –
Ялгыз нишләргә кирәк?

Хатлар яздым утырып,
Кәгазь битен тутырып.
Хатым китте, үзем калдым,
Язган җирдә утырып.

Сугышчының гаиләсенә, якыннарына булган сагыну хисләре шундый җырларда әлегәчә яши.

Шул ук районның Ядегәр авылында мин башлыча бәет һәм мөнәҗәтләр язып алдым. Оркыя апа Камалова аларны, пөхтә итеп, ике калын дәфтәргә теркәгән, кадерләп саклый иде. Аларның күбесе халык арасында киң таралган әсәрләр, арада фольклор җыелмасы томнарында басылып чыккан вариантлар да очрый. Оркыя апа аларның һәрберсенең көен белә иде. Алар арасында «Манара», «Янып үлгән егетләр бәете», «Өмет итәм рәхмәтеңдин», «Суга баткан Гайшә бәете», «Сак-Сок», «Ана бәете» һ.б. бар. Оркыя апа 1905 елда туган, 7 ел мәдрәсәдә укыган. Шуңа күрә аның бәетләр, мөнәҗәтләр репертуарының бер өлешен китап традициясен дәвам иттергән әсәрләр тәшкил итә. Ягъни бу бәетләрнең кайберләре, кулъязма хәлендә генә калмыйча, «Сак-Сок бәете», «Зөлхәбирә

бәете» исемнәре белән XX гасыр башында китап булып та басылып чыккан. Татар авылларында аларны кырыктартмачылар таратып, сатып йөргәннәр.

Бу турыда башка өлкәләрдә дә ишеткәләргә туры килгән иде. Мәсәлән, 1984 елда Горький (хәзер Түбән Новгород) өлкәсенең Сергач районы Грибан авылында Галләмова Наимә апа (1905 елда туган, 4 ел укыган) нәкъ шул турыда сөйләде. Шуңа күрә кайбер бәет-мөнәҗәтләрнең безнең көннәргә килеп җитүе халыкның язма традициясенә, аларның XX гасыр башында ук укымышлы татар хатын-кызлары тарафыннан китаптан күчереп таралуына бәйләнгән. Бу традиция әле бүгенге көнгәчә дәвам итә.

Авыз иҗатының традицион жанрларыннан булган әкият бу якларда әз булып чыкты. Шуңа күрә Ядегәр авылында укытучы Сания апа Хәсәнованың бик матур итеп «Таңсылу» әкиятен сөйләве куанычлы булды. Ул башка әкиятләрне дә исенә төшерде. Сания апа, туган авылына, туган якларга багышлап, үзе иҗат иткән шигырьләрен дә укып күрсәтте. Кукмара районының Янил, Янсыбы, Ядегәр, Сәрдекбаш, Зур Кукмара авылларында туган ягын, аның тарихын белгән, яраткан кешеләр легендалар, риваятьләр сөйләделәр. Мәсәлән, Сәрдекбаш авылы тарихын Мос-тафин Кадыйр Мостафа улы бәян итте. Бу әсәрләр авыл, елга, чишмә исемнәренең килеп чыгышын, аларның тарихын аңлата.

Җыелган материаллар безнең фольклор фондында саклана һәм алар киләчәктәге тикшеренүчеләр өчен мөһим чыганак булып тора. Бөек рус язучысы М. Горький сүзләре белән әйткәндә, «Үткәнне без ни дәрәҗәдә яхшырак белсәк, шул ук дәрәҗәдә җиңелрәк, тирәнрәк, шатланыбрак бүген башкарыла торган эшләрнең бөек мәгънәсен аңлый алабыз».

Еллар аша караганда, бу хакыйкатькә тагын бер кат ышанасың.

### Түгәрәк утрау (Таңсылу)

*(әкият)*

Безнең шәһәрдән ерак булмаган бер урында зур утрау бар икән. Анда искиткеч гүзәл сарай салынган. Ул сарай алтыннан булып, бөтен тирә-якка нурын чәчеп тора икән. Бу утрауда яшәгән патшаның кызы Таңсылу чибәрләрнең чибәре була. Аның чибәрлеге турында легендалар сөйлиләр. Һәрбер илдәге патша шушы кызга өйләнергә тели. Әмма патша кызын кияүгә бирергә уйламый. Утрау

шундый матур. Шул утрауның янында гына диңгез дә бар. Кешеләр шул диңгездә су коена. Гаҗәп, читтән килүчеләр ул диңгезгә керә алмый. Алар бу диңгезгә керүгә һәлак була. Ә утрауның кырыенда дөньяда нинди агач, нинди җимеш бар – барысы да шунда үсә. Алар туктаусыз чәчәк атып, җимеш биреп тора. Җимешне биргәч, яңадан чәчәк ата башлый. Бу утрауга башка юлбасарлар, дошманнар, теләсәләр дә керә алмыйлар, суга баталар.

Бервакытны сарай патшасының кызы Таңсылуның дөньяны күрәсе килә. Әтисеннән рөхсәт алмыйча, сарайның манарасына менә дә тирә-якны күзәтеп тора. Шул вакытта һавада бер өермә барлыкка килә. Өермә кызны үзенең көче белән тартып алып китә һәм тирән бер җирдәге елгага илтеп ташлый. Кыз хәлсез, бернәрсә дә белми, аңсыз ята. Бервакыт көмеш кыңгырау чыңнары ишетелә. Шуннан соң кыз бераз аңына килә, торырга тели, ләкин аягына баса алмый. Үлән ашап йөргән кашкалы ат, Таңсылуның янына килеп, елгага тезләнеп ята. Күзләре белән ымлый, янәсе, «менеп атлан, мин сине алып китәм». Бөтен көчен җыеп, Таңсылу атның өстенә менеп ята. Утырырлык хәле булмый. Ат аны ерак-ерак җирләргә алып китә. Кая китте – бу үзе дә белми. Озак бара. Ат бер авыл янында бер өй, ярлы кеше өе янына килеп җитә. Авыл башында җире булмаган ярлы гына кешенеке була. Бу өй артында шомыртлары, миләшләре чәчәк атып утырган. Шул вакыт атын каршы алырга дип, яшь кенә бер чибәр егет чыга.

– Ә, син нәрсә алып кайттың, кашкам, кунак алып кайттыңмы? – дип каршы ала. Кызны өйгә алып керә, әнисе аны бик нык кунак итә. Таңсылу хәзер хәл җыя. Таңсылу аңына килгәч, үзенең илен бик сагына, өенә кайтасы килә. Ләкин кайту юлын ул һич тә белми. Егет тә белми. Шуннан соң:

– Кайгырма, җаным, сине өеңә илтеп куярмын, – ди егет. – Әйдә әле, – ди, – синең белән барыйк урманга, җиләкләр җыярбыз, – дип алып китә. Урманга баралар, җиләкләр җыялар, тырысларын тутыралар. Урманда гаҗәеп бер агач үсә, шул кадәр куе яфраклы, һич җиде кешенең колачы җитмәслек, яфраклары шундый көчле, җилдә шаулап утыра торган. Болар карап торалар, аптырашып. Шушы вакытта урман эчендәге ниндидер көчләр кызны алып китмәк булалар егеттән. Шушы вакытта, үзләре дә белештермичә, алар имәнгә барып сыена:

– Имән, безне коткар!

Егетне дә, кызны да имән үзенең яфракларының көче белән үзенә тартып ала. Ышыкланып утыралар болар. Бу имән тирәсенә беркем дә килә алмый, һөҗүм ясый алмый. Кич җитә. Болар имән ботагыннан җиргә төшә. Бервакыт төн җитә, имән шаулаудан туктый. Нindидер кошлар тавышы, ерткыч хайваннар тавышы ишетелә. Нindидер куркыныч боларга якыная сыман. Курыкмыйча, имәнгә сыенып утыра икесе. Бервакыт төнге сәгать 12 тула. Урманда абагалар чәчәк аталар. Урман шундый яктыра, нурларга күмелә, көн яктысы кебек була. Егет әйтә:

– Без абага чәчәк атканын күрдек. Без бәхетле, безне берни эшләтә алмаслар. Әйдә, Таңсылу, абага чәчәк атканда, чәчәген алыйк икебез.

Имәннән төшеп, алар абага чәчәген алалар һәм икесе дә урман буйлап китәләр.

– Абага чәчәге булгач, курыкмыйбыз инде, – ди егет. Болар урман уртасында баралар, шулкадәр якты ут яна. Әллә кайлардан күренә. Егет әйтә:

– Бер тамчы да курыкмыйм. Без икебез дә барып, нинди ут икәнен күрик әле.

Икәүләшеп барсалар, кечкенә генә өй, эчендә ут яна моның. Өй янына баралар, иске генә өй, баскыч төпләре черек. Хәлдән тайган, коры сөяккә калган ямьсез бер карчык килеп чыга.

– Исәнме, әбекәй, ни хәлләрең бар? Ни эш бетерәсең? Кәефләрең ничек? Авырмыйсыңмы?

– Ә, шулаймыни, кунаклар бар икән, әйдәгез, керегез, рәхим итегез.

Өйдә бернинди җиһаз юк, сәкедә иске генә бер киез. Икесе дә керәләр.

– Әбекәй, хәзер чәй куйыйк, шакмаклар, коры агачлар алып керәм, хәзер чәй эчертәбез.

– Ярар, улым, рәхмәт, рәхмәт.

Шулай итеп, егет самавыр куеп җибәрә. Карчыкның әзер ипие бар икән, ул ипиен егеткә, кызга тәкъдим итә.

– Без ашадык кына, син аша, әбекәй, аша.

Болар карчыкка әйбәтләп чәй эчертәләр.

Карчык әйтә:

– Минә еракта бер чишмә бар, шуның суын эчсәм, мин сихәтләнер идем. Ул чишмәнең суын алып кайту, әлбәттә, җиңел түгел. Алып кайта алмассызмы икән?

– Алып кайтам, әби. Мин суга киттем, ә син әбинең өйләрен җыештыр, ярыймы?

– Ярый.

Хәзер кыз өй җыештырырга кала, егет, чиләк алып, суга китә. Әби хәзер моны бөтен урыннардагы ерткыч тавышлары чыгарып куркыта башлый. Әмма егет бара: «Мин суны алып кайтырга тиеш», – ди. Ерак бара. Барса, матур тау, тауда өч чишмә: берсеннән чыга зәңгәр су, берсе – ак су, берсе кайнаррак сулы. Егет хәзер әйтә:

– Кайсысын алып кайтыйм икән? Тукта, татып карыйм әле.

Башта зәңгәр суны татып карый. Нигәдер бөтен тәне, гайрәтләнеп, үзеннән-үзе көч ала. Ак суны эчеп карый – искиткеч көч керә моңа, тауларны күчерерлек көч сизә үзендә. Ак суны чиләк белән алып кайта. Әби урманны шушы хәлгә китерә ки, егет бер тамчы суны да түкми. Алып кайткач, әби әйтә:

– Рәхмәт, улым. Бер кешенең дә миңа чишмә суы алып кайтып эчергәне юк, бик рәхмәт сиңа!

Әби чишмәнең суын эчә. Таңсылу өйләрне ялт иттереп җыештырып чыгарган. Алар әйтәләр:

– Әби, менә аланлыкта бик шифалы чәчәкләр үсә. Шуларны җыеп кайтыйк.

Егет аланлыкка чыгып китә, кызны тагын калдыра. Аланлыкка барса, хуш исләрдән исерә торган, шул кадәр матур чәчәкләр күреп, хуш исләр тоеп, хәйран кала егет. Хуш исләрдән күзләре йомылып китә моның.

– Кайсысын алыйм икән, – ди. – Вак кына таҗлы бер чәчәк бар, шунысын алыйм әле.

Алып кайта.

– Сезгә киңәш бирермен, – ди әби. – Яхшы күңелле балаларга рәхмәтем зур, улым. Алып кайтырсың кызны әтисенә. Улым, чормага менче. Шунда чормада төреп куйган бер кәгазем булыр, шуны алып төш.

Егет, җитез генә чормага менеп, кыстырып куйган кәгазьне алып төшә, әбигә бирә. Әби кәгазьне ачып җибәрә – күзләрнең явын ала торган юка ефәк яулык. Зур гына яулык.

– Менә, улым, бабалардан, атамның аталарыннан калган ядкарь. Бу яулык сиңа, ни теләсәң, шуны эшли торган яулык. Син моннан, ачыккан вакытта, нәрсә телисең, шуны сора. Мин сиңа моны

бүләк итәм. Ачыккан вакытта, табынга күңелең теләгән ризыклар киләчәк. Инде берәр җиргә каядыр барасың булса, «Ач!» дип әйтсәң, ул шунда ук җил-палас булып, кирәк урыныңа илтеп куячак. Инде шушы яулыкка урансаң, сине беркем дә күрмәячәк. Шул хәтле серле яулык бу. Син бик ошадың миңа, мин сиңа бирәм аны. Син хәлемне сорадың, кирәкле ярдәмеңне күрсәттең. Мә, улым, ал, – ди әби.

Егет шул кадәр шатлана, нишләргә белми.

– Әбекәем, мин синең изгелегеңне нәрсә белән кайтарыйм? Мин сиңа бурычлы булып калам. Мин нәрсәләр эшлим?

– Улым, күңелең изгелектә булса, эшләрсең яхшылыкны. Ярар, эшләрсең, игелеген күр. Хәерле юл сезгә. Менә шушыңа утырып, тылсымлы сүз әйтсәң, «Тылсым иленә илт, палас!» – дисәң, тылсымлы илгә илтеп куяр.

Әби белән җылы саубуллашалар, әбигә рәхмәтләр әйтәләр, кабат килергә вәгъдә итәләр һәм: «Палас, безне тылсым иленә илт», – дип, яулыкны селкиләр һәм, паласка утырып, урман өстеннән күтәрелеп, әбигә кул болгап саубуллашалар, китәләр. Палас бара да бара, бара да бара. Диңгезләр, урман, кырлар өстеннән үтә. Инде бу тылсым иленә – үзләренең иленә барып җитте. Сарайның матурлыгы югалган, нур чәчеп тормый, эрактан алтыннары да каралган, утраудагы җимеш агачлары корыган, суларның яме киткән, кешеләрнең күңелләре шиңгән. Әткәсенең кайгыдан күзләре сукырайган, елап, авыр хәлдә, үлем хәлендә ята. Хәзер палас, боларның утраулары турысына җитеп, җиргә төшә. Бөтен халык йөгереп килә. Корыган агачлар кинәт, ямь-яшел булып, чәчәк аталар һәм ал, сары, кызыл чәчәкләр күп була. Утрауның алтын нурлар сибә торган сарае үз хәленә кайта. Бар халык йөгереп килә, Таңсылуны кочаклап алалар. Сөенәләр, нишләргә белмиләр, хәзер патшага хәбәр итәләр. Таңсылуны тавышыннан таныган әткәсе, кызын кочаклап, куанып елый. Таңсылу да әткәсен кысып-кысып кочаклап елый.

– Кайттым, әткәем, менә мине шушы яхшы күңелле егет алып кайтып куйды.

– И кызым!

Табын әзерлиләр, бөтен утрау халкы килә. Шундый шатланып, мәҗлес үткәрәләр. Хәзер бөтенесе ни булганын, ни күргәнен кыз сөйләп бирә. Шуннан соң патша әйтә:

– Беркемгә дә бирмәгән кадерле кызымны сиңа бирәм, улым, киявем булырсың, патшалыгым да сиңа булсын, әнкәңне дә алып килерсең. Шушында рәхәт гомер итәрсең, рәхмәт, балам!

Бик тә инде хәер-дога кыла патша. Патшага егет әйтә:

– Падишаһым, солтаным! Сезнең кызыгызны китереп куйдым, әмма аны үземә кәләш итәр өчен түгел. Минем үземнең авылым, кырларым-тугайларым бар. Анда йортым бар, шомыртларым, миләшләрем үсә, анда газиз әнкәм бар. Мин аларны ташлап китә алмыйм. Алар миңа менә шушы алтын сарайлардан күп мәртәбә кыйммәт. Анда минем изге ата-бабамның туфрагы, изге җирем. Бик рәхмәт, бик рәхмәт, мин Таңсылуны моннан аерып, кәләш итеп алып китмим, әмма монда торырга теләмим.

– Бәрәкалла! – диде патша, – рәхмәт, – диде. – Ни телисең, күпме байлык кирәк, алтынмы, акчамы, ал, ал! Мин сиңа җанымны бирергә дә ризамын.

– Юк, рәхмәт, миңа алтын кирәкми, миңа акчалар да кирәкми. Мин бер генә нәрсә телим: мин яңадан сезне терелтәсем, күзегезне ачтырасым килә, үземнән-үзем шунда канәгать булачакмын. Мин сезгә дару табып алып килермен, күзегез ачылыр, – ди.

Таңсылу һәм бөтен утрау халкы егетне озатып кала. Егет, теге карчыкны эзләп, килеп төште урманга. Карчык моның киләсен сизеп тора. Егет әбинең хәлен сораштыра. Әби аны үз баласы кебек кабул итә.

– Әбекәем, син шундый яхшылыклар эшләдең, Таңсылуны кайтарып куярга шундый ярдәм иттең. Әбекәем, шул патшаның күзен ачып терелтергә ярдәм итсәң, гомер буе хезмәт итәр идем. Нәрсә генә теләсәң дә эшләр идем.

– Бар, ак чишмәдән су алып кайт. Менә сиңа савыт.

Аңа әби бер шешә бирә:

– Менә шул суны этисенең күзләренә сөрт, тәннәренә сөртсәң, әнкәсе терелер, әткәсенең күзләре ачылыр.

Суны егет алып кайта, паласына утырып оча. Егет барып җитә. Аны шундый итеп каршы алалар! Ул сарай эченә кергәч, Таңсылу аны нишләргә дә белмичә каршы ала. Шул кадәр ярата, шул кадәр ярата:

– Килдеңме, сөеклем!

– Хәзер әткәңнең күзен ачарбыз, әнкәң терелер.

Хәзер патша янына бара:

– Менә шушыны күзеңә сөрт, хатының тәненә сөртсен.

Патша күзенә сөртә, бөтен дөньяны, аны тавышыннан гына белә иде, күзләре ачыла, егетне күрә. Шатлыгыннан нишләргә дә белми. Ул шул кадәр дә ошата егетне, ярата. Хатыны да терелә, сәламәт, элеккедән дә сәламәтрәк була. Шундый зур шатлык утрауда. Яшьләр тормышына, патшаның тормышына бөтен утрау халкы шатлана. Җыелып, яңадан мәҗлес оештыралар, бөтенесе ялыналар, ялваралар:

– Кал, син бит безгә шул кадәр кадерле кеше. Без сине гомер буе патша итеп тотарбыз!

Егет әйтә:

– Бик рәхмәт, ихтирам итүегез өчен рәхмәт. Ләкин бит минем шундый яхшылыкларымны әнкәмә дә эшлисе бар әле. Кабат әйтәм: бернинди байлыкларга да, бернинди гүзәл урыннарга да мин үземнең әнкәмне, туган туфрагымны алыштыра алмыйм. Сез мине гафу итегез, мине әнкәм көтә торгандыр.

Таңсылу әйтә:

– Мин сиңа ияреп китәм, мин тора алмыйм синнән башка, тора алмыйм.

Егет әйтә:

– Син кал, синең әткәң-әнкәң биредә, алар синсез тора алмый.

Бөтен утрау халкы аны озатып калалар. Ул паласына утырып кайтып китә, әби янында була. Аның хәлен белә, чишмә суы алып килә һәм әйтә:

– Әби, мин кешеләрне әби-бабайларыгыздан калган ядкарь белән шатландырдым, инде аны үзегездә саклагыз. Бик рәхмәт, рәхмәт, әбекәем, алып куй, кирәк булса килермен.

Егет, яулыкны кайтарып биреп, урынына урнаштырып, авылына кайтып китте. Әнкәсе, чыгып, аны каршы алды. Улының кайтканына сөенде. Тегенең ничек-ничек Таңсылуны озатканын белгәч, әнисе бик нык шатлана. Улының ерак киткәнен белгәч, әнисе бик кайгырган иде, бик таушалган иде, улы кайткач, бик сөенә. Егет, кашка атын алып, әтисе йөргән тугайларга, болыннарга чыгып китә.

Ядегәр авылында Сания<br>Хәсән кызыннан язып алынды. 1985

## Мөнәҗәт

Бисмиллаһир-рахманир-рахим.
Куркамын мин нәүбәтеңдин,
Төрле-төрле һиммәтеңдин.
Өмет итәм рәхмәтеңдин,
Кунак ашы җәннәтеңдин.
Җитәдер үлем нәүбәти,
Катыдыр аның һиммәти.
Аллаһның чиксез рәхмәти,
Ни әйләсә – үз кодрәти.
Җан бирүе ачы диләр,
Илаһым, бир үзең түзем.
Җан биргәчтен, йомылыр күзең,
Яфрак күк саргаер йөзең.
Сырхау хәле мөшкел икән,
Алып килерләр мулланы.

Күңелендә тотса Аллаһны,
Зикер әйтеп чыгар җаны.
Зикер әйтеп чыгар җаны,
Тамырлардан күчәр каны,
Ерак торыр якыннары.
Килсә бер көн әҗәл җитеп,
Йомшак түшәкләрдән төшеп,
Кара җир астына кереп,
Ярдәм кыйл, йә Рәсүлалла!
Ике куллар минем күршем,
Калмас янда якын кешем.
Йә хәсрәтле минем башым,
Ялгыз гүрләрдә калганмын.
Синең урының тыныч булыр,
Изге иманың саклагач.
Гүр эчендә нык йокларсың,
Кара туфраклар каплагач.

Ядегәр авылында
Оркыя Камаловадан (1905 елда туган)
язып алынды. 1985

# МИҢЛЕМУЛЛА ҺАМАН УЙДА

*Ленар Җамалетдинов*

Татар халкы кайсы гына төбәктә яшәсә дә, аның үзенчәлекле, бай фольклор хәзинәсе була. Аның сакланышы төрле факторларга бәйле: әйтик, теге яки бу төбәктә татар халкы тупланып яшиме, әллә башка милләтләр белән катнаш хәлдә көн күрәме; төрле мәдәни чараларда, бәйрәмнәрдә һәвәскәрләр тарафыннан фольклор файдаланыламы; халык телендә йөргән фольклор әсәрләрен махсус җыючы, бәһали алучы шәхесләр бармы; бу төбәктә фольклор экспедицияләре эшләгәнме, алар туплаган фольклор әсәрләре ышанычлы кулларда сакланамы һ.б.

Инде искәрткәнебезчә, төбәкләрдә фольклорны аеруча яратучы һәвәскәр затлар булырга мөмкин. Алар гадәттә фольклорның аерым жанрларын үз итәләр, аларны дәфтәрләргә теркәп баралар, саклыйлар, хәтта әлеге язмаларын фольклорны фәнни өйрәнү үзәкләренә җибәрәләр. Бу җәһәттән архивларда бигрәк тә җыр, бәет дәфтәрләре еш очрый. Әкиятләрне туплап, зур күләмле җитди коллекцияләр булдырган һәвәскәрләр дә мәгълүм. Шундыйларның берсе – Кукмара районының Байлангар авылы кешесе Миңлемулла Кәримуллин.

Безнең мирасханәдә Миңлемулла Кәримуллинның Байлангар һәм Каенсар авылларында төрле елларда язып алынган 30 әкияте саклана. Аларның бер өлеше Бөек Ватан сугышына кадәр үк, 1939–1941 елларда кәгазьгә төшерелгән һәм Казанга Тел, әдәбият һәм тарих институтына җибәрелгән.

Миңлемулла Кәримуллин Байлангар авылында 1913 елда туган. Авыл башлангыч мәктәбен һәм Кукмара киез итек фабрикасы каршында ачылган кичке мәктәпне тәмамлаганнан соң, курсларда укып, 1932 елда Кукмара МТСында тракторчы булып эшли

башлый. Дүрт елдан соң, эш вакытында бәхетсезлеккә юлыгып, 23 яшьлек егет бер аяксыз кала. Шулай да тракторын ташламый, сыңар аяклы килеш, эшләвен дәвам иттерә.

Шушы дәвердә ул күп укый, үзе дә иҗат белән шөгыльләнә башлый, пьесалар язып карый, авылдашларыннан халык әкиятләрен язып алып, Казанга фольклорчы Хәмит Ярмигә җибәрә, аның фикерен сорый.

Сугыштан соңгы чорда да бу энтузиаст халык әкиятләре белән кызыксынуын дәвам итә. 1948 елда Х. Ярмигә юллаган хатында ул, моңа кадәр җибәргән әкиятләренә дә җавап алмавы турында әйтеп, «киләчәктә фольклор материаллары җыю кагыйдәләрен өйрәнүдә ярдәм итүегезне үтенәм», – дип яза.

Күренә ки, авылның гади тракторчысы Миңлемулла Кәримуллин фольклор җыю, төгәлрәк әйткәндә халык телендәге әкиятләрне туплау, эшенә җитди карап, бу шөгыльнең методикасын үзләштерү зарурлыгын аңлау дәрәҗәсенә күтәрелә. Әмма җавап, ни өчендер, һаман да язылмый. 1949 елда ул Х. Ярмигә янә әкият текстлары һәм берничә иске китап сала, киләчәктә тагын әкиятләр җибәрергә вәгъдә итә.

Сугыштан соңгы хатларын М. Кәримуллин инде Каенсар авылыннан яза. Бәлки ул шунда яшәгәндер дә.

Бәла ялгыз йөрми, диләр. Миңлемуллага тагын бер бәхетсезлек килә: ул, тракторда эшләгәндә тимер чәчрәп, бер күзсез кала, икенчесенә дә зарары тия. Бу хәл 1954 елда була. Нәтиҗәдә 41 яшьлек ир бөтенләй эшли алмас хәлгә төшә һәм зур булмаган пенсия хисабына яшәргә мәҗбүр була. Әмма әкиятләргә булган мәхәббәте барыбер кимеми.

М. Кәримуллинның 1959–1960 елларда язылган хатлары Свердловск өлкәсендәге Вагранская станциясеннән килә. Нинди язмыш аны ул якларга илтеп ташлагандыр, анысы безгә мәгълүм түгел. Әмма биредә дә ул үзенең мавыгуын ташламый – Институтка Х. Ярми исеменә тагын унлап әкият тексты җибәрә. Бу әкиятләрне ул, элек ишеткән булып, шунда исенә төшереп язган булса кирәк. Чөнки кайберләрендә «1954 елны Сабир Мусабаевтан», «Сәетгалиев Сәетгәрәйдән» дигән искәрмәләр бар. Шуның өстенә үзенең хатында ул: «Биредәге кешеләрдән дә әкиятләр язып алырга уйлаган идем, андый кешеләрне таба алмадым», – дип яза. Димәк, фаразыбыз дөрес булырга тиеш.

М. Кәримуллинга җавап хаты үз вакытында язылмаган, күрәсең. Чөнки Миңлемулла биредән (Свердловск өлкәсеннән) язган хатында да методик ярдәм соравын дәвам итә. «Бәлки мин бик күп вакытымны бер дә кирәксезгә, бушка уздыра торганмындыр, минем җибәргән әкиятләрем турында дөрес җавап бирүегезне үтенәм. Әкиятләрнең теленә килсәк, үзем ничек сөйлим, шулай язам. Башкача яза алмыйм», – дип хәбәр итә ул Х. Ярмигә 1960 ел башында.

Ниһаять 1960 елның 10 гыйнварында аңа җавап хаты җибәрелә. Хат текстының күчермәсе теркәлмәгән, бәлки анда бу тынгысыз затка тиешле киңәшләр бирелгәндер.

М. Кәримуллин әкиятләре белән беренче тапкыр фольклорчы һәм язучы Э. Касыймов кызыксына. Ул үзе төзегән «Абага чәчәге» исемле сатирик әкиятләр җыентыгына (Казан, 1962) Миңлемулланың өч әкиятен кертә. Ә татар фольклорының 12 томлы фәнни җыелмасындагы әкият томнарының 3 нче китабына (Казан, 1981) мин үзем М. Кәримуллинның тагын ике әкиятен тәкъдим иттем. Аның басылган әкиятләреннән «Алдакчы Тимер», «Кол һәм алпавыт», «Абага чәчәге» дигәннәре аеруча кызыклы.

Димәк, М. Кәримуллин җибәргән 30 әкиятнең бишесе абруйлы фәнни җыентыкларда дөнья күргән. Янә дә шул ук күптомлы фәнни җыелманың Х. Ярми һәм Х. Гатина тарафыннан төзелгән «Тылсымлы әкиятләр» томында (2 нче китап. Казан, 1978) М. Кәримуллинның тагын дүрт әкияте телгә алына (алар алда искә алган китапта басылган әкиятләрнең вариантлары буларак күрсәтелә). Шулай итеп, мирасханәдә саклана торган (ФФ., колл. 2, папка 1) 30 әкиятнең 9 ы фәнни әйләнешкә кергән дигән сүз. Басылырга лаеклы әкиятләр әле тагын бар.

М. Кәримуллинның шуннан соңгы язмышы безгә мәгълүм түгел. Әгәр аның якташларыннан берәр кеше, эзтабарлык эшенә алынып, бу мәсьәләгә ачыклык кертә алса, бик игелекле гамәл булыр иде.

Бу китапка кертелгән башка әкиятләрнең кайда һәм кемнән, кайчан, кем тарафыннан язып алынуы күрсәтелде.

Китапка шулай ук йола һәм уен җырларыннан берничә әсәр кертелде. Янә бер бәет һәм балалар фольклорының төрле жанрларына караган үрнәкләр урнаштырылды. Бу соңгылары нигездә фольклорчы Р. Ягъфәров инициативасы белән тупланган иде.

## Кырык уллы кеше

Әүвәле заманда бар иде, ди, ирле-хатынлы ике кеше. Шуларның бар иде, ди, кырык улы. Балалары күп булгач, аптырыйлар, нишләргә дә белмиләр. Аптырагач, киңәшеп, һөнәргә өйрәтә башлыйлар.

Тора-бара һөнәргә өйрәнеп җитәләр дә эшли башлыйлар. Үзләре көн күрерлек булгач, аталары белән киңәш итеп, өйләнмәкче булалар, шул шарт белән: булсын кырыгына кырык кыз, алар барысы да бер анадан булсыннар. Шулай киңәшләшкәч, олы уллары шундый кызларны эзләргә чыгып китә.

Бара. Бер көн бара, өч көн бара, дүртенче көн бер елга буена туры килә. Анда була бер аждаһа, ул аждаһа яныннан узып китәр өчен бик тә зур көч кирәк була, чөнки ул аждаһа узып китүчеләрне йоклата. Ә бу егет елгада үскәнлек белән, моның хәйләсен сизеп, йокламыйча гына узып китә.

Шуннан ул китә. Ай бара, ел бара, карыш буе җир бара. Бара торгач, бер шәһәргә барып төшә. Шәһәр кырыендагы бер карчыкка керә. Карчыктан сораша, карчыкка үзенең нәрсә эзләвен сөйләп бирә. Карчык бу шәһәрдә андый кызлар барлыкны әйтә. Шуннан егет иртәгесен торып, бара шул йортның капка төбенә. Барып керә. Сәлам биреп, исәнлек-саулык сорашып, үзенең хәлен сөйли башлый, кырыгына кырык кыз кирәклекне әйтә. Кызларның ата-аналары сөйләшеп, кызлары белән киңәшеп, олы кызны бу егеткә бирәләр. Егет, кыз белән күрешеп, берәр көн гомер итеп, шуннан кызны өенә алып кайтып китә.

Атна кайта, ел кайта. Теге аждаһалы елгага кайтып җитә. Аждаһа йоклатырга тырышса да, егет тагын йокламый гына узып китә. Шул аждаһадан узгач, өч көн кайта, дүртенче көн өенә кайтып җитә. Кайткач, кырык кыз табуын, үзенең шуларның берсенә өйләнүен сөйләп бирә. Шуннан киңәшәләр дә, егет үзе өйдә калып, ата-аналарын, туганнарын кырык пар атка утыртып җибәрә. Кырык беренче парга үз хатынын утыртып җибәрә. Үзе дә теге аждаһадан узганчы озата китә.

Баралар-баралар, теге аждаһа яныннан узып китәләр. Шуннан көн баргач, төн баргач, ел баргач, олы уллары әйткән шәһәргә барып керәләр. Кызлар егетләрне шатлык белән каршы алалар. Шуннан, муллалар чакыртып, тотыналар туй ясарга. Туйда була кырык

мичкә аракы, кырык мичкә бал. Көн эчәләр, төн эчәләр, атна буе туй ясыйлар. Аннары, абыйлары әйткән вәгъдәгә туры китереп, кайтырга юлга чыгалар. Барысы да шатланыша-шатланыша кайталар. Олы абыйлары хатыны гына, кияве булмаганга, күңелсезләнебрәк кайта.

Көн кайткач, төн кайткач, ел кайткач, килеп җитәләр болар аждаһалы җиргә. Аждаһа боларны йоклатып, чолгап ала. Абыйлары өйдә көтә, тегеләр кайтмый көткән вакытта. Шуннан аждаһаны уйлап, каршы алырга чыгып китә. Барып җитә, күрә, аждаһа тегеләрне чолгап алган. Әйтә:

– Йә, аждаһа, сиңа ни кирәк, ник җибәрмисең? – ди.

Аждаһа әйтә җавабында:

– Фәлән җирдә, фәлән шәһәрдә фәлән патшаның алтын чәчле кызы бар. Шул кызны алып кайтып бирсәң, боларны җибәрәм, – ди.

Егет:

– Кыз синеке булыр, – дип, энеләрен уятып өйгә алып кайтып китә.

Бер көн кайта, өч көн кайта. Дүртенче көнне кайтып җитәләр. Өйгә кайткач, олы абыйлары өч көн үткәрә дә, шуннан ата-аналары, туганнары белән бәхилләшеп, алтын чәчле кызны эзләргә чыгып китә.

Көн бара, төн бара. Бара торгач, барып җитә бер урман янына. Күрә: урманда бер кеше кулы белән имәннәрне тота да йолкып ташлый, тота да йолкып ташлый. Егет барып аңарга сәлам бирә, исәнлек-саулык сораша:

– Син кем буласың, нигә бу имәннәрне йолкыйсың? – ди.

Теге җавап бирә:

– Мин булам Имән батыр, – ди.

Шуннан Имән батыр сорый:

– Егет, бу урманнарда ялгызың нишләп йөрисең, кая барасың? – дип.

Егет үзенең хәлен сөйләп бирә. Әйтә:

– Фәлән-фәлән патшаның алтын чәчле кызы бар, шуны алмага барам, – дип.

Егетнең сүзенә җавап итеп, Имән батыр әйтә:

– Мине дә алып бар, мин сиңа кирәк булырмын, – ди.

Икәү бергәләп китәләр. Баралар, баралар, көн баралар, төн баралар. Бик күп киткәчтен, барып җитәләр бер таш-тау арасына.

Күрәләр, бер егет таш чөеп уйный, һавага зур-зур ташларны чөеп җибәрә дә, шул ташлар, һавадан аның тезенә төшеп, тузан булып китәләр. Юлчылар бу таш чөеп уйнаган егеттән сорашалар:

– Ник болай иттереп уйныйсың? – дип.

Егет әйтә:

– Минем кәсебем шул, – ди.

Болар сорыйлар:

– Синең исемең ничек? – дип.

Теге әйтә:

– Минем исемем Таш батыр, – ди.

Шуннан соң Таш батыр болардан сораша башлый.

– Сез нишләп йөрисез, кая барасыз? – ди.

Болар үзләренең хәлләрен сөйләп бирәләр, фәлән-фәлән шәһәрдән фәлән патшаның кызын алмага барабыз, диләр.

Таш батыр әйтә:

– Мине дә алып барыгыз, минем дә кирәгем булыр, – ди.

Шуннан китәләр өчәүләп.

Болар өчәүләп баралар, баралар, болын буйлап баралар, кара урманнар үтеп китәләр. Бара торгач, барып җитәләр зур гына күлгә. Күлнең буе да юк, иңе дә юк, һичкайдан чыгарга юл юк. Күлнең әйләнәсендә йөри торгач, очрыйлар бер кызга. Кыз болардан сораша башлый:

– Нинди кешеләр, кая барасыз, нишләп бу тирәгә килеп эләктегез? – дип.

Шунда болар үз хәлләрен сөйлиләр:

– Бара идек фәлән шәһәргә, фәлән патшаның алтын чәчле кызын алыр өчен. Ләкин безнең юлыбызда тоткарлык бар, күлне һич кичеп чыгар хәл юк, – диләр.

Кыз әйтә:

– Әгәр дә мине дә алып барсагыз, мин сезне кичерермен, – ди.

Дүртәве дә бергә китәргә риза була. Кыз шул минутта күлнең суын эчеп бетерә дә күлнең урыны коры җир булып кала. Күл аша чыгалар да, чыккач, кыз яңадан күлне күл иттереп калдыра. Шуннан китәләр. Көн барып, ай барып, барып керәләр бер шәһәргә. Шәһәрдә алтын чәчле кызны сорашалар, һичбер белгән кеше юк. Күп кенә сораша торгач, алар бер карт кына карчыкка туры киләләр. Ул карчык патшаны белә икән. Ул боларга әйтеп бирә: фәлән-фәлән урамда, дип. Барып җитәләр патшаның капка төбенә. Киңәш

итеп, капка төбендә барысын да калдырып, егет үзе генә патшаның дворецына кереп китә.

Патша бер заман ят кеше барын күрә дә, сорый башлый:

– Син нинди егет, ничек курыкмыйча монда килдең? – дип.

Егет әйтә җавабында:

– Мин фәлән кешенең олы улы. Алтын чәчле кызыңны алмага килдем, – ди.

Шуннан патша әйтә:

– Бер көрәшчем, бер йөгерешчем бар. Шуларны җиңсәгез, кырык мичкә скипидәрем бар, шуны эчеп бетерсәгез, шул чагында гына кызымны бирәм, – ди:

Егет, бик кайгы белән генә чыгып, иптәшләренә хәлне сөйли.

Иптәшләре:

– Курыкма, без аны булдырабыз, шулай дип кереп әйт патшага, – диләр.

Шуннан егет патшага кереп әйтә:

– Давай батырларыңны, – ди.

Патша батырларын китерә. Өч көн чик куя. Әгәр дә өч көн эчендә патшаның батырын екса, йөгереген дә узып китсә, кырык мичкә скипидәрне дә эчеп бетерсәләр – шул чагында патша кызны бирергә вәгъдә кыла.

Майның тугызында иртә белән сәгать тугызда көрәшә башлыйлар кичке алтыга кадәр, һичберкем һичберәүне җиңә алмый. Бу көнне шуның белән бетерәләр. Майның унысы көнне иртә үк башлыйлар. Кичке сәгать алтыга кадәр тагын берсен-берсе җиңә алмыйлар. Майның унберенче көнендә, актык көнне иртә белән сәгать җидедә тотыналар. Актык куәтләре белән кичке алтынчы яртыга кадәр берсен-берсе ега алмый. Актык чиккә ярты сәгать вакыт калгач, Таш батыр куәт биргән күк: «Йә, Имән батыр, ни йөрисең?» – дип әйтүгә, Имән батырның куәте килеп, күтәреп алып бәрә. Патшаның көрәшче батырын атып бәрү белән, яртылай җиргә керә. Шулай итеп, патшаның бер батыры җиңелә.

Майның уникесе көнне йөгерергә баралар. Патшаның ике йөгерүчесе белән Таш батыр китә. Таш батыр үзенең хәйләкәрлеге белән тегеләрдән артка качып калып, патша йөгерүчеләренең үз янына әйләнеп килгәннәрен көтеп ята да, ике кулына ком учлап, тегеләрнең күзләренә бәрә. Тегеләр шунда егылып калалар. Таш батыр үзе алдан йөгереп килә. Ә тегеләр Таш батыр килгәннән әллә

нихәтле соң гына килеп җитәләр. Шулай итеп, патшаның йөгерекләре дә җиңелә.

Инде чират җитә скипидәр эчәргә. Теге кыз кырык мичкә скипидәрне бер минутта, аһ та итми, эчеп бетерә. Патшаның моңа бик эче поша. Патша, вәгъдәсеннән язып, янә кырык мичкә эчәргә куша. Кыз аны да эчеп бетерә. Патша йөрәгенә чыдый алмый:

– Тагын кырык мичкәне эчеп бетерсәң, кызымны бирермен, бетерә алмасаң башыңны кистерәм, – ди.

Кыз бу кырык мичкәне дә эчеп бетерә. Патша шуннан алтын чәчле кызын бирергә риза була.

Дүртенче көнне патша үзенең кызына унике йөк мал биреп, озатыр өчен ничәмә вәзир биреп, кызыннан аерылып кала. Таш батыр, Имән батыр, кыз, егет – һәммәсе юлга чыгалар. Кайтырга чыккач, ай баргач, ел баргач, кыз скипидәрне түгеп калдырып, тагын баргач килеп җитәләр баягы күлгә. Күлгә җиткәч, вәзирләр кайтып китәләр. Кыз баягыча күлне эчеп бетерә дә, болар чыгып китәләр. Кыз, исәнлек-саулык теләп, шул урында кала.

Егетләр үз юллары белән китәләр. Баралар, баралар, бик күп баргач, Таш батыр урынына кайтып җитәләр. Таш батыр да исәнлек-саулык теләп, үз урынында калып, озатып җибәрә. Егеткә бер бик үткен кылыч бүләк итеп бирә. Бу кылыч ике яклы булып, уртасында тоткасы була. Таш батыр әйтә:

– Аждаһа сине, өч чакрым калгач, суырыр, шушы кылычны тотып барырсың. Аждаһа авызына җиткәч, шушы кылыч белән аны ярып чыгарырсың, – ди.

Шулай итеп аерылалар. Шуннан болар тагын үз юлларына китәләр. Ай баргач, ел баргач, кайтып җитәләр Имән батыр урманына. Шунда Имән батыр да, исәнлек-саулык теләп, аерылып кала. Егет, берничә көн үткәч, унике йөк мал төяп, кыз белән өенә кайтып керә. Ата-аналары, туганнары шатланышып каршы алалар. Шуннан кызны, малларны өйдә калдырып, егет китә аждаһа янына. Аждаһа егетне, өч чакрым калгач, суыра башлый. Егет кылычын тотып барып җитүенә, аждаһа суырып йотыйм дигәндә, егет аждаһаны бөтен буена ярып чыга. Шул вакыт аждаһа җаны чыгып бетәр алдыннан егеткә әйтә:

– Егет, тагын муеныма чап, болай калдырма, – ди.

Егет әйтә:

– Егет кешенең сүзе дә, эше дә бер була, бер эшне икенче тапкыр эшләми, – ди.

Әгәр дә муенына чапса, аждаһа терелер иде. Егет тагын да чапмый, шул бер чабуы белән эшне тәмам итеп, өенә кайтып китә.

Июнь числосында гына барып кайттым, һаман шулай исән-сау торалар икән.

Кукмара районында яшәүче Галим Галиуллиннан
Г. Толымбай язып алган. 1936

## Өч күгәрчен

Борын-борын заманда булган икән, ди, ярлы гына бер кеше. Бу кешенең булган, ди, бердәнбер улы. Тормышлары авыр булгач, берәү генә булса да, болар малайларын бик яшьтән эш эзләргә чыгарып җибәргәннәр. Малай, бик ерак шәһәрләргә китеп, чит җирләрдә байларга хезмәт итеп йөргән. Үсеп җиткәч, ата-аналарын сагынып, авылына кайтырга булган бу.

Үзегез беләсез: ул вакытта бит ярлы кеше гел җәяү йөри торган булган, хәзерге кебек машина-фәлән дә юк, тимер юлы юк та юк инде.

Ике кадак сохарины капчык төбенә салып, юлга чыгып китә бу. Кайта шулай, атна кайта, ай кайта; бик ашыйсы килсә, бер-ике кисәк сохарины суыра да, ярга ятып су эчеп, тагын алга китә. Кайта торгач, бу егет барып керә, ди, бик калын урман эченә. Урман юлы белән бара торгач, бу юл тар гына бер сукмакка әйләнә. «Адашсам адаштым инде, барыйм әле мин шул сукмак беткәнче», – дип уйлый бу. Бара торгач, барып чыкты, ди, бу бик текә бер тау буена. Тау шулхәтле биек, ди, түбәсенә күтәрелеп карасаң, башыңнан бүрегең төшәрлек. «Ни булса булыр», – дип, егет әлеге сукмак белән тау башына менеп китә. Текә ярларны, зур тау-ташларны үтеп, өч атна дигәндә генә бу егет менеп җитә, ди, теге биек тау башына.

Тау башына менсә, анда төрле-төрле бакчалар, матур агачлар үсеп утыра, ди, агачларда төрле татлы җимешләр пешеп тора, ди. Тауның иң биек җиренә басып карый, ди, бу. Шуннан бөтен тирәяк ялт итеп күренеп тора, ди. Шулхәтле матурлыкка егет шакката. Карый торгач, күрә бу: тауның уң ягында, нәкъ менә шушы тау кебек, тагын бер тау бар икән, ди. Ике тау арасында бик зур бер алан, ә шул алан уртасында утыра икән, ди, бик матур итеп эшләнгән бер йорт. «Бу йортта бер-бер кеше булмый калмас», – дип, егет төшеп китә шул йортка таба киткән сукмак белән. Бара-бара бу, йорт янына барып җитә. Йорт бик матур бакча эчендә утыра икән. Ишеген

ачып, йорт эченә керә. Йорт эчендә беркем юк, тып-тын, ди. Бөтен бүлмәләрне карап чыга, бер кешене дә таба алмый. Бу егетнең карыны бик ачкан була. «Ашарга берәр нәрсә юкмы икән?» – дип, мичне ачып карый, ни күзе белән күрсен: мич тулы ризык. Шуннан соң бу шундагы бер шкафны ачып караса: шкаф тулы төрле эчемлек. Бу мичтән пешкән әйберләрне алып, тамагын туйдыра да: «Кем булса да кайтыр әле», – дип ятып йоклый. Бик арган булганлыктан, яту белән йокыга да китә бу.

Бер заман уянып китә дә, тавышсыз-тынсыз гына тыңлап ята. Озак та үтми, тәрәзә ачылып китә, тәрәзәдән өч күгәрчен гөрләп кайтып керә. Күгәрченнәр кайтып керәләр дә бик чибәр өч егеткә әвереләләр. Килеп керү белән үзара: «Булмады бит, ә, булмады», – дип бик кайгырышып сөйләшә башлыйлар. Шулай үзара сөйләшә-сөйләшә, болар ашарга хәзерләнәләр. Араларыннан берсе аш алырга дип мич янына бара, барса, андагы әйберләрнең кузгалганлыгын сизә. Иптәшләрен мич янына чакырып китереп, әйберләрне карыйлар – әйберләр чыннан да кузгалган. «Гомердә мондый хәл булганы юк иде, кем керде микән монда?» – дип, барлык бүлмәләргә кереп карый башлыйлар. Эзли торгач, бу егетне табалар.

Егетне караватастыннан тартып чыгардылар. «Болар мине нишләтерләр икән инде?» – дип, егет куркуга төште. Егетне үз каршыларына утыртып:

– Син монда хәтле ничек итеп килә алдың, нинди кеше син, кая барасың? – дип сораша башладылар.

Сораша-таныша торгач, егетнең зарарлы кеше булмавын белделәр, «бу бик чибәр кеше икән» дип, аңа сый-хөрмәт күрсәттеләр. Шуннан соң болар:

– Әгәр дә ошаса, син бездә берәр ел хезмәт ит, аннан соң китәрсең, – диләр.

Егет, ризалык биреп, болар янында калырга, аш-су әзерләп торырга булды.

Ярар. Егет шулай яхшы гына хезмәт итә. Бу өч күгәрчен-егетнең җиде амбары бар икән. Егет боларда унбиш көннәр чамасы хезмәт иткәч, өч күгәрчен-егет моңа җиде амбар ачкычын бирделәр. Егетне үзләре белән алып, алты амбарны күрсәтеп чыктылар. Ә җиденче амбар турысына килеп җиткәч, бер алтын ачкычны алып:

– Менә бу җиденче амбар ачкычы, бу амбарны безнең рөхсәттән башка ачма, – диделәр.

Өч күгәрчен-егет һаман үз хезмәтләрендә йөриләр, иртән чыгып китәләр, кич кайталар. Егет тә һичбер хыянәтсез генә хезмәт итә. Атна үтә, ай үтә. Бер ай вакыт үткәч, бу егетнең башына бер уң төшә: «Тукта әле, ди, мин бу җиденче амбарны ачып карыйм, нәрсә бар икән анда?» – ди. Шулай уйланып йөри-йөри дә бу, бервакытны тегеләр тәрәзәдән очып чыгып китү белән, җиденче амбар янына бара, алтын ачкыч белән алтын йозакны ача. Шуннан соң амбар ишеген әз генә ачып карый. Ачып караса: ишек ярыгыннан кояш яктысы шикелле яп-якты нур чыга. Якынрак килеп карый, караса: амбар эчендә айның ундүртенче кичәсе кебек нур чәчеп, бик матур бер кыз утыра, ди. Егетне күрү белән, бу кыз телгә килеп: «Эшләпәм, эшләпәм», – дип, гел шул бер сүзне генә кабатлый икән. Егет, бу кызның матурлыгына шаккатып: «Бу нигә бертуктаусыз “эшләпәм, эшләпәм” дип әйтә икән?» – дип уйлап, ишекне ябып, амбарны алтын йозак белән бикләп куя.

Кич җиткәч, күгәрченнәр очып кайтып тәрәзәдән килеп керәләр. Хәзер егет боларга бөтенләйгә ияләшеп җитә, тегеләр дә моңа бик нык ышандылар инде. Ашарга утыргач, егет, сүз башлап, теге өч егеткә әйтә:

– Мин сездә икенче аемны хезмәт итәм инде, ди, сез иртә чыгып китәсез, кич кайтасыз, нишләп йөрисез соң сез? – ди.

Бу күгәрченнәр бер-берсенә карашып алдылар да, бу егеткә ышанганлыкларын күрсәтеп, олы күгәрчен болай дип сүз башлады:

– Әйтсәк әйтик инде, ди. Менә фәлән патшаның кызын дию пәрие урлап киткән иде, ди. Ул минем яшьтән үк яраткан кызым иде. Шул кызны дию пәрие кулыннан коткарып кайту өчен егерме өч ел йөрдек инде без, ди. Йөри торгач, кызның үзен коткарып алып кайттык, тик менә эшләпәсе дию кулында калды, – ди.

– Нигә, эшләпәсе булмаса ярамыймыни? – ди егет.

– Кыз шул эшләпәсеннән башка якты дөньяга чыгып йөри торган кыз түгел, менә шуның эшләпәсен алып кайтырга дип йөрибез без, ди, бер дә җае чыкмый әле, – ди.

Егет аптырый инде:

– Нишләп, ди, аңа икенче эшләпә тегеп биреп булмыймыни? – ди.

– Юк, ди, ул кечкенә вакытта авыру булган, врачлар аңа шушы эшләпәне ясап биргәннәр, шуннан соң ул шул эшләпә белән генә йөри ала торган булып калган, – ди күгәрчен.

Егет әйтә:

– Ул эшләпә артыннан мин барып карасам ничек булыр икән соң? Мин алып кайта алмаммы икән? Ул дию пәрие тора торган җирләр моннан еракмы? – ди.

– Әй, егет, – ди күгәрчен, – син генә барып җитә торган җир түгел ул, ди. Аның өчен җиде диңгез кичәргә кирәк. Җиде диңгезне үткәч, сигезенче диңгез башлана. Әнә шул сигезенче диңгез уртасында бер утрау бар. Шушы утрауның өстендә дию пәриенең сарае бар. Кызның эшләпәсе әнә шул сарайда калган, – ди.

– Соң ул эшләпә кайда саклана икән? – ди егет.

– Кызның эшләпәсе кырык кат сандык эчендә саклана. Ул кырык кат сандык эчендә кырык кат тартма булыр. Менә шул кырык кат тартманың иң эчкәре тартмасында саклана ул эшләпә, – ди күгәрчен.

– Ул кырык сандыкны ничек итеп ачарга кирәк икән соң? – дип сорый теге егет.

– Ул кырык сандык кырык төрле йозак белән бикләнгән, һәрбер йозакның үзенә аерым ачкычы бар, – ди.

Бу егет аптырап әйтә:

– Әй, – ди, – бу һичкем булдыра торган эш түгел икән, ди, зрә генә йөрисез икән сез, – ди.

Шуннан соң күгәрчен-егетләр үзара сөйләшеп алалар да: «Әйдә, без бу егетне үзебезнең һөнәрләргә өйрәтик әле, бик уңган егет күренә, тиз генә отып алыр ул», – диләр.

Бер заманны болар егетне өйрәтә башлыйлар. Егет шулкадәр тырышып өйрәнә боларның һөнәрләрен, өч ай дигәндә, үзләреннән артык белә бу. Егет хәзер теләсә нәрсәгә әверелә ала: үсемлекме, кешеме, хайванмы, киекме – барысы да була бу.

Күгәрчен-егетләр үзара сөйләштеләр, киңәштеләр дә моны кызның эшләпәсен алырга җибәрмәк булдылар. Егет юлга чыгарга хәзерләнде. Ул юлга чыгып китәр алдыннан теге күгәрчен-егетләрнең берсе моңа тарак бирде:

– Менә мин сиңа бер хикмәтле тарак бирәм, ди. Алай-болай куркыныч туса, менә шушы таракны ике арага ташларсың: ташлау белән ике арада калын урман булыр, – ди.

Икенче күгәрчен-егет моңа бер кайрак китереп бирә:

– Андый-мондый хәтәр булса, менә шушы кайракны ташларсың: бик озын, бик биек бер тау булыр. Шул тау аркасында син бәла-казадан котылырсың, – ди.

Шуннан килеп, өченче егет моңа бер көзге китереп бирә:

– Куркыныч туса, шушы көзгене ике арага ыргытырсың, ди. Ике арада бик зур диңгез булыр. Шул диңгез аркасында син дошман бәласеннән котылырсың, – ди.

Егет, күгәрченнәр биргән әйберләрне алып, юлга чыгып китә. Чыгып китә дә кырда кош булып оча, суда балык булып йөзә, ут тауларыннан боз булып үтә, ди, бу. Юлда барганда бик күп авырлыкларга очрарга, бик күп җәфалар күрергә туры килә моңа. Бу, үз башына килгән төрле авырлыкларга түзеп, җиде кат тауны, җиде диңгезне үтә. Бара-бара, сигезенче диңгезгә барып җитә бу. Шул сигезенче диңгезнең нәкъ урта бер җирендә бик матур бер сарай салынган икән, ди. Бу сарай төрле ягыннан матур-матур бакчалар белән әйләндереп алынган. Бакчаларында төрле-төрле кошлар сайрап утыра икән, ди. Егет сарайга бик озак карап торганнан соң, моңа бер уй төшә: «Тукта әле, ди, бу патша сараеның тәрәзәсе янына барып сандугач булып сайрап карыйм әле мин, патша кызы сандугач тавышын ишетеп чыкмасмы икән», – ди.

Бу егет сандугач була да рәшәткә янындагы бер ботакка кунып сайрый башлый. Патша кызы, сандугач тавышын ишетеп, сарайдан чыга да моның сайравын бик кызыгып тыңлап тора. Сандугач шулкадәр моңлы итеп сайрый, моны һич еламыйча тыңларга мөмкин түгел. Кыз, түзә алмыйча, үксеп-үксеп елап җибәрә. Бу кыз үзе дә шулхәтле матур икән, кызны күреп, егет моңа бик нык ташыйк була, гашыйк була да, тагын да моңлырак, тагын да матуррак итеп сайрый башлый. Кыз моның сайраганын тыңлап тора-тора да, бу сандугачны тотып алмакчы булып, сиздермичә генә сандугачка таба килә башлый.

Ярар. Бу кыз шулай сандугач тавышына гашыйк булып, сандугачны тотып алу юлын эзли торсын, ә без бу сарайның хуҗасына килик.

Бу сарай бер дию пәриенең сарае икән. Бу дию пәрие бер патшаның менә шушы бердәнбер кызын урлап алып килеп, шушы диңгез утравы уртасындагы сарайда тота икән. Өч күгәрчен яныннан чыгып киткән егет монда килеп төшәр алдыннан гына бу дию пәрие, үзенең гаскәрләрен алып, икенче бер дию пәриенә каршы сугыш ачарга дип чыгып киткән икән. Сугышка китәргә хәзерләнеп гаскәрләрен туплагач, бу дию пәрие патша кызына әйтә:

– Без өч көндә кайтып җитәрбез, – ди. – Фәлән пәри патшасына каршы сугышырга барам. Син бу сарайда берүзең генә хуҗа

булып каласың, кара аны, анда-монда чыгып йөрисе булма, – ди, куркыта инде моны.

Теге егет бу сарай янына сандугач булып килгән вакытта кыз сарайда берүзе генә булган икән.

Ярар. Теге сандугач һаман сайрый бит инде, ә кыз моны тотарга тели. Кыз, акрын гына сандугач янына килеп, тотып алыйм дигәндә генә сандугач очып китә дә икенче бер ботакка барып куна. Шулай йөри-йөри тота алмагач, бу кыз бер озын гына чыбык ала да якынрак килеп сандугачка китерә дә суга. Сандугач агач ботагыннан егылып төшә, авызыннан, борыныннан кан китә моның. Кыз сандугачны кулына ала да:

– Харап иттем бит мин сине, – ди, – әле генә нинди матур итеп сайрый идең, хәзер сайрамассың инде, мин үзем гаепле, – ди.

Шуннан соң бу кыз елый-елый сандугачны сарайга алып кереп, йомшак кына урынга сала. Үзе елый-елый икенче бүлмәгә чыгып китә. Кызның чыгып китүе була, сандугач егеткә әверелә дә алырга килгән эшләпәне эзли башлый. Бүлмәдән бүлмәгә кереп сандыкларны ачып йөри торгач, кырык кат сандык эчендәге кырыгынчы тартманы ачкыч белән ачып, эшләпәне ала.

Егет сандыкларга тотыну белән, теге сугышка киткән дию пәрие моны сизеп ала. Тиз генә гаскәрләрен җыя да кайтырга чыга.

Ярар. Ул үзенең гаскәрләре белән кайта торсын, без хәзер теге егеткә килик.

Егет сандык эчендәге тартмадан эшләпәне алып чыгып килгәндә, каршысына патша кызы чыгып моның муенына асылына:

– Башка нәрсәне алсаң ал, зинһар, эшләпәне калдыр, – ди.

Кызның ай-ваена карамыйча, егет эшләпәне алып чыгып, кош булып очып китә. Кыз елап кала.

Озак та үтми, дию пәрие кайтып керә. Егетнең эшләпәне алып киткәнлеген шунда ук белә бу. Ничек-ничек булганлыгын кыз да сөйләп бирә. Дию пәрие тиз генә бөтен гаскәрен җыя да егетне куа чыгып китә.

Егет, дию пәриенең куачагын сизеп, ашыга башлый инде.

Күгәрченнәр өенә кайтып җитәргә өч кенә көнлек юл калды дигәндә, дию пәрие егет артыннан куып җитә яза бит, боларның аралары бик әз генә кала. Әлеге безнең егет, дию пәриенең куып җитүен сизеп, күгәрченнәрнең берсе биргән таракны ташлый. Таракны ташлавы була, ике арага калын урман калкып чыга. Дию

пәрие урманны үткәнче, егет шактый гына юл ала. Урманны үтү белән, дию пәрие егетне яңадан куып җитә. Егет күгәрченнәр биргән кайракны ташлый. Ташлавы була, ике арада бик озын тау-ташлык ясала. Дию пәрие бу тау-ташларны үткән арада, егет тагын байтак юл ала. Тау-ташларны үтү белән, дию пәрие тагын моны куып җитә. Дию пәриенең куып җитүеннән куркып, егет теге күгәрченнәр биргән көзгене ике арага ташлый. Ташлавы гына була, ике арада бик зур диңгез җәелә. Дию пәрие бу диңгезне бик тиз генә кичеп чыга да, тагын да катырак ачуланып, егетне җан-фәрман куып китә. Куа торгач, егет артыннан җитә бу. Инде тоттым дигәндә генә, егет бер авылга җитеп, шунда кереп китә. Авылга килеп керүгә, көянтә белән су алып кайта торган бер кызга очрый. Шул кыз янына бара да бу:

– Матур кыз, чиләгеңә генә кереп ятыймчы, – ди. – Мине, – ди, – бер дию пәрие куып җитеп килә. Дию пәрие синең яныңа килеп җитү белән, чиләгеңне түк, дип әйтер. Чиләгеңне түгәрсең, түккәч мин өч бөртек тары ярмасы булып чәчелермен, – ди, – син шул тары ярмасының бер бөртеген аягың белән басып яшереп кал, – ди.

Шулай ди дә бу егет кызның чиләгенә төшеп китә. Шул арада дию пәрие дә килеп җитә. Кыз янына килеп җитә дә:

– Суыңны түк хәзер, – ди дию пәрие.

Кыз суын түгеп җибәрә, егет өч бөртек тары булып чәчелеп китә. Дию пәрие шунда ук әтәч була да тары ярмасын чүпли башлый. Тары ярмасының ике бөртеген чүпләп бетерүгә, теге кыз аягын алып җибәрә, аның аяк астыннан тары бөртеге карчыга булып очып чыга да әтәчне ботарлый башлый. Карчыганың әтәчне ботарлавын дию пәриенең барлык гаскәрләре карап торды бит инде. Башлыкларының үтерелүен күрү белән, боларның кайсы кая качып беттеләр. Шуннан соң егет, үз кыяфәтенә кереп, теге судан кайтып килүче кызга кыйммәтле бүләкләр биреп, күп рәхмәтләр әйтеп, күгәрченнәр янына кайтып китте. Әлеге чибәр кыз моңа шаклар катып: «Өнемме бу, әллә төшемме?» – дип, ышаныр-ышанмас, исе китеп кала инде.

Егет күгәрченнәр янына эшләпәне алып кайтып керә. Күгәрченнәр бик шатланалар, бу егетне нишләтергә дә белмиләр инде. Шуннан болар, бик тиз генә җиденче амбарны ачып, теге патша кызын алып киләләр, эшләпәне киертәләр. Кыз шундый матур, шундый нурлы йөзле була, моңа сокланып карап туя алмыйлар.

Ярар. Хәзер болар дүрт егет, бер кыз – бишәүләп утырып ашадылар, эчтеләр, бик күңелле булды. Күгәрчен-егетләр үзара киңәшләшеп-сөйләшеп алдылар: «Бу егет безнең бик зур йомышыбызны үтәде, нинди бүләк белән генә бүләклик икән моны?» – диләр. Сөйләшеп-сөйләшеп бернинди дә киңәшкә килә алмадылар, теге егетнең үзеннән сорыйлар:

– Менә син безгә бик зур хезмәт күрсәттең, без өчәүләп эшли алмаган эшне син берүзең эшләдең. Моның өчен нәрсә белән риза-латыйк сине? – диделәр.

Егет әйтә:

– Мин нәрсә бирсәгез дә риза, – ди. – Мин үзем дә сездән бик күп белем алдым, миңа һөнәр әйбердән кыйммәтрәк, – ди.

Егетнең шулай дигәнен теге кыз тыңлап тора да егетне тышка алып чыгып китә. Тышка чыккач, бу кыз егеткә әйтә:

– Син аларның бик зур хезмәтләрен үтәдең. Минем арттан алар егерме өч ел буена йөрделәр, бер эш тә чыгара алмадылар, – ди. – Син ул эшне бер-ике атна эчендә үтәп кайттың, ди. Аларның бик ябык бер атлары, күгәреп беткән бер кылычлары, искереп беткән бер камчылары бар, – ди. – Хезмәтең өчен син алардан шул әйберләрне сора, – ди, – ул әйберләр сиңа бик кирәк булырлар, – ди, – алар ул әйберләрне берсүзсез сиңа бирерләр, – ди.

Егет:

– Ярар, сорармын, – ди.

Керәләр болар. Кыз: «Мин өйрәткәнне белдермә», – дип әйтеп куйган була егеткә. Болар кереп утыру белән, күгәрченнәр яңадан сүз башлап, егеттән сорыйлар:

– Шулай да нәрсә бирик икән соң без сиңа, ни хаҗәтең бар синең? – диләр.

Егет әйтә:

– Миңа, – ди, – ябык кына, начар гына булса да бер ат, күгәреп беткән булса да бер кылыч, иске генә булса да бер камчы бирсәгез бик ярар иде, – ди. – Начар булсалар да, мин шуларга риза, – ди, – бүтән нәрсә кирәкми миңа, – ди.

Күгәрченнәр бик риза булып, моның сораган әйберләрен сөенә-сөенә бирәләр:

– Безгә күп хезмәт иттең инде син. Хәзер өеңә кайтасыңмы, әллә безнең белән торасың киләме, кайсын теләсәң, шунсын эшлә, – диләр.

Егет әйтә:

– Юк, – ди, – мин өйгә кайтыйм инде, – ди. – Минем өйдә әтием-әнием бар, аларны бик сагындым. Аларның бүтән балалары юк, картайган көннәрендә аларны тәрбия итәргә кирәк бит, – ди.

Хәзер егетне юлга хәзерли башлыйлар, бик яхшы итеп киендерәләр, теге ябык кына атны, күгәреп беткән кылычны, камчыны бирәләр. Китәр алдыннан егет боларның барысы белән дә саубуллаша да, өйрәткән гыйлемнәре, биргән бүләкләре өчен бик күп рәхмәтләр әйтеп, теге ябык кына атка атлана. Егет атка атлангач кына, күгәрченнәр моны туктатып әйтәләр:

– Без сиңа бер киңәш бирәбез, – диләр, – син бервакытта да исергәнче эчмә, андый-мондый әшәке эшләр эшләп йөрмә, – диләр.

– Менә сиңа бер пычак, – ди күгәрчен-егетләрнең олысы, – атыңнан төшеп, шушы пычакны безнең түшәмгә кадап кит, син берәр төрле хәтәргә очрасаң, без шул пычакка карап белербез, – ди.

Егет, атыннан төшеп, болар биргән пычакны түшәмгә кадап куя. Шуннан соң атына атланып, боларның өйрәтүе буенча күзен йомып: «Мин өйдә булыйм», – дип, атының уң ягына сугып җибәрә. Сугып җибәрүе була, ат очып китә. Шуннан соң күп вакыт үтми, ат бераз селкенеп киткән кебек була. Егет күзен ачып җибәрсә, бу үзләренең өйләре янында тора икән. Атыннан төшеп, өенә кереп китә. Өйгә кереп, әтисе-әнисе белән елаша-елаша күрешә бу. Әтиәниләре бик сагынышканнар, картайганнар икән, ди.

Ярар. Бу егет берничә көннән соң үзенең ата-анасына әйтә:

– Сез дә картайгансыз икән, өй эшенә дә кеше кирәк, – ди, – әгәр дә сез рөхсәт итсәгез, мин өйләнер идем, – ди.

Егетнең әти-әниләре бик шатланып үзләренең ризалыкларын бирәләр. Егетнең әнисе әйтә:

– Без сине бик өйләндерер идек тә бит, улым, тик менә кем кызына яучы җибәрик икән, – ди, – безнең кебек ярлы кешегә бик бирәселәре килмәс шул, – ди.

Егет әйтә:

– Кайгырма, әни, – ди, – бер җае чыгар әле, – ди. – Мин сине үзем белмәгән җиргә җибәрмим, – ди, – әнә күрше шәһәрдәге фәлән патшаның кызын барып сорап кара әле, – ди, – бирмәсме икән? – ди.

– Әй, улым, – ди әнисе, – булмас эш артыннан йөреп юкка вакыт әрәм итмик без, – ди. – Безнең кебек фәкыйрь кешегә патша кызын бирәме соң?! – ди.

Егет әйтә:

– Син, әни, – ди, – барып сорап кара әле, – ди, – бирмәсә, анда күз күрер, – ди.

Улы бик үтенеп сорагач, карчык патша янына барырга була. Бер аягына чабата, икенчесенә итек киеп китә бу патша сараена. Барып җитә. Патшаның каравылчылары: «Бу карчык хәер сорашып йөри икән», – дип уйлап, бер телем икмәк чыгарып бирәләр.

– Мин хәер эстәмим, – ди, карчык әйтә, – минем патшада йомышым бар, – ди.

Патшага кереп әйтәләр:

– Шундый-шундый карчык килгән, сине күрергә тели, – дип.

Патша башын кашый да:

– Керсен алайса, – ди. Карчык барып керә сарайга.

– Ни йомышың бар, әби? – ди патша.

– Падишаһым-солтаным, – ди, – улым яңа гына читтә йөреп кайтты, – ди, – яше дә җиткән, өйләнергә тели, – ди. – Менә мине синең кызыңа яучы итеп җибәрде, синең кызыңны хатынлыкка сорый, – ди.

– Ярар, – ди патша, – кызымны бирәм, ди, тик менә мин, – ди, – берничә шарт куям, – ди. – Шул шартларны үтәсә, кыз сезнеке була, – ди.

– Соң син нәрсәләр эшләргә кушасың? – ди карчык.

Иң элек, – ди, патша әйтә, – үзенә бер сарай салдырсын, ул сарай минем сараемнан да яхшы булсын, – ди. – Шул сарайдан минем сараема хәтле су өстенә алтын күпер салдырган булсын, – ди. – Ул алтын күпердән машиналар йөреп торсын, – ди. – Алар барысы да алтын буяу белән буялган булсын. Күпер астында су булсын, суда пароходлар йөреп торсын, – ди. – Ул суның ике як ярында алмагачлар үсеп торсын, төрле-төрле җимешләре пешеп торсын, – ди. – Менә шушы эшләрне үти алса, ул минем кызымны алыр, үти алмаса, үпкәләштән булмас, мин аның башын кистерермен, – ди.

Патшаның бу сүзләрен ишетү белән, карчыкның башыннан зиһеннәре таралып китә, бик зур кайгыга төшеп, өенә кайтып китә. Кайтып керү белән, улына әйтә:

– Менә, улым, – ди, – патша әйтә, шундый-шундый эшләрне эшли алса гына, мин аңа кызымны бирермен, – ди, – ә инде эшли алмасаң, башыңны кистерергә уйлый ул, – ди. – Патшадан яхшылык көтмә, ул усаллыкның барысын да эшләр, – ди. – Харап булып

куймагаең инде, дип куркам, улым, – ди карчык. – Бик зур эшләр кушты бит, кая инде безгә ул эшләрне эшләү, – ди.

Егет әйтә:

– Ярар, әни, юкка кайгырма әле син, – ди. – Ул эшләрне генә эшләрбез, бар да ул дигәнчә булыр, – ди.

Төн урталары җитеп, бөтен кеше йокыга китү белән, бу егет күгәрченнәрдән алып кайткан камчысын алып чыгып, бер генә селтәп җибәрә. Селтәп җибәрүе була, җир йөзендәге пәриләрнең ни бары моның каршысына килеп басып:

– Ни боерасың? – дип сорыйлар моннан.

Егет әйтә:

– Таң атканчы патша сараеннан да яхшырак итеп миңа бер сарай салыгыз, – ди. – Патша сарае белән безнең сарай арасында алтын күпер булсын, – ди. – Аның өстеннән алтын буяулар белән буятылган машиналар йөреп торсын, – ди. – Күпер астыннан зур-зур пароходлар үтеп торсын, елганың ике ярында алмагачлар үсеп торсын, алмалары пешеп торсын, – ди. Дию пәриләре:

– Ярар, була ул, – дип калалар.

Хәзер дию пәриләре тотыналар да егет әйткәннәрне ике сәгать эчендә эшләп ташлыйлар, патша кушканнан да берничә өлеш яхшырак итеп эшлиләр, ди.

Патша иртә белән торып чыкса, ни күзе белән күрсен: моның сараена каршы якта бик матур итеп бер сарай салынган. Ике сарай арасында ялт иткән зур күпер төзелгән, күпер өстеннән машиналар ялт-йолт итеп кенә узып торалар.

Патшаның шул вакытта кылт итеп исенә төшә: «Их, – ди, – егеткә әйтүен әйттем дә, – ди, – ну минем кызым өйдә юк бит әле», – ди.

Иртә белән сәгать сигез тулды дигәндә, егет, алтын машинага утырып, алтын күпер аркылы чыгып, патша сарае янына килеп туктый. Шушындый әйбәт машина белән килгәч, каравылчылар да туктатмый, туп-туры патшаның ишегалдына ук кереп китә бу. Килеп керү белән, патша янына барып, үзенең ни өчен килгәнен сөйләп бирә. Патша нәрсә дә әйтергә дә белмичә аптырап кала.

– Егет, – ди, – сүз бирүен бирдем мин, ди, тик менә моннан бер ай гына элек урамга чыккан җиреннән урлап киттеләр бит минем кызымны, – ди. – Кем урлаганын да белмим, – ди.

– Ярар, – ди егет, – алай булгач мин аны эзләргә чыгыйм, үзем табып алып кайтырмын, – ди.

– Мин аны эзләргә дип бер дигән батырларымны җибәргән идем, – ди, – бер айдан артык эзлиләр, әле һаман таба алмыйлар, күрәсең, – ди.

– Ярар, – ди егет, – синең батырларың булдырмаганны мин берүзем генә эзләп карыйм әле, – ди.

Егет, өенә кайтып, әти-әнисеннән рөхсәт ала да, алар белән саубуллашып, теге ябык кына атына атланып чыгып китә кызны эзләргә.

Барып җитә бу теге күгәрченнәр янындагы шәһәргә. Килеп җитү белән, атын шунда калдырып, үзе күгәрчен булып, өч күгәрчен янына очып барып керә. Теге өч егеткә хәл-әхвәлне сөйләп бирә:

– Менә шундый-шундый хәл, – ди, – мин кыз эзләп йөрим, – ди.

Күгәрченнәр янындагы кыз әйтә:

– Мин ул кызны беләм, – ди. – Ул кыз, – ди, – моннан барганда сигезенче диңгез уртасындагы утрауда торучы дию кулындагы кыз, – ди. – Минем эшләпәмне шул дию кулыннан алып кайттың бит син, – ди.

Шулай дигәч, егетнең исенә кылт итеп теге кыз килеп төшә.

Күз ачып йомганчы бу егет кош булып әверелә дә теге дию пәриенең сараена очып китә. Барып җитә. Барып җиту белән, үз кыяфәтенә кайтып, сарайга барып керсә, кыз елап утыра икән, ди. Егетне күрүгә кыз:

– Каян гына килеп чыктың соң син? – дип муенына асылына, – ди.

Егет әйтә:

– Мин сине эзләп килдем, – ди.

Болар исәнлек-саулык сорашып, бер-берсенең хәлләрен белешәләр дә юлга чыгарга хәзерләнәләр. Күгәрченнәрдән өйрәнгән белеме буенча, егет кызны да, үзен дә кош итә дә икәү очып чыгып китәләр юлга. Баралар-баралар да, бераз гына хәл алырга дип, диңгез буендагы бер шәһәр янына туктыйлар болар. Егет кыздан сорый:

– Сусамадыңмы, су эчәсең килмиме? – ди. Кыз әйтә:

– Минем, – ди, – эчәсем дә, ашыйсым да килми, тизрәк әти-әниләрем янына кайтып җитәсем килә, – ди.

Шуннан соң егет кызны диңгез буенда калдырып:

– Мин берәр тустаган гына сыра эчеп чыгыйм, – дип, шәһәр читендәге бер йортка кереп китә.

Барып керә. Башта бу бер тустаган эчә. Тора-бара, шундагы кешеләр белән сүзгә керешеп китеп, күбрәк эчеп ташлый бу. Теге күгәрченнәрнең «эчеп-исереп, әшәкеләнеп йөрмә», дигән киңәшләрен онытты инде бу.

Бераздан исереп килеп чыга. Кыз янына бара. Кызның моңа бик каты ачуы килә: «Ай, ялгышканмын икән ләбаса, эчкече егет икән бу», – ди. Шуннан соң кыз моның белән юлга чыгып китәргә куркып:

– Син бераз гына ятып ял итеп ал, – дип, моңа йоклап алырга киңәш бирә.

Егет исерек булгач, яту белән, бик каты йокыга китә. Егетнең йокыга китүе була, диңгез яры буена бик зур пароход килеп туктый. Пароход эче гаскәр белән тулы. Пароход килеп туктау белән, пароходтан ике батыр яр буена чыгып йөриләр, кызны күреп, кыз янына киләләр дә сорыйлар:

– Син монда нишләп утырасың? – диләр. Кыз әйтә:

– Мин, – ди, – үземнең иптәшемне саклап утырам, – ди, – ул ял итә әле, – ди.

Шуннан соң батырларның берсе кызга карап-карап тора да үзенең кесәсеннән бер рәсем чыгара. Бер кызга карый, бер рәсемгә карый, ди, бу. Бераз карап торганнан соң, бу батыр сорый теге кыздан:

– Син кем буласың, кем кызы соң син? – ди.

– Мин фәлән-фәлән патша кызы, – ди.

Батыр бу кызның шул үзләре эзләп йөри торган патша кызы икәнен белде. Шуннан соң теге батыр әйтә:

– Без сине ай ярым эзләп йөрибез инде, менә хәзер генә таптык, сине әтиең янына алып кайтабыз, – ди.

– Мине, – ди кыз, – сез тапмадыгыз бит, менә бу батыр егет эзләп тапты, – ди. – Егет бераз ял итсен әле, мин аннан башка беркая да бармыйм, – ди кыз бик батыр гына.

Кыз шул арада сизенеп: «Алай-болай була калса, истәлек булып калсын», – дип, үз бармагындагы йөзеген алып егеткә киертеп куя.

Тегеләр кызны алып китәргә азапланалар. Кыз китәргә риза булмагач, аны утырган җиреннән тартып торгызалар да көчләп пароходка алып кереп китәләр. Шуннан соң теге исереп йоклап яткан егетне кискәләп, тураклап ташлыйлар. Үзен коткарган егетнең шулай булуын күреп, кыз бик каты елый, кайгыра. Берүзе нишләсен инде, ул арада пароход кузгалып та китә.

Хәзер күгәрченнәргә килик. Көннәрдән бер көнне күрәләр: теге егет түшәмгә кадап киткән пычак бер идәнгә, бер түшәмгә кадала. Пычакны күреп, күгәрченнәр: «Безнең егет нинди дә булса берәр бәхетсезлеккә очрагандыр ахры», – дип, егетне эзләргә чыгып китәләр. Эзләп йөри торгач, теге диңгез кырыена барып чыгалар. Шунда егетнең туракланып ташланган кисәкләрен табып, бу өч күгәрчен үзләренең һөнәрләре белән тегене яңадан терелтәләр. Теге егет тәмам терелгәч, күгәрченнәр:

– Әйттек без сиңа: эчеп-исереп, әшәкеләнеп йөрмә, дип. Яхшы киңәшне тотмагач, менә шулай була ул, ярый әле без белдек, без коткардык, – диләр.

Бу бик ояла, хурлана инде. Күгәрченнәргә:

– Моннан соң болай эшләмәм, – дип сүз бирә, рәхмәтләр укый.

Күгәрченнәр моңа кайтыр юлларын өйрәтәләр. Егет өенә кайтып китә.

Өенә кайтып керә, ата-аналары белән күрешеп, хәл-әхвәлләрен белешкәч, әнисеннән теге патша кызы турында сораша башлый. Әнисе әйтә:

– Әй, улым, – ди, – безгә бирәләрме соң алар кызларын, – ди.– Без сораган кызны патшаның бер зур батыры коткарып алып кайткан икән, кызны шуңа бирәләр, бүген туйлары була, – ди.

Егетнең моңа бик каты эче пошып, чыгып китә теге патша йортына. Патша сараена җиткәнгә хәтле кош булып очып бара егет. Барып җиткәч, элекке хәленә кайтып, сарайга керим дип барса, патшаның кушуы буенча сарай төрле яктан биек коймалар белән әйләндереп алынган булган икән. Бер генә урында кечкенә бер капка калдырылган икән, ди. Сарайга керергә теләгән кеше шул капка эченнән үтәргә тиеш икән. Патша кызы капка янына кечкенә бер йорт салдырган. Үзе шул йорт эченә кереп утырып, шәһәргә керүче һәрбер кешегә бер стакан су эчереп җибәрә икән.

Ярар. Егет сарай тирәсендә йөри торгач, шушы кечкенә генә капканы килеп таба. Капкадан килеп керә. Килеп керү белән теге кечкенә йортның тәрәзәсеннән моңа да бер стакан су бирәләр. Патша кызы кергән бер кешене бик җентекләп карап тора бит инде. Егет килеп кереп стаканны алуга, патша кызы моны төсмерләп алып, әйтә моңа:

– Егет, – ди, – кулың нишләде, бармагыңны нигә бәйләп куйдың? – ди.

– Пычак белән кискән идем, бик каты канаганга бәйләп куйдым, – ди егет.

– Начар чүпрәк белән бәйләгәнсең икән, үзем яхшылап бәйлим әле, – ди.

Егетнең бармагын күрсәтәсе килми, патша кызы бик каты инәлеп сорагач кына, риза була бу. Патша кызы моның бармагын чишеп җибәрсә, ни күзе белән күрсен: егет кулында үзе биргән балдак ялт итеп тора. Кыз, балдакны күрүгә, егетнең муенына асылына:

– Харап иткәннәр иде бит сине. Шулай да мин синең яңадан терелэсеңә ышандым, менә шуңарга көтеп алдым, – ди.

Шулай ди дә егетне үзенең атасы янына алып кереп китә. Кыз атасына әйтә:

– Минем кадерле әтием, – ди, – мине коткарган кеше теге батыр түгел, менә шушы егет, – ди. – Миңа ышанмасаң, аның кулындагы балдакны кара, – ди. – Мине коткарган өчен, мин аңа үзем бүләк итеп киткән балдак ул, – ди.

Патшаның теге алдакчы батырга бик каты ачуы килде. Ялганлап йөрүе өчен патша аны терелэй тунарга хөкем итте.

Патша, кызын бу егеткә биреп, кырык көн туен итте, илле көн уен итте, ди. Туй үтү белән, егет кызны үз өенә алып кайтып, әти-әниләре белән бик күңелле итеп көн итә, шуның белән әкият тә бетә.

Бүген бардым, кичә кайттым, бик ямансыладылар.

Мәмәшир авылында<br>Шәфигулла Сәмигуллиннан (43 яшь)<br>Х. Ярми язып алган. 1951

## Алдакчы Тимер

Борын заманда Тимер исемле алдакчы кеше булган. Аның алдакчы икәнлеге янәшә-тирәгә җәелгән. Аннан бик күп байлар курыкканнар. Ул байларны теләсә ничек мыскыллаган. Көннәрдән беркөнне байлар җыелып Тимер өстеннән патшага жалоба язганнар. Патша, жалобаны алгач, чиктән тыш котырынып:

– Мин ул алдакчының башын тиз кисәрмен, – дигән, Тимердән курыккан байларны суганлап-борычлап сүгеп. – Тимерне тотмыйча өйгә кайтып кермәгез! – дип, вәзирләрен чыгарып җибәргән.

Вәзирләр Тимерне бик күп шәһәрләрдән эзләп, таба алмыйча кайтканнар. Патша моның белән генә тынычланып калмаган.

Үзенең батырлыгын байларына күрсәтәсе килеп, ничек тә Тимерне табып, аңар башкара алмаслык эшләр кушып, үти алмаса, аның башын кистермәкче булган. Тимерне эзләп табу өчен, тагын вәзирләрен чыгарып җибәргән.

Вәзирләр, эзли торгач, кечкенә генә бер шәһәрдә Тимерне очратып, аңар эшнең ничек икәнен сөйләп биргәннәр. Тимер аларның сүзләренә каршы килми, түбәнчелек белән башын иеп:

– Патша хәзрәтләренә каршы килеп булмас, – дип, – вәзирләр белән бергә патша сараена киткән.

Патша, вәзирләре белән бергә кайтучы ят кешене күреп, чамадан тыш куанган: «Моңа кадәр беркем дә тота алмаган алдакчыны тотып, башын кистереп, үземнең кем икәнемне бөтен дөньяга белдерим әле», – дип, бик түбәнчелек белән Тимерне каршы алган. Патша Тимерне табу шатлыгыннан вәзирләренә өч көн беркая да чыкмый ял итәргә кушкан. Тимерне үз бүлмәсенә алып кереп, аның тамагын бик яхшылап туйдырган. Аннан соң патша, үзен эре генә тотып, Тимергә йөкләмәләр бирә башлаган. Патша:

– Тимер, син бик күп байларның әйберләрен алдап алып ярлыларга тараткансың, ләкин бер дә эләкмәгәнсең. Менә мин сиңа бер эш кушам, шуны үти алмасаң, башыңны кистерәм, – дигән.

– Нәрсә кушсагыз да сезнең эшегезгә каршы түгел, – дигән Тимер.

– Менә минем бер үгезем бар, ул унике ишекле абзарга бикләнгән, ишекнең һәрберсендә берәр каравылчы тора, һәр ишекне бикләп, ачкычларын үзләренә алганнар. Каравылчы солдатлар да белмәсен – үгезне урлап чык! – дигән патша.

– Моны уйлап та тормыйм мин, – дип, Тимер, патша яныннан чыгып китеп, шәһәр читендәге бер ярлы карчыктан үзенә квартир алган.

Анда кереп ашап-эчкәннең соңында, үзенең киемнәрен салып, әбинең киемнәрен киеп, карчык кыяфәтенә кереп, кулына буш чиләк белән чүмеч тотып, өйдән чыгып киткән. Бер кибеткә кереп, тәмледән дә тәмле, тиз исертә торган бер чиләк аракы алып, караңгы төшкәч, патша сараена таба киткән. Патша капкасы төбендәге каравылчы солдат янына барып, бернәрсәгә исе китмәгән төсле яулык почмагы белән күзләрен серткәләп, солдатка карап тора башлаган. Каравылчы солдат аннан:

– Әби, нәрсәгә бик аптырап карап торасың? – дип сораган.

Аңар каршы Тимер:

– Минем дә синең шикелле улым бар иде, ул да солдат хезмәтенә китте. Сезнең шикелле гомер буе беркая китми, аяк өстендә тора торгандыр дип, улымны жәлләп куйдым. Сез бичараларга да читен инде, – дигән.

– Яхшы түгел, әби. Чиләк тотып кая барасың? – дигән солдат.

– Беркая да бармыйм, улым, ярлы кешене беләсең бит инде, әз булса да табыш булыр, файда итәрмен дип, сыра ясаган идем, аны да сата алмадым. Иртәгә ашарыма да юк, нишләсе булыр, – дип, Тимер эчтән сулап куйган.

Солдат, кесәсеннән ике тиен акча алып:

– Әби, читенсенмәсәң, ике тиенлек кенә сыра бир әле, – дигән.

– Акчаң кирәк түгел, улым, акчаңа шырпы булса да алырсың. Ач булсам да, мин синең шикелле тоткында түгел. Улым өчен булыр, мә, эч! – дип, Тимер бер чүмеч аракыны солдатка биргән.

Солдат аракыны йотлыга-йотлыга эчеп бетергән. Тимер, солдатның кызасын белеп, аның янына якынрак килеп сөйләштерә, башлаган. Солдат кыза төшеп:

– Әби, оят булса да, тагын бер чүмеч бир әле, – дигән.

Тимер, солдатка тагын бер чүмеч аракы салып биреп, койма буена куелган эскәмиягә барып утырган. Солдатның кызуы җиткән, үзенең кайгысын уртаклашу өчен, Тимер янына утырып, үз хезмәтенең авырлыгы турында сөйләп:

– Әби, андый-мондый кеше килсә: «Минем улым», – диярсең, – дип, Тимерне өйрәтеп тә куйган.

Шул вакытта эчтән:

– Сез кем белән сөйләшәсез анда? – дигән тавыш ишетелгән. Тимер, куркынган булып, утырган урыныннан торып китә башлаган. Солдат:

– Курыкма, әби, курыкма, үземнең иптәш ул, үгез каравыллый, – дип, Тимерне эскәмиягә утырырга кушып, әкрен генә: – Якташ, якташ, чык әле монда, әни күчтәнәчләр алып килгән! – дип, иптәшен чакыра башлаган.

Капка эченнән чыгып, солдатның иптәше дә Тимернең аракысы белән сыйланган.

Башта эчкән солдат яхшы ук кызып:

– Мин сиңа акча түләрмен, – дип, Тимергә күзен кысып:

– Әни, монда кеше күрер, әйдә эчкә керәбез! Сыраң белән минем иптәшләремне дә сыйларсың! – дип, Тимерне эчкә алып кереп киткән.

Тимер:

– Куркам, улым, патша белер, – дип куркынган булып эчкә кергән.

Каравылчы солдатлар аңар:

– Курыкма, курыкма, патшалар йөри торган юл түгел бу. Монда бездән башка эт тә булмас, – дигәннәр.

Шулай итеп, Тимер, унике солдатны да исертеп: «Бераз йөрәк керсен», – дип, калган аракысын үзе эчеп, кайсы кайда, кайсы кайда ятучы солдатларның кесәләреннән ачкычларын алып, үгезне абзардан алып чыгып, квартирына кайтып киткән. Тимер, квартирына кайтып кергәч, үгезне суеп, итен пешерергә дә биргән. Ул үгезнең тиресен, бер чиләк канын җыеп куеп, тәмләп кенә ит ашап йокларга яткан.

Ә инде патшага килсәк, ул төннәр буенча Тимерне уйлап әле бер якка, әле икенче якка әйләнеп яткан-яткан да таң алдыннан гына йокыга киткән. Патша, ашамый-эчми, иртәгесен үгезен карарга чыгып киткән. Ул чыкканда унике солдат та үз урыннарында постта булганнар. Патша ачуланмасын дип, борыннарыннан гына тын алып торганнар. Патша абзарны ачып караса, җилләр искән. Патша каравылчыларны кыздырырга тотынган. Ачуына чыдаша алмый кызарынып-бүртенеп:

– Нигә йокладыгыз? Тимерне нигә тотмадыгыз? – дип акырган.

Һәрбер солдат:

– Без бернәрсә дә белмибез, йокламадык та, – дип җавап биргәннәр. Эчеп егылганнарын әйтсәләр, патшадан курыкканнар.

Патша, үгезен алып кайту өчен, Тимергә вәзирләрен җибәргән. Тимер вәзирләргә:

– Урлаган әйберне кешегә бирмиләр, мин аны патша өчен дип урламадым. Мин аның итен сатып бетердем инде, – дип җавап биргән.

Тимернең һәрбер сүзен вәзирләр, түкми-чәчми, патшага сөйләп биргәннәр. Патша, ачуыннан күркә шикелле кабарып: «Мин аның һичшиксез башын кисәргә тиеш, – дип, өч көн, өч төн бер дә йокламый уйлый торгач, Тимергә үтәү өчен бер эш табып, артык шатланып: – Менә монысыннан котыла алмас, башын тиз кисәрмен», – дип куйган.

Патша Тимерне үз янына чакыртып, ачу белән:

– Яхшы, син үзеңнең патшаңнан көләргә телисеңмени әле? Үгезне дә суйгансың, минем кулдан тиз генә котыла алмассың. Сиңа тагын бер эш бирәм, үти алмасаң, башыңны кистерәм, – дигән.

Тимер:

– Патша хәзрәтләренең сүзенә бервакытта да каршы түгел. Әйтегез! – дигән.

– Минем унсигез солдатым бар, шуларның өстендәге киемнәрен урла, үзләре дә белмәсен, көндез дә булсын! – дигән патша.

– Җиренә җиткерербез, – дип, Тимер үзенең квартирына кайтып киткән.

Патша аның артыннан:

– Менә бу юлы котыла алмассың. Солдатларга да ныклап әйтеп куярмын, – дип калган.

Тимер төнге сәгать уникегә кадәр йоклап, ашаган-эчкәннең соңында, үгез тиресен алып, патшаның көн дә чыгып иркен ача торган бакчасына киткән. Бакча бик шәп эшләнгән булган, һәр ягы су белән чолганып алынган. Читтән караганда бакча диңгез эчендәге утрау төсле булган. Тимер, үгез тиресен күтәргән килеш, су буена килгән дә каек белән бакча эченә кереп киткән. Бакчага керә торган күперне саклап торучы солдат Тимерне күрми дә калган. Тимер, балтасы белән бакчадан дүрт казык кисеп алып, дүртесен дә күл эченә кертеп, дүрт җиргә каккан. Аннан соң үгез тиресен алып кергән дә, дүрт аягын ныклап казыкка бәйләп, башын үгезнеке шикелле күтәртеп бәйләп куйган. Тире читтән карап торучыга сырты гына күренеп тора торган үгездән аерып алырлык булмаган. Тимер эшен бетерүгә, ятып да башлаган, йоклап торуны кирәк тапмаган, бер агач төбенә яшеренеп, үгезне күзәтергә тотынган. Гадәтләре буенча, патша солдатлары сәгать сигез тулгач бакчага иркен ачарга килгәннәр. Тиле-вәлерәк бер солдат як-ягына каранып бара торгач, су өстендәге үгезне күреп, иптәшләренә:

– Иптәшләр, иптәшләр, патша безне юкка гына тиргәгән. Әнә патшаның үгезе суга кереп баткан! – дип кычкырган.

Солдатлар шатлыкларыннан нишләргә дә белмәгәннәр. Үгезне алып чыгу өчен, бер солдатны чишендереп суга кертеп җибәргәннәр. Теге солдат үгез янына кереп, мөгезеннән тотып тартырга тотынган. Үгез аның тартуын бар дип тә белмәгән. Солдат, үгезне тарта-тарта хәлдән тайгач, кулларын бутап иптәшләренә:

– Нәрсә карап торасыз анда? Керегез монда, барыбыз бергә чыгара алырбызмы-юкмы, аякларын бик каты терәгән – кузгатып та булмый. Кергәндә берәр тал чыбыгы да алып керегез, сыртын кашымый чыкмас! – дип кычкырган.

Калган унҗиде солдат та өсләрендәге киемнәрен салып, һәркайсы кулларына тал чыбыклары алып, үгезне алып чыгарга суга кереп киткәннәр.

Тимер, качкан урыныннан чыгып, солдатларның киемнәрен җыеп алган да квартирына кайтып киткән.

Солдатлар, бернәрсә булмаган шикелле, чыбык белән үгезнең сыртын кашырга тотынганнар. Үгез аларның кыйнаганнарын исенә дә алмый, күзен бер ноктага терәп торган. Үгезне чиратлашып та кыйнап карадылар, чыкмагач, унсигезе дә үгезне мөгезеннән тотып тартырга тотынганнар. Нык тарта торгач, каккан казыклар чыдамый, үгез тиресе «поштыр» итеп килеп чыккан. Солдатлар:

– Тиресе йолкынгач, үгезне алып кайтсаң да үләр, патшадан кыен гына алырбыз, – дип, үгезнең тиресен суга батырганнар да су кырыена чыгып ял итәргә утырганнар.

Төрлесе төрлечә мактанырга тотынган:

– Мин ныграк тарткан идем, үгезнең тиресен салдырдым, – диешкәннәр.

Ял иткәннең соңында киемнәрен кияргә барсалар, җилләр искән. Бакча эченнән эзләмәгән җирне калдырмаганнар, ләкин киемнәрен таба алмаганнар. Шәрә тән килеш патша янына кайтып киткәннәр. Патша, солдатларын күреп, сүзен әйтә алмый катып калган. Бераз аңына килгәч, солдатларын үз янына чакырып, йомшак сүз белән генә, ничек булганын ачык беләсе килеп, сораштыра башлаган. Солдатлар Тимернең ничек алдаганын белсәләр дә, үзләренең булдыксызлыкларын белдерәселәре килми:

– Бара торган килеш киемнәр өстән юкка чыкты, – дип җавап биргәннәр.

Патшаның ачуы чиктән тыш арткан. Тимерне үз янына чакырып:

– Мин сиңа актык эшемне кушам, шуны да үти алсаң, ярты байлыгымны бирәм, – дигән.

– Сезнең һәр эшегезне дә үтәргә каршы түгел, әйтегез! – дигән Тимер.

Башта уйланып куелган булганга, патша аптырап тормаган:

– Иртә белән үземнең яннан хатынымны урлап кит! – дигән.

– Тулысы белән үтәлер эшегез, – дип, Тимер кайтып киткән.

Квартирына кайтып, кичәге шикелле сәгать уникегә кадәр йоклап, җыеп куйган җиреннән бер чиләк үгез канын алып,

патша бакчасына киткән. Бакчага кергәндә аны беркем дә күрмәгән. Тимер түземсезлек белән көтә торгач, таң атып, кояш та чыккан. Патша солдатлары, гадәтләре буенча, бакчада иркен ачып кайтып киткәннәр, һәр көнне патша белән хатыны солдатлардан соң ат белән шул ук бакчага иркен ачарга киләләр икән. Бүген дә матур көр атка җигелгән лисорлы тарантаска утырып, патшаның килгәнен күреп, Тимер, өстендәге барлык киемнәрен салып ташлап, баштанаяк үгез каны белән буялган. Аннан соң патшалар килә торган юл буендагы кәкре имән янына барып, башын түбән, аякларын югары куеп асылынган. Патша Тимер янына килеп җиткәч аптырап калган. Ул, мыскыллы көлемсерәп:

– Хатын, бу Тимер түгелме соң? – дигән.

Аңар каршы хатыны ышаныч белән:

– Тимер, атасы, Тимер, – дип җавап биргән.

Үзенең малын кызганган патша:

– Вәт, хатын, бездән башка да Тимерне үтерүчеләр бар икән, рәхмәт төшкереләре. Бу эшне үтәп чыкса, ярты патшалыгымны ала иде бит. Вәзирләргә әйтербез дә шакшының гәүдәсен моннан алып, бөтен халык алдында мәсхәрәләп күмәрбез. Минем дә халык алдында дәрәҗәм күтәрелер, – дип, үз юлларына киткәннәр.

Алар киткәч, Тимер агачка асылынган җиреннән төшеп, бакча эченнән алар каршысына чыгып, баягыча асылынып тора башлаган. Тимер янына килеп җиткәч, патшаның күзе шардай булган.

– Хатын, хатын, әллә Тимер ике микән? Тегесе кәкре имәндә иде бит. Хатын, син Тимер янында ат белән торып тор, мин тегесен карап килим, чыннан да ике микән әллә? – дип, тарантасыннан төшеп килгән юлыннан кире йөгергән.

Патша киткәч, Тимер агачтан төшеп, патша хатыны янына утырып, шатырдап чабып квартирына кайтып киткән. Тимер, квартирына кайткач, ашык-пошык юынган да, патша хатынын ышанычлырак квартирга яшерү өчен чыгып киткән. Тимер, үзен сорап килсәләр, квартир хуҗасына дөресен әйтергә кушмаган:

– Мине сорап килсәләр: «Патша хатыны белән мунчага китте», – диярсең! – дигән.

Озак та тормаганнар, патшаның вәзирләре Тимернең квартирына килеп:

– Тимер кая китте? – дип сораганнар.

Әби аларга:

– Тимер әле генә патша хатыны белән мунчага китте, борчып йөри күрмәгез тагын, үзе кайтканчы көтеп торыгыз, – дип җавап биргән.

Мондый хәл буласын көтмәгән вәзирләр, патшага кайтып, эшнең нәрсәдә икәнен сөйләп биргәннәр. Патшаның вәзирләре киткәч, Тимер аптырап калмаган, хатынын сорап патша үзе киләсен белеп, үз квартиры тирәсенә барлык ярлы халыкны җыеп, патшаны көтеп тора башлаган. Озак та тормаган, иллеләп кораллы солдат белән Тимер квартирына патша килеп, солдатларына:

– Бу ярлы-ябагайларны камчылап, Тимерне кулга алып, хатынны Тимер кулыннан коткарырга! – дип чәчәләнеп, гайрәт белән кычкырган.

Тимер үз ниятен алдан ук аңлатып куйганга, ярлылар үзләрен батыр тотканнар. Моны күреп, патшаның күзен кан баскан.

– Хәзер үк Тимерне богаулап алыгыз! – дип кычкырган. Шул вакытта ук Тимерне богаулап алганнар. Тимернең квартирын астын өскә китереп тикшерсәләр дә, патша хатынын тапмаганнар. Патша Тимергә ачу белән:

– Хатынны кая куйдың? – дип кычкырган.

– Мин синең хатынны бирмәскә уйлаганым да юк, – дигән Тимер. – Миңа тиешле малыңны бир дә хатыныңны алырсың. Бу мәсхәрәләвең хакында киләчәктә үзебез сөйләшербез, – дип, Тимер патшага карап көлеп куйган.

Патша, Тимерне куркытырга теләп:

– Хатынның кая икәнен әйтмәсә, хәзер үк асыгыз! – дигән.

– Син мине астырып хатыныңны минем кулдан ала алмассың. Миңа тиешле бурычыңны түлә дә ал! – дип, ярлыларга күзен кысып: – Патша безгә тиешле акчаны түләмәсә, хәзер үк патшаның хатынын үтерегез! – дип кычкырган Тимер ярлыларга.

Ярлылар:

– Ярар, – дип шаулашып куйганнар.

Моны күргәч, патшаның тез буыннарына кадәр калтырап киткән. Патшаның хатыны ифрат матур булган. Малын Тимергә бирмәсә – хатынын ярлылар үтерәчәкләр, малын бирсә – малын жәлли. Уйлап торган да бер вәзирен янына чакырып:

– Ярты байлыгыма чамалап, Тимергә тиешле акчаны алып кил! – дип, аны кайтарып җибәргән.

Патша, асат кына Тимердән хатынын алып, үзен астырырга теләсә дә, булдыра алмаган. Тимергә тиешле булган акчаны түләп, хатынын алып киткән. Тимер, патшадан алган барлык малларны ярлыларга таратып, ярлыларны куандырган.

Байлангар авылыннан Миңлемулла Кәримуллин
язып җибәргән. 1939

**Кол һәм алпавыт**

Элекке заманда кешеләрне бик кызык кына хөкем иткәннәр, ди. Бер кеше кечкенә генә ялгышлык эшли икән – аны судка биргәннәр. Гаебе зурмы, кечкенәме, аны тикшереп тормаганнар. Бүреккә «үтерергә», «коткарырга» дип ике кәгазь язып салып, гаепле кешегә шуның берсен алырга кушканнар.

– Менә бу кеше крестьяннарны миңа каршы баш күтәрергә котырта, – дип, алпавыт үз крестьянын судка биргән.

Сүз берләшеп куйганлыктан, судьялар ике кәгазьгә дә «үтерергә» дип язып салганнар.

Теге кешенең иптәшләре сизеп, моңа:

– Бүректә икесе дә «үтерергә» дигән кәгазь, – диләр. Бу аларның сүзенә әһәмият бирмәгәндәй була.

– Әфәнделәр! – дигән ул судьяларга. – Соңгы минутымда булса да, алпавыт минем теләгемне үтәсен. Моннан соң ул үзенең колларын азат итсен, ә миңа җир бүлеп бирергә кушып, законга туры китереп, сездән язу алып бирсен. Шулай итсә, мин тынычлап үләр идем, – дигән.

– Барыбер үләсе кеше бит, ул үлгәч, аның өчен кем җир сорап йөрер, – дип, теге кеше сораганча язу язып биргәннәр.

Теге кеше язуны кесәсенә салып куйган да, бүректәге бер кәгазьне алып, авызына кабып йотып та җибәргән. Бу хәлдән алпавыт та, судьялар да аптырап калганнар. Аның эчен ярып, кайсы кәгазьне алганын карап булмый бит, бүректә калган кәгазьне карарга мәҗбүр булганнар. Билгеле инде бүректә «үтерергә» дигән язу калган булган. Судьялар каушауларыннан нишләргә белми:

– Син «коткарырга» дигән язулысын алгансың, – дип, теге кешене азат иткәннәр.

Шулай итеп, теге кеше үзе дә котылган, крестьяннарны да җирле иткән.

Миңлемулла Кәримуллин Каенсар авылыннан
язып алып җибәргән. 1940

## Ярлы белән мулла

Бер авылда бер ярлының эшкә уңган бик матур кызы булган. Карт мулла бу кызга кызыгып йөри икән. Кызын сорап мулла ярлы кешегә әллә ничә тапкыр яучы җибәреп тә, күп акчалар ышандырып та караган. Ярлы агай:

– Китапта кешене түгел, этне дә сату зур гөнаһ, дигәннәр. Кызымны көчләп карт муллага бирә алмыйм, үзе кемне тели, шуңа барсын, – ди икән.

Мулланың моңа бик яман ачуы чыккан.

– Яхшылык белән бирмәсәң, усаллык белән алырга да күп сорамам, – дигән бу.

Бер көнне мулла авылдагы юан корсакларны җыеп аш мәҗлесе үткәргән. Матур кызны кулга төшереп булмасмы дип, теге ярлыны да мәҗлескә чакырган. Ярый, агай кыстатып тормаган, килгән. Мәҗлестәгеләр моны:

– Хәзрәт карт түгел әле, үз көчендә, кызыңны бирсәң, ким-хур булмассың, – дип, аптыратып бетергәннәр.

Мулла да моңа: «Әзрәк йомшап китмәсме», – дип, бер тустаган әче бал тоттырган. Әче балны эчеп җибәргәч, ярлы кеше кыюланып киткән. Мыек очларын бөтергәләп, тамак кыргалый башлаган.

– Ай-һай, хәзрәт, – дигән, – кызымны сиңа бирсәм, арагызда әллә ниләр булмагае, дим. Безнең нәсел кешеләре, үзең дә беләсең, авылда иң көчлеләрдән бит, – дигән. – Кызым сине имгәтеп ташласа, әллә нинди бәлаләргә керермен, – дигән.

Ярлы кешенең мактанганын мулла бик яхшы белгән. «Болай булгач, эш җайлана», – дип уйлаган да тегенең биленнән кысып алган.

– Миндә синең кызыңа җитәрлек кенә көч бар әле, – дигән.

Ярлының сөякләре аз гына сынмый калган.

– Ярар, хәзрәт, – дигән бу, – көчең күп булса, сынашып карыйк, безнең көчне дә татып кара, – дигән. – Мин сиңа өстәл тактасы аркылы өч тапкыр коры кул белән сугармын, шуңа чыдый алсаң – кыз синеке, чыдамасаң – йөз сум акча бирерсең, – дигән.

Моны ишеткәч, хәзрәтнең күзләре майланган. Өстәл астына кергән дә:

– Әйдә, сук! – дигән.

– Хәзрәт, – дигән ярлы кеше, – кыз алу, кыз бирү кечкенә эш түгел, ике арада кәгазь язый к. Анда шуны да кертербез, берегез дә

миңа көчләп сугарга кушмасын. Үзем ничек сугарга телим, шулай сугармын, – дигән.

Мулла бу шартка шатланып риза булган. Кәгазь язып, старостадан пичәт тә суктырып алганнар. Шуннан соң мулла өстәл астына кереп утырган да:

– Әйдә, сук! – дигән.

Ярлы агай килеп өстәл тактасына әкрен генә суккан. Мәҗлестәгеләр:

– И аңгыра мужик, бу сугуың белән чебенне дә үтерә алмассың, – дип көлешкәннәр.

Мулла да тегендә:

– Акыллы булса, өч сугар өчен кызын бирмәс иде, мин аңа ничаклы маллар вәгъдә иткән идем, бирмәгән булды, җүләр, – дип көлеп яткан.

Ярлы агай ләм-мим димәгән, чәйнектән агызып бер тустаган бал эчкән дә:

– Калган икесен үз вакытым белән килеп сугармын әле, – дип чыгып киткән.

Шул китүдән кире килмәгән бу, хәзрәт әле дә булса өстәл астында моның килүен көтеп утыра, ди.

Каенсар авылында<br>Миңлемулла Кәримуллин язып алган. 1940

## Абага чәчәге

Имеш, җәйнең нәкъ уртасында төнге уникедә абага чәчәк ата икән. Кара урманга барып, шуны табып авызыңа капсаң, кеше күзенә күренмисең икән.

Менә шул сүзне ишетеп, бер мулла абага чәчәген кулга төшерү турында хыялланган, әмма кара урманга барырга йөрәге җитми, курка икән. Чыннан да, бик куркыныч эш икән бу. Дога укып, абага арасында түгәрәк сызык сызып, шуның эчендә тып-тын гына утырырга кирәк икән. Алай-болай куркып иптәшеңә кычкырсаң, йә шунда сызыктан читкә тайпылсаң, җеннәр өере ботарлап ташлый икән үзеңне.

Мулла тикмәгә шүрләмәгән шул. Алай да өметен өзмәгән бу. Моның курку белмәс бер хезмәтчеге булган. Көннәрдән бер көнне мулла моңа серен ачкан

– Әйдә, бергә барыйк! – дигән.

– Барсак, барырбыз, – дигән теге.

Хезмәтче риза булгач, мулла моңа догаларны өйрәтә башлаган.

– Шул догаларны укыгач, абага эчендә сарымы, кызылмы чәчәк күрсәң, миңа бирерсең, – дигән.

Көне килеп җиткәч, болар култык асларына Коръән кыстырып кара урманга чыгып киткәннәр. Кара урман уртасында болар икесе ике төшкә туктаганнар. Хезмәтче, мулла өйрәткән догаларны укып, түгәрәк сызган да: «Ичмасам, бер туйганчы йоклыйм әле», – дип, сызык эченә кереп ятып йоклаган.

Мулла ике күзен дүрт итеп үз түгәрәгендә утыра биргән. Карый торгач, моның күзенә сынып саргайган яфрак чалынган. Торабара яфрак сарылы-кызыллы чәчәк булып күренә башлаган. Мулла җәһәт кенә яфракны өзеп алып, бисмилласын әйтеп, Коръән эченә салып куйган.

– Йа, хода, картлык көнемдә үз бәхетемә ирештердең, – дип пышылдаган мулла.

Абага чәчәген кулга төшергәч, мулла шатлыгыннан нишләргә белмәгән, алай да җеннәр үтерер дип куркып, шыпырт кына утырган. Хезмәтчесен дә уятмаган.

Таң атып, кайтыр юлга чыккач, мулла хезмәтчене әрләргә тотынган:

– Синең ише ялкау хәерче бәхетен йоклап җилгә очыра. Йокламаган булсаң, бүгенге көнне сиңа да бәхет эләгер иде. Менә мин абага чәчәген кабам да, теләсә нинди кибеткә кереп, җаным теләгән малны алып баеп китәм, – дигән.

Хезмәтче моңа:

– Йокламаган кеше байый торган булса, мин әллә кайчан зур бай булган булыр идем, – дигән. Аннары мулланы котыртып әйткән: – Син әллә баерсың, әллә юк, абага чәчәген кабып караганың булдымы? – дигән.

Мулла абага яфрагын Коръән эченнән алып авызына капкан да:

– Йә, корчаңгы, күрәсеңме мине? – дигән.

Хезмәтче мулланы бик яхшы күрсә дә, күрмәгәнгә салышып:

– Хәзрәт, син кайда? Әллә җеннәр алып киттеме? – дип кычкырган.

– Курыкма, мин монда, синең янда! – дигән мулла.

Хезмәтче мулланың эч серен белергә теләп әйткән:

– Болай булгач, хәзрәт, син баерсың инде, мине дә җиңелрәк хезмәткә күчерерсең, – дигән.

– Һи, ахмак, – дигән мулла, – мин баегач, синә эш тагын да күбрәк булыр, – дигән.

Шулай дигән дә мулла хезмәтчене мыскыл итәргә тотынган. Әле алдына төшеп, әле артына калып, таяк белән төртә башлаган:

– Ишәк, мине күрәсеңме? – ди икән. Үзе шаркылдап көлә икән.

Шулай әрләшеп-нитеп кайта торгач, болар олы су аша салган басмага җиткәннәр.

Басмага кергәч, мулла:

– Күрәсеңме, дим, ишәк? Хи-хи, – дип, хезмәтчегә каты гына төрткән.

Хезмәтче чак кына басмадан төшеп китмәгән. Хезмәтченең бик яман ачуы чыккан. Артына борылган да мулланы күрмәмешкә салынып:

– Хәзрәт, син мондамы? Монда булсаң, артык шаярма, суга төшерә яздың бит, – дигән. – Башка кеше булып, күзгә күренә торган булса, менә болай иттереп кенә бирер идем, – дигән.

Шулай дип муллага берне салып торып җибәргән икән, теге мескен олы суның уртасына ук очып барып төшкән. Төшкән дә Коръәне-ние белән агып та киткән.

Авылга кайткач, хезмәтче, мулланы сораганнарга:

– Хәзрәт абага чәчәген тапкан иде, шуны кабып, кеше күзенә күренмичә йөри торгандыр, – дип сөйләгән.

Каенсар авылында<br>Миңлемулла Кәримуллин язып алган. 1949

## Атланма, билен сындырырсың

Бер көнне берәүнең кечкенә малае тавык йомыркасы табып китергән. Болар бик ярлы торалар икән. Атасы әйткән малайга:

– Улым, бу йомырка безгә зур байлык китерә ала бит, – дигән.

– Ничек ул алай? – дип сораган малае.

– Ә менә ничек: без бу йомырканы күрше әбинең тавыгы астына салып чебеш чыгарырбыз. Чебеш үсеп җитәр дә киләсе елга шушындый ук матур-матур йомыркалар салыр. Ул йомыркаларны сатарбыз да сарык бәрәне алырбыз. Бер-ике елдан сарыкларыбыз да күбәер. Өч-дүртен сатып, кырыкмыш тай алырбыз. Ул ике елдан сабанга җигәрлек ат булыр, өченче елында сиңа бик матур бер колын китерер...

Атасы шулай дигәч, малае шатланып:

– Ул матур колынчыкка атланып мин чабып китәрмен, иеме, әти? – дигән.

Атасы ачуланып:

– Атланма, билен сындырырсың! – дип өстәлгә суккан икән, кулындагы йомыркасы ватылып, әллә кайларга чәчрәгән.

Малай куркып:

– Колынны харап иттең бит, әти, – дип, кычкырып елап җибәргән.

Каенсар авылында
Миңлемулла Кәримуллин язып алган. 1949

## Ялганчы Кәҗә һәм батыр Әтәч

Борын-борын заманнарда бер авылда яшәгән икән, ди, бер бабай. Бу бабайның бер кызы, бер Кәҗәсеннән башка бернәрсәсе дә булмаган, ди. Бик ярлы булган бу.

Көннәрдән бер көнне бабай үзенең кызын болынга Кәҗәсен көтәргә җибәргән. Кыз Кәҗәне көн буена болында көтеп йөргән дә, кичкырын гына алып кайтып, ишегалдына кертеп япкан, ди.

Бабай, Кәҗә янына чыгып:

– Йә, Кәҗәкәем, көне буена болында булып, ни ашадың, ни эчтең? – дип сорый икән.

Кәҗә моңа:

– Бер яфрак ашадым да, бер кашык чамасы су эчтем, – дип җавап биргән, ди.

Картның моңа ачуы килеп:

– Бер Кәҗәне дә туйганчы ашатып кайта алмагансың, – дип, кызын бик каты ачуланган, ди.

Икенче көнне карт болынга Кәҗәне үзе алып киткән. Кәҗә көне буена болында йөреп туйганчы ашаган, ял иткәләп алган да, ди, тагын торып ашарга тотынган. Бабай моны күреп бик шатланган: «Ярый, үзем алып килгәч, бик рәхәтләнеп, туйганчы ашады әле бу», – дип уйлый икән бабай. Шулай дип уйлаган да теге бабай, кич булганны да көтеп тормаган, кәҗәсен калдырып өенә кайтып киткән, ди.

Кич булып караңгы төшүгә, Кәҗә дә болыннан кайтып кергән, ди. Бабай сорый инде бу Кәҗәдән:

– Нихәл, Кәҗәкәем, көне буена болында йөрдең, ни ашадың, ни эчтең? – ди.

Кәҗә аңа:

– Бер яфрак ашадым да, бер кашык чамасы су эчтем, – дип җавап биргән, ди.

Картның моңа бик ачуы килә. «Гаеп кызда түгел, бу Кәҗә үзе бик ялганчы хайван икән», – ди. Шуннан соң бабай: «Бу ялганчы Кәҗәдән барыбер бер рәхәт тә күрмәссең», – дип уйлый да Кәҗәсен суеп ашарга була.

Икенче көнне бабай Кәҗәне ике мөгезеннән тотып алып, аякларын бәйләп сала. Бабай пычак алырга дип өенә кереп киткән арада Кәҗә аякларын ычкындыра да чыгып сыза.

Китә бу. Бара-бара барып җитә бу кечкенә генә бер өйгә. Бу – Куян йорты икән. Барып керә. Өй эчендә беркем дә юк. Бу барып кергәндә, Куянның чыгып киткән вакыты булган икән, ди.

Кояш баеп караңгы төшә башлауга, Куян үзенең өенә кайтып керә. Керсә, ни күзе белән күрсен, теге Кәҗә түр башына менеп, мөгезләрен тырпайтып, сакалын селкетеп утыра икән, ди. Куян моны күреп бик каты курыккан да, алдына-артына карамастан, урманга таба торып чапкан, ди.

Урманга барып керүгә, бу Куянга очраган, ди, бер Бүре. Бүрене күрү белән Куян акырып елый башлаган.

Моны күреп, Бүре:

– Нигә елыйсың, сиңа ни булды? – дип сорый икән.

Куян моңа:

– Нигә еламаска, көне буена урманда йөреп, өемә әйләнеп кайтсам, түр башында бик куркыныч бер нәрсә утыра, күрү белән йөрәгем ярыла язды, – ди.

Моны ишетү белән Бүре батырланып:

– Әйдә киттек, без аны хәзер куып чыгарабыз, – ди.

Китәләр. Куян өенә барып җитү белән, Бүре үзе дә курка-курка гына ишекне ача. Караңгы өйдә зур мөгезле, озын сакаллы Кәҗә башын күрү белән Бүренең дә котлары чыга. Бүре тиз генә өй ишеген яба да урманга карап сыза. Куян аның артыннан китә. Куянның урманга барып керүе була, моның каршысына лап-лап басып килә икән, ди, бер Аю. Аюны күрүгә, Куян тагын кычкырып елап җибәрә:

– Коткарыгыз, харап булдым, өемә куркыныч бернәрсә кергән, – ди.

Аю бик батырланып:

– Ташла әле, юкка-барга елап күз яшеңне әрәм итмә, без аны хәзер куып чыгарырбыз, – ди икән.

Китәләр. Караңгы төшүгә Куян өенә барып җитәләр. Аю бик батырланып өй ишеген ачып җибәрүгә, сәке өстенә менеп утырган зур мөгезле, озын сакаллы Кәҗәне күрү белән, бик каты куркуга төшә. Аю да куркуыннан алдына-артына карамый урманга чаба. Куян – аның артыннан.

Куянның урманга барып керүе була, очрый инде моңа бер Төлке. Төлке дә бик батырланып бара. Караңгы бүлмәдә кукыраеп утырган Кәҗәне күрү белән, Төлкенең дә котлары чыга: кача бу.

Куян нишләсен, йорт-җирен калдырып чыгып китә урманга.

Таң атып яктыра башлауга, барып җитә бу бер урман каравылчысының йортына. Бу йортның койма башында утыра икән, ди, бер Әтәч. Әтәчне күрү белән, Куян, гадәтенчә, тагын да кычкырып елап җибәрә, ди.

– Нигә елыйсың соң син, Куянкай? – ди Әтәч, моннан сорый инде.

– Нигә еламаска, – ди Куян, – минә минем өемә бер куркыныч нәрсә кереп утырды, аны үзем дә, Бүре белән Аю да, хәтта Төлке дә куып чыгара алмады, – ди.

– Юкка елама, Куянкай, әйдә, киттек, минә мин үзем сиңа ярдәм итәрмен, – ди Әтәч.

Китәләр. Куян өенә барып җитүгә, Әтәч әйтә инде Куянга:

– Миңа өй ишеген ачу гына кыен булыр, син ишекне ачып мине кертеп җибәрерсең, калганын үзем белермен, – ди.

Өй янына барып җитү белән, Куянның ишекне ачып җибәрүе була, Әтәч, өй эченә кереп, Кәҗә мөгезләре арасына барып кунуы була. Кәҗә башына куна да бу, чукый башлый Кәҗәнең күзләрен. Кәҗә бернәрсә эшли алмый. Чыгып кача Куян өеннән. Әтәч аны бик еракка хәтле куып бара.

Шулай итеп, батыр Әтәч Куянны ялганчы Кәҗәдән коткарган, ди.

Янил авылында<br>Кәримә Шигаевадан (40 яшь)<br>Х. Гатина язып алган. 1951

## Туй мәҗлесе такмаклары

Алмалар өзеп алдым мин,
Ал яулыкка салдым мин;
Күңлем керде, хәслем салдым[1],
Кызыңны димләп алдым мин.

Атлар җиктем яратып,
Кыйблага каратып;
Без кызыбызны сезгә бирдек,
Үзебез күк яратып.

Ач тәрәзәң, җиләк бирәм
Бөрлегәннәре беләң;
Без утырабыз кодаларның
Бер дигәннәре белән.

Өстәл астым күләгә,
Өстәл өстем кенәгә;
Син кодамны охшатамын
Казаннан килгән түрәгә.

Ишекләрдән кердем мин ай кебек,
Сыгылып сәлам бирдем тал кебек;
Сез кодаларым килеп кергәч,
Җаным эреде сары май кебек.

Җырлап та җырлап без утырыйк,
Бал эчәләр икән, дисеннәр;
Балалы казлар күк шаулашыйк,
Бертуганнар болар, дисеннәр.

Ишекләр ачтым, түрләр күрдем,
Сандыклар ачтым, гөл күрдем;
Сез кодаларым килеп кергәч,
Асыл кошлар белән бер күрдем.

Түшләреңә таккан биш тәңкәңнең
Берсен өзеп миңа бирсәнә;
Эчләреңдә яткан җаның ничек,
Безне лә шулай күрсәнә.

Өсләремә кигән киемемне
Элеп куйдым түргә чөйләргә;
Сез дә кодалар килеп кергәч,
Ямьләр керде безнең өйләргә.

Аршын да аршын ука камзул
Билләрегездән лә артмыймы?
Бер дә ашамыйсыз, бер дә эчмисез,
Әллә безне җаныгыз тартмыймы?

Чылтыр, чылтыр дугалар,
Кыз алырга килгән кодалар;
Үзегез түрдә, атыгыз үрдә,
Нигә җырлашмыйсыз, кодалар?

*Егет ягы:*
Олы юлларның ла, ай, маягы,
Ак юкәгач икән таягы;
Чыгарыгыз әле кызыгызны,
Аксак түгелме икән аягы?

Кара урман артларыннан
Кара ла болыт киләдер;
Кара ла болыт, ай, кар булмас,
Егете матур, кызы хур булмас.

Түбән яктан берәү менә,
Бөрлегәннән кызыл тун тышы;
Килгәннән бирле карап торам,
Сез икәнсез безгә кул кеше.

Кара урманнарны үттем-сүттем,
Мин тапмадым камчылар саплыгы;
Күпләр эзләдем, күп сорадым,
Мин тапмадым сездән яхшыны.

Безнең кодаларның өй капкасы
Барысы да имән тактасы;
Бу да ашаганнар, бу эчкәннәр –
Барысы да олылар аркасы.

[1] *Хәсел салу* – хәстәрен күрү.

Ай, илдек без, илдек без,
Иделләрне кичеп килдек без;
Идел кичеп, юлда кунып,
Бер кыз алырга килдек без.

*Кыз анасы:*
Beләзегемнең билкәсе,
Уникедер аның серкәсе;
Инде генә бездән аерыла,
Сез булырсыз аның әнкәсе.

Түгәрәк өстәл өстендә
Күтәреп суккан ашъяулык;
Кадерсез үскән бала түгел,
Кадерсез итмәгез баштан ук.

*Егет анасы:*
Һавадан очкан кошларның
Койрыгын бөтәрләп тотармын;
Балагыз өчен кайгырмагыз,
Үземнеке күк итеп тотармын.

Алъяпкыч бауларым чия чук,
Чияләнгәч, чишәр хәлем юк;
Син кодагыем белән күрешкәч,
Аерылып китәр хәлем юк.

*Егеткә:*
Алъяпкычың иң түгел,
Ике иң түгел, киң түгел;
Аерылмагыз, пар килгәнсез,
Сезгә ятлар тиң түгел.

Көмеш йөзекләр мин койдырдым
Ялан да көмеш акчадан;
Эзләп алдым, кияү, таптым сине
Гөл чәчәге үскән бакчадан.

Биек кенә тауның, ай, башында
Авыр икән чана төяве;
Никләр җырламыймын берәр җыру,
Үз бәбкәемнең кияве.

*Кәләш:*
Аклы гына күлмәк, кара чалбар
Киярсеңме икән, әтекәй?
Сиңа хезмәтләрем бик әз тиде,
Бәхилләрсеңме икән, әтекәй?

Әткәй, миңа яшел чанаң бир,
Чанаң бирмә, сырлы дугаң бир;
Өстәл башларына бер утырып,
Әткәй, миңа хәер-догаң бир.

*Кияү белән кәләшкә:*
Егет булсаң, бул егет,
Көмеш койдыр каеш йөгәнгә;
Егет гомереңне әрәм үткәрмә,
Кәбен койдыр[1] җаның сөйгәнгә.

Ефәккәй яулык башында,
Җилләр аладыр ла китәдер;
Җилбердәп үскән зифа буйны
Егет аладыр ла китәдер.

Җилбер, җилбер, җилбер чук,
Ник җилберди– җил дә юк?
Сезнең кебек пар килгән
Авылда түгел, илдә юк.

Ике Идел пар килгән,
Агар җире тар килгән;
Казанда түгел, юк Мәскәүдә
Сезнең кебек пар килгән.

Олы юлның буенда
Суырылып үсә бер юа;
Елашмагыз, кызлар,
җырлашыгыз,
Аерылыша торган бер йола.

Ишек алды шау нарат,
Ник шаулый икән бер нарат?
Шауламас иде ул нарат,
Аерылып китә бер канат.

[1] *Кәбен койдыру* – никах укыту.

*Кызның өшәнчекләрен элгәндә:*
Чуклы гына да сөлгеләрне
Элеп лә куйыйк түрләргә;
Без кызыбызны сезгә бирдек,
Хезмәт итсен иде сезләргә.

Аклы гына сөлгеләрдән
Хуш ис кенә аңкысын;
Безнең туганкайның йөзләре
Нурлар кебек балкысын.

*Кәләш:*
Түшләремә бәйләгән тәңкәмне
Ничек итеп чутларын алыем?
Энекәем урынына син калдың,
Ничек итеп күңелләреңне табыем?

Кунакларны озатканда:
Килсен лә болыт, яусын яңгыр,
Китсен лә урман буена;
Безнең болай йөрешүләр
Китсен лә гомер буена.

И айлаштай, айлаштай,
Табаларда пешкән майлы аштай;
Сез китәрсез, без калырбыз
Яфракларын койган агачтай.

*Туй мәҗлесендә:*
Кара урманнарны чыккан чакта,
Очрады миңа Миннәхмәт;
Олы башларыңны кече итеп,
Җырлап бирүеңә рәхмәт.

Миңа әтекәем атлар бирде,
Күк алаша белән алыш, дип;
Миңа энекәем шуны әйтте:
Үз туганнарың белән таныш, дип.

Башларыңа япкан яулыгың
Яңа гына яуган кар кебек;
Йөзләрегез тулган ай кебек,
Акылыгыз сары май кебек.

Сезнең илдә басма ясыйлармы?
Безнең илдә басма ясыйлар;
Сөйләшер сүзгә, күрер күзгә,
Безнең илдә сезне мактыйлар.

Сезнең янга барыр идем,
Араларда иннек  бар;
Сез кодалар белән утырулар
Йөзлек түгел, меңлек бар.

Ишек алдым яшел чирәм,
Таптый-таптый кайтырбыз;
Бу сыйларны, хөрмәтләрне
Мактый-мактый кайтырбыз.

Кара урманнарны чыккан чакта
Бөрлегәннәр ашадым туйганчы;
Китмәгез әле, туганнар,
Күзкәйләрем күреп туйганчы.

Сәрдәүч авылында
Анастасия Матвеевадан
һәм Ольга Дмитриевадан
Н. Әхмәтҗанова язып алган. 1958

## Комсомолец Рәхи бәете

Бер мең дә тугыз йөз дә утыз алтынчы елларда,
Башларымны ашадылар кышкы салкын буранда.

Усал кулак кулларында ак пычак ялтырады,
Караңгыда ялгыз башым, йөрәгем калтырады.

Кичтән чыккан вакытымда үләсемне белмәдем,
Әҗәл җитми үлеп киттем, дусларымны күрмәдем.

Кичен җырлап йөргән идем Мәмәшир урамында,
Төнлә Гомәрләр чәнечте тау башы урамында.

Гомәр эчемә чәнечкәч, чыкты кайнар каннарым,
Кукмара больницасында чыкты минем җаннарым.

Урак урган җирләрем, печән чапкан җирләрем,
Үзем үлдем, күкрәп калды туган-үскән илләрем.

Әнкәй, ашың пешеп җиткәч, балаларың җыелыр;
Алар булып, мин булмагач, кайнар яшең коелыр.

Зиратларда сайрап торган мин яраткан кош булыр,
Чәй эчәргә утырырсыз, минем урыным буш булыр.

Машиналар кызу бара, төягәннәр ташкүмер,
Егерме бер яшькә җиткәч, әрәм булды яшь гомер.

Сөйгән кызым, урамнарда сулап йөр син киң сулу,
Төрле чакларым булгандыр, бәхил булсын Миңсылу.

Миңсылуны күрә алмадым азакк ы сулышымда,
Кулларыннан кыса алмадым, үкенәм шунысына.

Вәкъкас дустым, синең белән җырлап йөрдем урамда,
Минем җаным чыккан чакта, син калдың чит урамда.

Мин йөргән автомобильдә колхозчылар йөрсеннәр,
Мине үтерүчеләргә каты җәза бирсеннәр.

Сабан туе көннәрендә җыела яшьләр чатларга,
Дуслар, мине искә алыгыз урам йөргән чакларда.

Вәкъкас, Рәхим, Борһан, Нурый, онытмагыз мине дә,
Ак бәхетләр телим сезгә җаным чыккан көнемдә.

Ах, дусларым, түзегез, түкмәгез яшегезне,
Инде мәңге күрә алмассыз якын иптәшегезне.

Безнең басу уртасында чәчәк ата гөлҗимеш,
Мине үтерүчеләрдән сез үч алырга тиеш.

Абый, дуслар, әткәй, әнкәй, йөзләремне күрегез,
Мин үлгәнгә борчылмыйча, матур тормыш төзегез.

Уралып, уралып ага шул Уралның сулары,
Гомерлеккә кала миннән Мәмәшир басулары.

Миннән калган киемнәрне туганнарым кисеннәр,
Совет өчен, колхоз өчен корбан булды, дисеннәр.

МТСтан алып кайтыйк ашлык суккыч машина,
Габдрахманов Гомәр җитте безнең Рәхи башына.

Мәмәширнең урамнары ике яктан канаулы,
Үтерүче дошманнарның көне булсын санаулы.

Кыр казлары йөзеп йөри, йөзеп йөри күлләрдә,
Мәмәширне кайгы басты безнең Рәхи үлгән көннәрдә.

Комсомол утырышына бергәләп йөргән идек,
Киләчәкнең җиңүенә планнар корган идек.

Тракторлар, комбайннар кайтты безнең кырларга,
Рәхи булмас инде хәзер вечерларда җырларга.

Әйдә, дуслар, киң кырларга, анда көтә басулар,
Безнең йөрәкләребездә кайный соңгы ачулар.

Мәмәшир авылының алдынгы шоферы
Зәйнуллин Рәхине авылдагы кулак калдыклары
1936 елның февралендә төнлә үтерәләр.
Рәхинең якын иптәшләре, аның истәлегенә
шушы бәетне чыгарганнар.
Аны Зариф Шәрипов язып җибәргән. 1941

## БАЛАЛАР ФОЛЬКЛОРЫ

### Такмазалар

*Балык тотканда*

Чиерт, чиерт, чиртмә бирәм,
Тарт, тарт, тартма бирәм.
Ала чык, бала чык,
Бер балыкны тарт та чык.

Янил авылыннан
Рәйсә Рәхмәтуллина
язып җибәргән. 1978

Балык баласы,
Суга саласы.
Агып киткәнен
Карап каласы.
(Кечкенә балыкны суга җибәргәндә әйтелә.)

Мәчкәрә авылында Резидә
Сәмигуллина язып алган. 1982

*Югалткан әйберләрне эзләгәндә*

Пәри, тап, тап, тап,
Тапсаң, тәмәке бирәм.
Тапмасаң,
Биш балаңны үтерәм,
Пумала белән куам.

Туембаш авылында Г. Вәлиева
язып алган. 1982

## Үртәвеч

Мостафа
Өй артында тоз сата.
Тозын сатып бетергәч,
Ботын күтәреп ята.

Туембаш авылында Г. Вәлиева
язып алган. 1982

## Такмаклар

Столовой калагы,
Берсе озын, берсе кыска
Чалбарыңның балагы.

Түбән Өскебаш авылында
Рәмзия Ганиева язып алган. 1982

Әби коймак пешерә,
Бабай ашап бетерә.
Тыңламаган малайларның
Артларына төшерә.

Кенәбаш авылында
Әлфия Әскәрова
язып алган. 1982

Ырлый, бырлый,
Кара тавык җырлый;
Үзе күкәй салмый,
Кешенекен урлый.

Олыяз авылында Мөнзилә
Шәфигуллина язып алган. 1983

Хәдичәләр, Мәймиләр,
«Чарт-чорт» сагыз чәйниләр.

Күкшел авылында
Дания Шакирова
язып алган. 1983

Кәҗә, кәҗә, мәкәрҗә,
Кермә минем бакчама.
Утыртырмын чуманга.
Апкитәрмен урманга,
Ашатырмын төлкегә,
Калдырырмын көлкегә.

Туембаш авылында Г. Вәлиева
язып алган. 1982

## Такмазалар

### *Әкиятсыман такмазалар*

Борын-борын заманда,
Монда түгел, Казанда
Яшәгән, ди, Мирза,
Чыгарган, ди, моржа;
Калдырмаган тишек.
Яккан, ди, ул пичен,
Тутырган, ди, төтен.
Күргән, ди, Хуҗа,
Башлаган, ди, куа.
Ялына, ди, Мирза:
– Төзәтермен, кума!
Куа икән, хуҗа,
Тоттырмый, ди, Мирза.
Борылган, ди, сулга,
Егылган, ди, суга.
Килеп җиткән хуҗа,
Кундырган, ди, моңа:
– Сабак булсын сиңа,
Бүтән алдакчы булма!

Туембаш авылыннан Г. Вәлиева
язып җибәргән. 1982

### *Бардым Тубага*

Бардым Тубага,
Кердем яңа кодага.
Кода суйган ак каз,
Ул да булса ят каз.
Килеп керде иясе,
Каз минеке диясе.
Түзмәде, салдырды судка,
Барып кердек судка,
Пешергәннәр ботка.
Куймаганнар ипи,
Куймаганнар кашык,
Утырабыз карашып.
Шул арада булмады,
Килеп керде Дәүли:
«Каз минеке», – дип даулый.
Килеп керде Җамалый,
Яңакларга чамалый.
Килеп керде Бәчә,
Мич арасына керде дә,
Каз мамыгын чәчә.
Өйдә чыдар хәл калмады –
Чыгып киттем тышка.
Салам күсәк күтәреп,
Басып торам ташка.
Килә Давыт,
Җиккән пар тавык,
Төягән табак-савыт.
Салам күсәк белән суккан идем,
Китте Давыт авып,
Чәчелде табак-савыт.
Табак-савытны җыярга килә
Йосып,
Киртә буена посып.

Мәчкәрә авылыннан
С.Н. (исем-фамилиясе тулысынча
күрсәтелмәгән) язып җибәргән. 1978

## Тел көрмәкләндергечләр

Татарстанның Татар Танае тимерчесе Таҗи Тимербаевның тае Тәтеш тавын төшкәндә тайның тоягы таеп тәртәгә тиеп, тәртәне теттереп ташлаган.

Сәрдек авылыннан Өлфәт Миңнемуллин
(10 яшь) язып җибәргән. 1975

Җылама, җылама, Җамалый, җылап җиңең җамалмас.
Җыламасаң, җиңгәң җиңеңне җамар.

Байлангар авылында Илдар Әминевтән
Алабуга дәүләт педагогия институты
студентлары язып алган. 1985

### Алдавыч әкият

Борын-борын заманда, булган, ди, бер бай. Аның булган, ди, бер көтү сарыгы. Көтү кайткан саен саный икән, ди, ул сарыкларын. Саный, ди, саный, ди, саный, ди... Ярар, саный торсын, санап бетергәч дәвам итәрмен...

Байлангар авылында Илдар Әминевтән
шул ук студентлар язып алган. 1985

### Санамыш

Аладан, боладан,
Мәче йөри елгадан.
Убырын, бубырын,
Остабикә, десятник,
Син кал, син чык.

Балыклы авылында Н. Галимова
язып алган. 1978

### Әйтеш

– Әби, кая барасың?
– Карурманга барамын.
– Аю-бүредән курыкмыйсыңмы?
– Юк.

*Шулай дигәч, күзенә өрәләр. Күзен йомса:* «Куркасың бит!» – *диләр.*

Туембаш авылында Г. Вәлиева
язып алган. 1982

### Алдавычлар

– Куян, диген.
– Куян.
– Башыңа тамга куям (*башына сугып алалар*).

Туембаш авылында Г. Вәлиева
язып алган. 1982

Уч төбендә бензин белән керосин.
Бензин, керосин; бензин, керосин.
Иснәп кара әле, нәрсә исе килә?
*(Учын иснәп торганда, шаяртып борынын кыстырып алалар.)*

Туембаш авылында Г. Вәлиева
язып алган. 1982

## ХАЛЫК КҮҢЕЛЕНЕҢ САФ КӨЗГЕСЕ

*Илсөяр Закирова*

Кукмара үзенең һөнәрчеләре, осталары белән данлыклы. Ялтырап торган җиз самавырлар, комганнар кайчандыр шушы төбәктә коелган. Кукмаралыларның атаклы итек басучылар икәнен бөтен Татарстан белә. Бу итекләрне чигеп бизиләр дә бит әле. Чиккән итекләр элек-электән затлы киемнәрдән саналган. Шушы төбәктә яшәүче керәшен, рус, мари, мордва халыкларының да милли киемнәре күз явын алырлык.

Без булган Сәрдекбаш, Яңа Сәрдек, Зур Сәрдек, Уразай, Тырыш, Аш Бужи, Кара Елга – бер-берсенә якын урнашкан авыллар. Зур йортлар, төзек капка-коймалар, сәнгать әсәре дәрәҗәсенә җиткерелеп эшләнгән тәрәзә йөзлекләре сокландыра. Татар авыллары шушындый булырга тиештер дә, дип уйлыйбыз. Бу авылларда йөргәндә, халыкның һөнәрле булуын тагын бер кат күрдек. Чиккән мендәр тышлары, сөлгеләр, тәрәзә пәрдәләре күп өйләрдә очрый. Шәл бәйләүчеләр, чигү чигүчеләр күп.

Сәрдекбаш авылындагы Фәүзия апа Баһавиевадан бәетләр, җырлы-биюле уеннар язып алдык. Кайчандыр Фәүзия апалар Мөхәммәт Мәһдиевне кунак иткән. Язучы Фәүзия ападан шәл бәйләү, бизәк исемнәре турында сорашкан, хәтта газетада «Шәл бәйләүче Фәүзия» дигән мәкалә язып чыккан. Нәкъ шушы мәкалә реклама ролен үтәгәндерме, Фәүзия апа илнең әллә кайсы почмакларыннан шәл сораган хатлар алган, аның шәлләрен кайларда гына бөркәнмәгәннәр. Әлбәттә, бу риваять тә, дастан да түгел, әмма мәшһүр язучыбыз, яраткан укытучыбыз Мөхәммәт абый турында истәлек буларак без аны язып алдык.

Уразай авылында яшәүче Саҗидә апа Мифтахова белән аның сөйкемле килене безне кадерле кунакларны көткән кебек

каршы алдылар. Саҗидә апа мөнәҗәтләр дә, риваятьләр дә күп белә икән.

Гомумән, кемгә генә керсәк тә, эшебезнең кирәклеген аңлаган, теләп ярдәм иткән әңгәмәдәшләр белән очраштык. Аларның барысын да санап чыгу мөмкин дә түгел. Аеруча өлкән яшьтәге акъәбиләр белән очрашулар күңелдә озак сакланыр. Яңа Сәрдектә яшәүче Фатихабану әби Мостафинадан мөнәҗәтләр, җырлар язып алдык. Мәсәлән:

Алмагачка кошлар кунган,
Кулъяулык болгап куам.
Җаным, бәгърем, хатлар яздым –
Шуларны укып куан.
Алмагачның төбе юеш,
Кичә яңгыр яуганмы?
Кулларны кулга бирешеп
Күрешергә язганмы?

Бу җырлар турында, Тукайга ияреп, «халык күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә рушан көзгеседер», дияргә генә кала.

Югары һәм Кече Чура дигән керәшен авылларында булганда да халыкның тырышлыгына, җаваплылыгына сокландык.

Гомумән, бу төбәк халкының йола-бәйрәмнәре хакында бай һәм кызыклы материал таптык, матур җырлар язып алдык. Мәсәлән, Зоя апа Егоровадан язып алган юраулар, төшлек салулар турында әле ишеткәнебез юк иде. Нардуган көннәрендә, төгәлрәге 13 гыйнварда кызлар киләчәген юраган. Кайчан кияүгә чыгасын беләсе килгән кызлар «читән кочаклаган», ягъни күзне йомып, рәшәткә (койма) кочаклаганнар. Әгәр рәшәткә такталары парлы булса, кыз шул елны кияүгә чыга. Ә кемгә чыгасын беләсе килсә, бер коймак пешереп, шул коймакны ашап, урамга чыккан. Беренче очраган кешенең исемен сораган. Димәк, ире дә шул исемдәге кеше булачак. Ярар, кайчан, ни исемле кешегә чыгасын да белде, ди. Ә ул кешене күрәсе килсә? Ул чагында төшлек саласың. Бер ак яулыкны төреп, баш астына салып, «уйлаган кеше төшкә керсен», – дип йокларга ятарга кирәк. Яки өстеңә чыбыклардан кое бурасы ясап элеп була. «Миңа кияү буласы кеше шушы коега су алырга килсен!» – диясе генә кала.

Зоя апаның сүзләренә караганда, бу юраулар киләчәктә ни көткәнен дөп-дөрес әйтеп бирә икән.

Кукмарада без булган соңгы авыл – Бучирмә (Березняк) авылы. Абдуллина Әминә апа безгә «Зәрә боткасы», «Сөрән» йолабәйрәмнәре, уеннар буенча кызыклы мәгълүмат бирде.

Гомумән, бу авылларны, Кукмара ягының матур табигатен, ачык йөзле, кунакчыл халкын без әле бик озак оныта алмабыз.

Халык күңеленең «раушан көзгесе»нә бергәләп күз салыйк әле.

## Мөнәҗәтләр

*Сабырлык*

Сабырлыктыр эшнең башы,
Сабырлыктыр күңел хушы,
Сабырлыклар иман нуры,
Сабырлык бир Тәгалә Аллам.

Сабыр итим, сабыр итим,
Сабыр итми нихәл итим?
Сабырлык бир, Тәгалә Аллам,
Сабырга рәхмәтем, диде.

Сабырга дәүләтем, диде.
Сабырга җәннәтем, диде.
Сабырлык бир, Тәгалә Аллам.

Сабырлыкның савабын
Китаплардан караганнар.
Сабыр иткән бәндәләрне
Изгеләрдән санаганнар.

Сабырлар җәннәткә керер,
Аллаһның рәхмәтен күрер.
Сабырсызлар – җәһәннәмгә.
Сабырлык бир, Тәгалә Аллам.

Сабырлык бир, сабырлык бир,
Сабыр коллар сабыр итәр,
Сабыр коллар сират күперен
Искән җилдәй җиңел үтәр.

Сабыр итик, сабыр итик,
Сабыр колдан шайтан качар,
Сабыр коллар җәннәт ишеген
Үз куллары белән ачар.

Түзә алмый йөрәк сыза,
Күзләрдән яшьләр коела.
Сабырларны Аллаһ сөя,
Сабыр бирсен Тәгалә Аллам.

Оча торган кошлар кебек
Һаваларда йөрсәк иде,
Җәннәт сараена кереп,
Дидарыңны (*Аллаһ Тәгаләнең үзен*) күрсәк иде.

Әҗәлләргә дәвалар юк,
Әҗәлләргә гозерләр юк.
Бакый иман белән барсак,
Булыр эшләребез бөек.

Ата-анадан, балалардан
Аерадыр ачы үлем.
Ходаем рәхмәтен салса,
Якты булыр минем гүрем.

Барыр җирем – кара туфрак,
Ятар җирем – кызыл балчык.
Кыямәт көне булганда,
Йөземне кыл, Раббым, ачык.

Бу дөньялар бездән калыр,
Кара туфрак чорнап алыр.
Кара туфрак астында кол
Күзен ачса, хәйран калыр.

Кәүсәр дигән елгалардан
Суларыңны эчерсәнә!
Яшеннәр яшьнәгән кеби
Сиратыңны кичерсәнә!

И Ходаем, сабыр әйлә.
Теләгемне кабул әйлә!
Фирдәвеси җәннәтеңне
Барчабызга насыйп әйлә.
Амин.

* * *

Шайтан сиңа сөялмәсен,
Аяк-кулың бәйләмәсен,
Күңелеңне каралтмасын,
Укы Коръән илә намаз.

Тот ураза, бир сәдака,
Хәлен белче ятимнәрнең.
Укы Коръән, әйт мөнәҗәт –
Күңеле булсын мөэминнәрнең.

Бәраәт кичәләрендә
Зәм-зәм суына бараек.
Бергә-бергә җыелышып,
Мөнәҗәтләр әйтеп алаек.

Рәхмәт ае килә, дуслар,
Гафил булып кала күрмик.
Пәйгамбәрләрнең шәфәгатен
Ахирәттә бергә күрик.

Рәхмәт ае килә безгә,
Бар фәрештә җиргә иңәр.
Фарыз гамәлләрне кылыйк,
И, туганнар, бергә-бергә.

Рамазанда руза тотып,
Әҗер саваплары алыйк.
Кәүсәр суларын эчәргә
Ахирәткә бергә барыйк.

Сәхәрләрдә Коръән укып,
Әҗер саваплары алыйк.
Кыяматтә барыбыз да
Изгеләр сафында булыйк.

Купка авылында Шәймәрданова
Мәскүрә Газизулла кызыннан (1944)
язып алынды

## Бәетләр

*Авылдагы мич бәете*

Бисмиллаһи, дип язып куям
Яза торган бәет башына.
Туксанынчы елда кергән газлар
Җитте минем газиз башыма.

Юкә утыннары ягып кына
Пешә иде гает коймагы.
Гает кайткач, минем хуҗа абзый
Шул коймакны ашап туймады.

Тәмле булып пеште бәлешләрем,
Матур китердем мин йөзләрен.
Ашаганда дуслар җыелышып
Йота язды бар да телләрен.

Пешә иде чүлмәк, чуен ашы,
Чыга иде хуш ис өйләргә.
Кая микән шушы хуш исләр, дип,
Бар да калды сагынып сөйләргә.

Гәрәбәдәй арыш икмәкләре
Пеште минем кайнар куенымда.
Карыны ачкан нәни балаларның
Зур телемнәр иде кулында.

Өйнең нуры булып утырдым мин,
Ап-ак иде минем күлмәгем,
Йөзем якты, тәнем җылы булды,
Авырлыклар һич тә күрмәдем.

Дәрәҗәле үткән көннәремне
Оныта алмыйм, гел дә уемда.
Хәзер инде ап-ак чеби генә
Үстерәләр минем куенымда.

***Җизни бәете***
*(2004 елның октябрендә поездга бәрелеп үлгән җизнәм Кәримулла улы Мөхлисуллага багышлана)*

Бисмиллаһи, диеп куям
Бәетемнең башына.
Тиз йөрешле яшел поезд
Җитте минем башыма.

Машинисты, мине күргәч,
Кычкырткандыр гудокны.
Ишетмәдем кычкыртканын,
Нишләтим соң колакны?

Кичен генә чыгып киттем
Апай хәлен белергә.
Аллаһтан вакыт җиткәндер
Салкын гүргә керергә.

Парлы чардуган ясагыз
Каберемнең өстенә.
Гамиләгә насыйп булсын
Шул урынның берсенә.

Гамилә бергә йөрдек без,
Йөрмәдек без якланып.
Пар күгәрченнәр килә, дип
Калды халык сокланып.

Балаларны кеше иттек,
Үкенечкә калмасын.
Кызым Альмираны гына
Тормышлы итә алмадым.

Телефоннан шалтыраткач,
Бар туганнар җыелды.
Минем йөземне карагач,
Күз яшьләре коелды.

Соңгы вакыт ни эшләптер
Күңелләрем үсмәде.
Ходай миңа сиздергәндер
Гомеремнең беткәнен.

Балаларым, туганнарым,
Мин китәмен мәңгегә.
Гамиләне ташламагыз,
Яшәгез бергә-бергә.

*Зөлфия бәете*

Бисмилла белән башлыймын
Язасы һәр бәет башын.
Яшьләй генә салкын кара гүргә
Кереп ятты газиз башым.

Озак тартыштым мин үлем белән,
Җиңеп кенә аны булмады.
Кеше каны акты йөрәк аша,
Үз каннарым бер дә калмады.

Өч кыз-туган үстек иркә генә,
Авырлыклар бер дә килмәде.
Нишләптер, бары миңа гына
Озын гомер Ходай бирмәде.

Матур үтте үзе минем яшьлек,
Ашыкмадым тормыш башларга.
Минем язмыш – шушы кыска гомер,
Язылгандыр, бәлки, ташларга.

Туганнарым, артык еламагыз,
Ходай бирсен сезгә сабырлык.
Кызым калды минем, төсем булып,
Аңа гына карап торырлык.

Алдан белдем балам кыз буласын,
Исемен дә куйдым әзерләп.
Булмады шул насыйп миңа гына
Үстерергә аны иркәләп.

Әти-әни, сезгә бигрәк авыр,
Авыр була бала кайгысы.
Мин китәм шәһит үлем белән,
Балам калды сезгә карыйсы.

Рамил, бәгырем, мең дә бәхил синңа,
Ташламадың соңгы көнгәчә,
Өмет иттең һаман, булыр, диеп,
Ятсам да мин берни белмичә.

Рәхәт яшә, яңа тормыш башла,
Кайгы-хәсрәт кабат килмәсен.
Ташлама син кызыбыз Зәлияне,
Ятимлекне бер дә сизмәсен.

Еллар үтәр, кызыбыз үсеп җитәр,
Минем каберемә килерсез.
Сине тапкан газиз әниең, дип,
Гөл-чәчәкләр белән күмерсез.

*Һадиев Габделбәр бәете*

Бисмиллаһи, дип яза башлыйм,
Яза башлыйм бәет башларын.
Сырхауханә капка төпләрендә
Ятып калды газиз башларым.

Күпме табибларга йөрсәм дә,
Авыруым һаман котырды.
Табиб миңа, терелгәнсең, диеп,
Больничныйны ябып тоттырды.

Тормыш миңа шактый авыр булды,
Дөньялыкта рәхәт күрмәдем.
Аллаһ кушып, ахирәткә баргач,
Рәхәт үтсен иде көннәрем.

Җир астыннан юллар юк, дисә дә,
Юллар булыр бездәй колыңа.
Зөләйха, син көтеп торсаң иде,
Ишек ачып оҗмах юлына.

Балаларым, кечкенәдән генә
Анагыздан ятим калдыгыз,
Ә шулай да минем белән бергә
Тормышны сез алып бардыгыз.

Мескеннәрем, хәзер мин дә китәм,
Каласыз сез бүген дөм ятим.
Аллаһ безгә менә шулай кушкан,
Каршы килеп булмый, нишләтим.

Мәчетләрдә, Алсу, син укыйсың,
Ташламасын Ходай ярдәменнән.
Иртә-кичен дога кылсаң иде,
Кызым, синнән шуны көтәмен.

Айнур улым, син тәүфикътан язма,
Тәүфикъ булса, бәхет була ул,
Әтисез дә, әнисез дә калгач,
Тормыш итү авыр була ул.

Айсылу, син мине нык яраттың,
Миннән башка тынгы тапмадың.
Күпме борчылсаң да, «әти» диеп,
Больницадан кире кайтмадым.

Тәтәләрем, бар да сезгә кала,
Ятим балаларны безнең карарга.
Ярдәм итегез сез берүк аларга да
Тормышларын ныклап корырга.

### *Факил бәете*

*(2008 елның 15 сентябрендә машина белән бәреп үтерелгән Ибраһимов Факил Хәбир улына багышлана)*

Бисмиллаһи, диеп язып куям
Яза торган бәет башына.
Кәчимирдән эштән кайткан чакта
Җиттеләр бит газиз башыма.

Башланган эш тәмамлансын, диеп,
Сизмәгәнбез төннәр җиткәнне.
Чыгып киттем, өйгә кайтам, диеп,
Белмәгәнмен гомерем беткәнен.

Явыз дошман куып килгән кебек,
Бер машина килде артымнан.
Эчендәге мәрхәмәтсез шофер
Шашкан булды ахры акылдан.

Арт ягымнан килеп бәреп китте,
Туктаса да, ярдәм итмәде.
Җаным чыкты шунда юл читендә
Үтүчеләр мине күрмәде.

Венера, син мине эштән көттең,
Эшләремнән кире кайтмадым.
Эзләп чыктың юлдан төннәр буе,
Караңгыда мине тапмадың.

Таң атканчы яттым юл читендә,
Көн яктыргач, таптың гәүдәмне.
Кычкырдың син: «Факил,
бәгърем!» – диеп,
Яңгыратып бөтен галәмне.

Авыр калды, бәгърем, бу дөньяда
Тормыш йөген сиңа тартырга.
Булышсалар гына туганнарым
Калган йортларымны корырга.

Әти-әни, газиз туганнарым,
Еламагыз минем үлемгә.
Ходай кушкан миңа шундый язмыш,
Кеше керми кеше гүренә.

### *Рәшидә бәете*

*(Тарлау авылында яшәгән Ибәтуллина Рәшидәгә багышлана)*

Мөхтәрәм туганнар, язам
Рәшидәгә мин бәет.
Җитмәгән җирләре калса,
Булмасын инде гаеп.

Ике меңнең ахырында
Салкын кышлар башланды,
Салкын кышлар алып китте
Минем газиз башларны.

Гомер буе яшәдем мин
Әкрен, үз көемә.
Кукмарадан туңып кайттым
Кичен генә өемә.

Күпме юрганнар япсам да,
Җылытмадыканымны.
Шушы төндә Газраил
Килеп алды җанымны.

Иртән балам эндәште дә,
Күреп минем йөземне.
«Әни җаным үлгән» – диеп,
Урамга ук йөгерде.

Хәбәр иткәч, «үлде» диеп,
Хезмәттәшләр җыелды.
Мине күргәч, барсының да
Күз яшьләре коелды.

Атасыз да, анасыз да,
Калдыгыз сез, балалар.
Шушы яшь балаларны
Кемнәр хәзер карарлар.

Балаларым, сез ятимнәр,
Тәүфикъলардан язмагыз.
Авыр булыр, ничек тә сез
Әбиегезне карагыз.

Әй, туганнар, бу дөньяда
Калды бик күп эшләрем.
Шушы ятим балаларны
Башлы-күзле итмәдем.

Гүзәл, дустым һәрвакытта,
Уртак булды серләрең.
Миннән башка ялгыз гына
Ничек үтәр көннәрең.

Иртә, кич тә, һәрвакытта,
Юлларда бергә йөрдек.
Ходай безне аерды бит,
Аерылмас дуслар идек.

Кышлар үтәр, җәйләр җитәр,
Каберемә килегез.
Минем кара туфрагымны
Чәчәкләргә күмегез.

*Сәлимгәрәй бәете*

Дәфтәр алып, каләм тотып,
Башлыйм язар сүземне.
Шешәдәге яшел елан
Харап итте үземне.

Әти, җаным, күпме әйттең,
Тыңламадым сүзеңне.
Менә хәзер балаларга
Ташлап китәм үзеңне?

Бу дөньяда мин эшлисе
Калды бик күп эшләрем.
Туганнарым, көтмәгәндә
Ялгыштым мин, нишләдем.

Минем үлгәнне ишеткәч,
Туганнарым җыелды.
Сизеп ятам барысының да,
Үзәкләре өзелде.

Әкълимәкәй, исән чакта
Төрле хәлләр булгандыр,
Хәзер инде догаңны кыл,
Каберемне нурландыр.

Әкълимәкәй, исән чакта
Авыр сүзләр әйтмәдең.
Мине ташлап китәр бу, дип,
Һич кенә дә көтмәдең.

Менә хәзер мин китәмен,
Каласың син ялгызың.
Сабыр ит син, җаныкаем,
Синең шундый язмышың.

Балаларым, бу дөньяда
Кешегә начар булмагыз.
Хәзергә көн шуны әйтәм:
Анагызны тыңлагыз.

Сез үсәрсез, зур булырсыз,
Атагызны белегез.
Җәйләр саен, онытмыйча,
Каберемә килегез.

Бергә эшләгән дусларым,
Эчәргә өндәдегез.
Бәлки хәзер үкенә-үкенә
Үтәдер көннәрегез.

Үкенегез, эчмәгез сез,
Бетсен хәзер ялгышлар.
Сез эчсәгез, сезне көтә
Шушындый ук язмышлар.

***Рәкыйп абый бәете***
*(Урып-җыю вакытында комбайнга кысылып үлгән Нуриев Рәкыйпкә багышлана)*

Бисмиллаһи, диеп башлыйм
Бәетемнең башларын.
Комбайннарга кысылды
Минем газиз башларым.

Комбайннан алдылар да
Мине сузып салдылар.
Җыелган бар иптәшләрем,
Күреп, телсез калдылар.

Балакаем өзгәләнде,
Күреп минем каннарны.
Тынды ул, «нишлим» диеп,
Йөзендә нур калмады.

Балакаем, син кайгырма,
Әҗәлләрем җиткәндер.
Ходай миңа шулай кушкач,
Миңа шундый тәкъдирдер.

Балаларым, бик нык елап,
Үзегезне бозмагыз.
Минем сезгә васыятем –
Анагызны тыңлагыз.

Мәхтүмәкәй, исән чакта
Мин белдем кадереңне.
Хәзер инде догаңны кыл,
Нурландыр каберемне.

Мәхтүмәкәй, ашың бүлгәч,
Балаларың җыелыр.
Шул чакларда мин булмагач,
Күз яшьләрең түгелер.

Озак булса да, көтегез
Сәгать өч тулганнарын.
Бер киткәчтен, кайтып булмый,
Күрсеннәр туганнарым.

Матур итеп яңгыр яуды,
Мине алып киткәндә.
Туганнарым сөенеп куйды,
Изге җаннан икәнгә.

Җитәр инде, бераз яздым
Йөрәгемдә булганын.
Шуның белән тәмам итәм,
Бәхилләгез, туганым.

*Сөембикә бәете*

Бисмилләһи, диеп башлыйм
Һәрбер язар сүземне.
Кукмарада больницада
Йомдым ике күземне.

Кайларга гына йөрмәдем,
Әйтмәделәр чиремне.
Төшләремдә дә бит күрдем
Шушы салкын гүремне.

Авырлыклар булганда да,
Шат булды шул күңелем.
Шат күңелле булсам да мин,
Кыска булды гомерем.

Газраил килгән чагында
Әҗәлдән булмый качып.
Пәйгамбәрләр көтсен иде,
Оҗмах ишеген ачып.

Изге Рамазан аенда
Мин дөньялыктан китәм.
Ходай кушсын, ахирәттә
Оҗмахын өмет итәм.

Улым, кызым, миннән калгач,
Тәүфикълардан калмагыз.
Тәүфикъ булса, бәхет булыр,
Сез шушыны аңлагыз.

Дөнья камытын киясең,
Яшьли генә син үзең.
Иярмә, улым, начарларга,
Тыңла олылар сүзен.

Яшьләй әнидән калдым, дип,
Улым, үзеңне ватма.
Тырыш балам, син ничек тә
Булган дөньяңны сакла.

Әсхәдулла, кер тәүфикъка,
Бала мәхрүм булмасын.
Ата бул син, безнең бала
Мескен булып тормасын.

Булган дөнья-мөлкәтеңне
Вайран итмә син, сакла.
Кызым торсын яныгызда,
Бер үк аны да какма.

Әсхәдулла, исән чакта
Белдеңме кадеремне?
Чардуганың ясатып куй,
Таптатма каберемне!

Әҗәлләрем җитә, диеп,
Күңелемә сизелде.
Бала үсеп җимәде, дип,
Үзәкләрем өзелде.

*Райнур бәете*

Мәчетләрдә кем укыган
Корбан ае гаетен.
Мин язамын шушы айда
Үлгән Райнур бәетен.

Салкын кышлар үтеп киткәч,
Матур язлар җитәләр.
Шушы язның бер төнендә
Җаным алып китәләр.

Соңгы вакыт, нишләптер, мин
Дөньядан ямь тапмадым.
Аякларым сызлаганга
Таяк белән атладым.

Кошлар килер озакламый,
Кунып сайрар кыекка.
Гөлназ, бәгырем, кошка карап,
Райнур юк, дип боекма.

Улым кала, дәвам булыр,
Терәк булыр һәрчакта.
Син ташлама йортны, Гөлназ,
Утлар янсын бар якта.

Күпме генә тырышсам да,
Йортның эше бетмәде.
Яшьләй дөнья куярмын дип,
Һич кенә дә көтмәдем.

Туганнарым, минем йортны
Булышыгыз корырга.
Улым, сиңа шушы йортта
Насыйп булсын торырга.

Әни-әти, балаларның
Өченчесен күмәсез.
Бала кайгысы авыр ул,
Әле дә ничек түзәсез.

Алдан язылган булса да,
Белеп булмый язмышны.
Улым, үсеп, син зур булгач,
Кабатлама ялгышны.

Ядегәр авылында Әсхәдуллина
Вәсилә Нурмөхәммәт кызыннан (1947)
язып алынды

## Уен җырлары

Галия, Сәрия, Рәйана гөлләрегез,
Әллә кемне сөяр кебек
Иде күңелләрегез.

Исемнәре Нурәхмәт,
Ерак юлны якын итеп
Кайтуларыңа рәхмәт.

Зәңгәрле димәгәннәр,
Матур итеп үстергәннәр,
Күз тияр, димәгәннәр.

Төягәннәр гөлҗимеш,
Ике кулы кесәсендә,
Начальник булган имеш.

Талда яф(ы)рак кына,
Венера йолдызы кебек,
Яшә ялтырап кына.

Чыршының бүрәнәсе,
Йөзләрендә кояш уйный,
Гәүдәңдә – күләгәсе.

Сәрдекбаш авылында Фидалия
Миңлемуллинадан (1965) язып алынды

Әй, аның үзәннәре,
Уеннарны ямьләндерә
Башка авыл гүзәлләре.

Кашың кара кыйгачтыр,
Синең сөйгән ярларың да
Үзең күк сандугачтыр.

Кара кияр чакларың,
Сайлап сөй, дустым, сайлап сөй,
Сайлап сөяр чакларың.

Исеме Хәербанат,
Аермады сезне дошман,
Аерды военкомат.

Армиядә сафларда,
Син аны көтәргә тиеш,
Карамыйча ятларга.

Исеме матур – Вахит,
Кесәңә ислемай тыгып,
Кызлар эзләргә вакыт.

Исемнәре Әшерәф,
Кашы кара, буе зифа,
Бераз гына яшерәк.

Исемнәре Нурулла,
Карасам, күзем чагыла
Йөзеңдәге нурыңа.

Гармун уйный беләсең,
Уйна гармун, тотма гыйшыйк –
Саргаерсың, үләрсең.

Исемең үзем куштым,
Нәселегезгә бер булып
Үсәсең инде, дустым.

Урталарга чыгуларың,
Кыланып торуларың,
Кыланып торуларыңа
Онытыла җыруларың.

Скипидар кушканнар,
Егетләргә әниләре
Җырламаска кушканнар.

Әрем чүмәләләре,
Уйнамагач ник килдегез,
Печән чүмәләләре.

Исемнәре Биктимер,
Ярларыңны җепкә тезеп,
Клиндер итеп кимер.

Алма юган су бит ул,
Сөйгән ярың кич чыкмаса,
Бигрәк ямансу бит ул.

Безгә киләсеңме әле,
Ярларыңны ятлар алган,
Шуны беләсеңме әле?

Бөдрә чәчең күренсен,
Авыл саен яр сөясең,
Ышанычлы түгелсең...

Борылып ага инеш,
Нинди теләкләр теләсәң,
Шул теләгеңә ireш.

Ки әле галошыңны,
Бер кычкырып җырла әле,
Яратам тавышыңны.

Исәпләшә белдегез,
Мәкнең алсу чәчәгедәй
Күземә күрендегез.

Гармунның бакалары,
Нур өстенә нурлар сибә
Ак күлмәк якалары.

Армиядә бит әле,
Сагынсаң да, тагын бер ел,
Тагын бер ел көт әле.

Безнең авыл ак балчык,
Ак балчыкны атлап чык.
Безнең класс егетләре
Бигрәкләр дә мактанчык.

Күгәрченнәр гөрлидер,
Гөрлидер оясында.
Без егетләрне күрәбез
Хайваннар дөньясында.

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр калайлар.
Безнең класс егетләре –
Туксан яшьлек бабайлар.

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырламый тормыйк әле,
Ал чәчәк күк яшь гомерне
Бушка уздырмыйк әле.

Сагынып көттегезме безне,
Дус күреп килдегезме.
Сездә очрашканнан бирле
Сагынып көттек сезне.

Каралар тигәләгән,
Кояш синең йөзләреңә
Нурларын сибәләгән.

Исеме уелмаган,
Йөзләреңдә кояш уйный,
Ай гына куелмаган.

Сәрдекбаш авылында Сәгъдиева
Наилә дәфтәреннән язып алынды

*«Симет» көе*

Дустым, уртага кергәнсең,
Әйләнмиме башларың?
Язарга торган каләм күк
Синең кара кашларың. } 2

Тәрәзә ачып, җимнәр сиптем,
Ашагыз, кошкайларым.
Мәкнең алсу чәчәге күк
Яшәгез, дускайларым. } 2

Урталарга керүләрең,
Елмаеп торуларың.
Елмаеп торуларыңа
Онытыла җыруларың. } 2

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Гандәлиф.
Артларыннан карап калам,
Былбыл микән әллә, дип. } 2

Югары Чура авылында Егорова Зоя
Михайловнадан (1941) язып алынды

*«Өчле» биюе җырлары*

Тартма, егет, тәмәкеңне,
Мыегыңны көйдерер.
Бу Чураның егетләре
Сөймәсәң дә сөйдерер.

*Кушымта:*

Ай-һилләү-һилләү-һилләү,
Утыз кызга бер кияү,
Анысы да аяксыз,
Йөри алмый таяксыз.

## Туй-мәҗлес җырлары

Безнең урман – куе урман,
Боланнар ас(ы)рагыз.
Кызыбызны сезгә бирдек,
Какмый-сукмый ас(ы)рагыз.

Пешереп бирәм белен,
Өйдәгеләр тышка чыкса,
Кисеп алырбыз телен.

Безнең урман – куе урман,
Бөрлегәннәре белән.
Без утырабыз дус-ишләрнең
Бер дигәннәре белән.

Рәхмәтләр яусын ашыңа,
Дәүләтләр яусын башыңа,
Пар алма күк тәгәрәп,
Дәүләтләр килсен каршыңа.

Каян гына килдең лә безгәй,
Төшмәенчә генә диңгезгә.
Каршы гына чыгып ала алмадык,
Ачулана күрмәгез, ай, безгә.

Башыңдагы бүрекләрең,
Сиксән сигез өлгесе.
Яхшы атаның балалары
Күз караудан билгеле.

Югары Чура авылында
Егорова Зоя Михайловна (1941)
һәм Никитина Клавдия Ефремовнадан (1917) язып алынды

## Солдатка озату җырлары

Солдат ашы, солдат ашы,
Солдат ашы май гына.
Кайтырга да күп калмады,
Егерме дүрт ай гына.

Үсә каен, үсә каен,
Үсә каен, яшь булгач.
Берни хәлләр итеп булмый,
Унсигез яшең тулгач.

Сәрдекбаш авылында Миңлемуллина
Фидалиядән (1965) язып алынды

Без капкадан чыккан чакта
Карап калды бер кеше.
Бу хәсрәтне күрми калмас
Ир баласы бар кеше.

Меним әле тау чакта,
Башларыгыз бик кадерле,
Башларыгыз сау чакта.

Югары Чура авылында Никитина
Клавдия Ефремовнадан (1917) язып алынды

## Төрле җырлар

*Ике килен – килендәш*

Ике килен-килендәш,
Берсе – чибәр, берсе – яшь.
«Тарак юк», – дип җавап бирә,
Чәч тарарга иренгәч.

Иртә торып, самовар куйган,
Самовар бик тиз эрегән,
Булса да була киленнәр,
Искитәрлек җебегән.

Ике чиләк кайнар суга
Пот ярымлап он салган,
Пичтә ипи пешә-пешә,
Кара күмергә калган.

Төркәш авылында Гайфуллина Фәнзилә
Динмөхәммәт кызыннан (1914) язып алынды

*Төркәш көе*

Айкый-чайкый керләр юдым
Таш күпер асларында (*2 тапкыр*).
Эзләп-эзләп сөя торган
Иркәм җир асларында.

Аерылабыз, аерылабыз,
Аерылабыз – мин китәм (*2 тапкыр*).
Аерылган кошлар кавышалар,
Кавышырбыз, дип өмет итәм.

Баш яулыгым ике иде,
Берсе суларга акты (*2 тапкыр*).
Төрлебезне төрле якка
Тормыш дулкыны какты.

Чәч үргечем, чәч үргечем
Чәчемне үрер өчен шул (*2 тапкыр*).
Әллә ниләр бирер идем,
Йөзеңне күрер өчен.

Төркәш авылында
Сәлахиева Халисә Зәкиҗан кызы (1921)
һәм Асриева Мөэминә Габделгазиз кызыннан (1922)
язып алынды

*«Алмагачлары» көенә*

Кисәм каен, кисәм каен,
Кисәм дә басма салам.
Каен басмаларга басып,
Кайгымны суга салам.

Сәрдекбаш авылында Миңлемуллина
Фидалиядән (1965) язып алынды

Аклы ситса күлмәгемне
Тузар, димәгән идем,
Яшь гомеремне болай
Узар, димәгән идем.

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр дегетләр.
Булса да була, җегетләр –
Искитәрлек җебекләр.

Безнең бакча башында
Төягәннәр бүрәнә.
Бер үпкәнгә риза түгел,
Тагын үп, дип килә лә.

Төркәш авылында Гайфуллина Фаизә
Динмөхәммәт кызыннан (1914) язып алынды

Алларың булырмын әле,
Гөлләрең булмасам да.
Ярларың булырмын әле,
Гомерлек булмаса да.

Төркәш авылында Сәлахиева Халисә
Зәкиҗан кызыннан (1921) язып алынды

И матур син, матур син,
Матур син, күбәләк син.
Кимә шушы киемеңне,
Күз тияр – үләрсең син.

Яшел пәрдәләр килешә
Пароход ишегенә.
Яры белән бергә яши
Бәхетле кеше генә.

Бучирмә авылында Шәяхбәрова Дамирә
Минһаҗ кызыннан (1939) язып алынды

## Уеннар

*«Бармаклы» уены.* Өстәлгә ике бармакны куялар. Җыр җырлыйлар. Җырның һәр сүзе бер бармакка туры килә. Мәсәлән, мондый җыр җырлыйлар:

Биек тауның башларында
Басуларны гизденме?
Ярың ятлар белән китте,
Әллә аны сизденме?

Җыр кемнең бармагы янында туктап кала, шуңа җәза бирәләр. Аңа карап:

Башымдагы яулыгымның
Бөгеп куйдым бер читен.
Җәза бирүчегә рәхәт,
Үтәү генә бик читен.

Биек тауның башларында
Яшел кыяклы суган.
Ярым бар, дип тормам инде,
Ярым ятларга туган.

Биек тауның башларында
Басуларны изденңме?
Ярың ятлар белән китте,
Әллә аны сизденңме, –

кебек җырларны башкаралар.

Бучирмә авылында Шәяхбәрова Дамирә
Минһаҗ кызыннан (1938) язып алынды

*«Вак бәлеш» уены.* Түгәрәкләшеп, җитәкләшеп басалар. Берәү – уртада. Аңа карап, җырлап әйләнәләр:

Сафа, Мәрьям туена
Пешергәннәр вак бәлеш.
Вак бәлеш, вак бәлеш.

Бөтенесе бергә уртадагы кешене кысалар:

Без дә булдык ул туйда,
Без дә булдык ул туйда.

*«Исакай» уены.* Аулак өйләрдә күңел ачу уены. Күңел ачучы яшьләр янына берәү Исакай булып киенеп керә. Ул иске тун, яки тунны әйләндереп кия. Кулына таяк тота. Капчыгы була. Һәр кешедән берәр әйбер ала. Яшьләр: «Исакай (Истакай?) килгән», «Бабай килгән», – дип каршы алалар. Ул барлык әйберләрне дә, берәр нәрсә әйтеп, бер кешегә бирә.

Төркәш авылында Гайфуллина Фаизә
Динмөхәммәт кызыннан (1914) язып алынды

*«Кәшәкәле» уены.* Урамда, капка төбендә чокыр казыйлар. Тамырлы агач алып, шуның белән шәрәне (шайба яки тупны) чокырга төшерергә тырышасың.

Бучирмә авылында Абдуллина Әминә
Хәкимҗан кызыннан (1921) язып алынды

## Юраулар, фал ачулар

Бер ак яулыкны төреп, баш астына салып ятканнар. Уйлаган кеше төшкә керсен, дип уйлап ятканнар.

7–18 гыйнварда Нардуган уздырыла. Төшлекне 13 гыйнварда салалар. Шушы көнне юрыйлар да.

Кое янында керәшен хатыннары җыелыша. Коедан бер чиләк су алалар. Шунда һәрберсе йөзеген сала. Йөзекләрне берәм-берәм алалар. Һәр йөзекне алган вакытта җыр җырлыйлар. Шушы җырның эчтәлегенә карап, йөзек иясенең язмышын юрыйлар.

Төркәш авылында Гайфуллина Фаизә
Динмөхәммәт кызыннан (1914) язып алынды

## Им-томнар

*Тырнак асты ярылганда.*

...нең кулына
Бур кергән,
Бур тоттым.

*Арпа имләү.*

...нең күзенә арпа чыккан,
Арпа имлим.
1,2,3, ... 9
9 да – тузып китсен,
7 дә – җилгә китсен,
5 тә – бизеп китсен,
3 тә – очып китсен,
1 дә – берлексез калсын,
Минем кулым түгел, Әйшә-Фатыйма кулы.

*Күз тиюне имләү.*

Бисмиллаһи, кар-кар,
Бисмиллаһи, сар-сар,
66 ала күз,
77 кара күз,

Әллә хатын, әллә кыз.
Ходай бирсен шифасын.
Тьфү, тьфү, тьфү.

*Балалары булмаган кешеләрне имләү.* Яңа кое казып, беренче суны балалары булмаган ир белән хатын эчәргә тиеш.

Икесе бүлеп күкәй ашарга тиешләр.

Хатын-кыз балага уза алмаганда, чүлмәк салганнар. Диаметры 15–20 сантиметр чамасы чүлмәкне, шырпы сызып, эчен җылытып, кендеккә ябыштырганнар (банка салу кебек). Бу – кендек борылсын өчен эшләнә.

Төркәш авылында
Сәлахиева Халисә Зәкиҗан кызы (1921) һәм
Әсриева Мөэминә Габделгазиз кызыннан (1922)
язып алынды

*Терлекләрне имләү.* Атның эче авыртса, 3 тапкыр Чирмеш зираты тирәли әйләндергәннәр. Чирмеш зираты Мазар елга өстендә урнашкан.

Чирмешләр яшәгән анда. Хәзер зиратлары бар. Терлекләр авырганда, аларны шул зират тирәли әйләндергәннәр. Алар, кабер газаплары тавышын ишетеп, бик курыкканнар, терелгәннәр, имеш.

Төркәш авылында Сәлахиева Халисә
Зәкиҗан кызыннан (1921) язып алынды

*«Фабрик күпере».* Чишмәбаш белән Зур Сәрдек арасында фабрик күбере дигән урын бар. Ул адаштыра торган җир. Элек монда мануфактура фабрикасы булган. Монда бик күп коллар эшләгән. Бу хәл бик борынгы заманнарда булган. Хезмәт бик авыр булган. Бик күп кеше үлгән. Үлгән кешеләрне күмеп тә тормыйча, рәттән тезеп, өсләренә балчык салып кына барганнар. Чүпрәкне буяр өчен, шул колларның канын агызганнар. Ул бай кисәк кенә бөлгән, аның сәбәбен дә белмәгәннәр. Бу байның каян килгәнен дә белмәгәннәр. Ул килгән кеше булган.

Хәзер шушы урын адаштыра. Анда өрәкләр күренә. Вакытсыз барсаң, алдан берәр кеше, арбалы ат барган кебек күренә. Тракторчылар да бу урында адашып йөри.

Зур Сәрдек авылында Хәсәнова Рәмзия
Сабирҗан кызыннан (1963) язып алынды

## Яңа ай күргәндә әйтә торган сүзләр

Ай күрдем айман белән,
Күңелем тулы иман белән.
Шушы айларда үлә калсам,
Алла озатсын иман белән.

Айга яулык,
Миңа саулык,
Айның йөзе ап-ачык.

Яңа туган айны беренче кат күргәндә уң күз белән карарга кирәк. Сул күз белән карасаң, күңелсезлек килергә мөмкин.

Югары Чура авылында яшәүче
Азина Галина Павловнадан (1960)
язып алынды

## Йола бәйрәмнәре

*Нардуган.* Аны 7–18 гыйнвар арасында уздыралар. Бу вакытта утырмага йөриләр. Кешеләр төрлечә киенеп, кешеләргә кереп биеп йөриләр. Атларны да «киендерәләр». 13 гыйнварда төшлек салалар. Кызлар кемгә кияүгә чыгасын юрыйлар.

Югары Чура авылында
Егорова Зоя Михайловнадан (1941)
язып алынды

*Майлы ботка бәйрәме.* Симет узгач, бер атнадан соң уздырыла. Һәрбер йорттан берәр стакан ярма җыялар. Чиркәү янындагырак бер йортта ботка пешерәләр. Олылар өйдә ашый. Табак белән балаларга да чыгаралар.

«Еллар имин булсын, халык таза булсын, икмәкләр уңсын, Ходай дәүләтне күп итеп бирсен», – дип, иман укыйлар.

Чәчүгә чыккач, поплар тубал белән чыккан, һәр ашлыкны аруландырган, укыганнар. Җиргә йомырка сипкәннәр. Балалар йомырка җыярга чыккан.

Югары Чура авылында
Михайлова Анастасия Федотовнадан (1914)
язып алынды

***Сөрән салу.*** Атка атланып, атның койрыгын төйнәп (ягъни матур итеп бизәп бәйләп), бөтен егетләр матур итеп киенеп, сөрәнгә чыкканнар.

Сөрәнгә, сөрәнгә,
Сөрән бирегез!
Абыстайлар, абыстайлар,
Түтиләр!
Бирегез күкәйләр!
Сөрәнгә, сөрәнгә! –

дип кычкырып барганнар. Җыелган күкәйләрне ялгыз кешегә кереп буяганнар, пешергәннәр. Бала-чага күкәй ашаган.

Бу яз көне була. Аннары Сабан туе була. Көннәр матурлангач, сабан беткәч үткәрелә. Сабантуйдан соң дүртенче бәйрәм – җыен.

*Төенчек җыены.* Төенчек җыены арышка төшкәч үтә. Халык иртә белән арыш урып кайта. Төштән соң җыен була. 3 көн бара. Аның базары да була. Күрше авылы белән бергә, бер көнне уздырыла. Иң элек Җанбай җыены булыр иде. Пыкрау вакытында Ишки җыены үткәрелә.

Төркәш авылында Сәлахиева Халисә Зәкиҗан кызы (1921)
һәм Әсриева Мөэминә  Габделгазиз кызыннан (1922)
язып алынды

*Симек бәйрәме.* Сабантуй алдыннан, тирә-яктагы удмурт авылларында үткәрелә. Березняк (Бучирмә) авылы янындагы удмурт зиратына киләләр. Удмуртлар, әби-бабайларын искә алып, каберләргә ризык куя. Зират янындагы аланда яшьләр (татарлар да) бик күңелле бәйрәм ясый. Бу «Симек» дип аталган бәйрәм. Болыннан чәчәкләр җыеп кайталар.

Бучирмә авылында
Абдуллина Әминә Хәкимҗан кызыннан (1921)
язып алынды

# АЛТЫНГА ТИҢ ХӘЗИНӘЛӘР

*Рәсилә Нурмиева*

Татар халкы йола-бәйрәмнәргә бай. Әмма, кызганыч ки, соңгы вакытларда кайбер йолалар, милли гореф-гадәтләр онытыла бара. Шуларның берсе – җыеннар. Әби-бабаларыбыз элек-электән язгы кыр эшләре тәмамлангач, Сабан туе үткәргәннәр. Сабантуй берничә көн дәвам иткән. Ә инде җир эшләрен бер кат төгәлләгәч, җыеннар үткәрелгән. Бу – халыкның эштән тукталып торган вакыты, җирне аяу, ягъни тынычлыгын саклау көннәре. Һәр авылның үз җыены булган. Чиратлашып үткәрелгән җыеннарга бер авыл икенчесенә кунакка йөргән. Җыеннарда туганнар-дуслар очрашкан, кешеләр бер-берсе белән танышканнар. Самоварлы табыннар янында уенкөлке сөйләшкәннәр. Яшьләр бер-берсен күзләгән.

Инде онытылып баручы әлеге йоланы Уразай авылы халкы торгызып җибәрде – биредә мөселманча авыл җыены уздырдылар. Җыенга авыл халкы, кайткан кунаклар, тирә-як авыллардан җыелганнар иде. Барча кеше шәригать кануннарына туры китереп киенгән.

Кукмара районындагы фәнни экспедициябез вакытында миңа шушы җыенның шаһите булырга туры килде. Аның төп оештыручылары: шушы авылның имам-хатибы Нәҗмиев Ислам Рәис улы, авыл җирлеге башлыгы Нәбиев Илгиз Мозакир улы һәм җыр сәнгате укытучысы Мифтахова Гөлсөяр Мансур кызы. Җыенны Ислам хәзрәт Аллаһы Тәгаләдән илебезгә-халкыбызга, барчабызга тыныч-имин көннәр, саулык сорап, авылдашларының тормышкөнкүрешенә кыскача күзәтү ясап башлап җибәрде. Хәзрәтнең улы Коръән сүрәләре укыды. Бу затларга сокланмау мөмкин түгел.

Җыенда барысы да җиренә җиткереп оештырылган иде. Иң беренче күзгә ташланганы – балаларга булган игътибар, алар өчен

махсус уен мәйданчыклары, атындыргыч-карусельләр урнаштырылган.

Саматов Габделсамат Хәйдәр улы авыл халкын, кунакларны пылау белән сыйлады.

Фәйзуллин Нурсил Нурислам улы сый-нигъмәттән сыгылып торучы чәй өстәле әзерләгән. Ислам хәзрәтнең хәләл җефете әзерләгән, телеңне йотарлык бәлештән һәркем авыз итте.

Бәйрәмне исә Гәрәева Рәмзия Илдус кызы (КДМСУ студенты) бик оста алып барды. Ә берсеннән-берсе кызыклы, үзенчәлекле уеннарны авыл халкы һәм кайткан кунаклар оештырды. Әлеге уеннарда һәммәсе – өлкәннәр, яшьләр һәм бала-чага да теләп катнашты. Һәр катнашучыга бүләкләр тапшырылды. Авыл үзешчәннәре үзләренең җырларын бүләк итте. Су буендагы болынлыкта халык моңнары яңгырады. Баянчы һәм җырчы Гөлсөяр ханымның чыгышын бигрәк тә үз иттеләр. Әлеге мизгелләрне сүз белән генә аңлатып бетерү мөмкин түгел. Мондагы халыкның бердәм булуы сокландырды. Бигрәк тә дин әһелләренең халык белән бергә эшләве, яшәве, халкы өчен җан атып йөрүе ошады. Әти-әниләрнең балаларын шушы рухта тәрбияләве күпләргә үрнәк булырлык. Сабыйларның шат авазы һаман да колагымда яңгырый. Бөтен дөньяга аклык-сафлык бөркелә иде әлеге мөселман җыенында. Аны, әйтик, «Ак җыен» дип атарга тәкъдим итәргә мөмкин. Әлеге җыен гомерле булсын иде. Милли гореф-гадәтләребезне онытмасак иде.

Гомумән, безнең алдыбызда халкыбызның югалып бетү алдында торган рухи байлыгын мөмкин булганча саклап калу бурычы тора. Алтын җирдә ятарга тиеш түгел. Кукмара районында яшәүчеләр белән аралашу вакытында шунысы сөендерде – өлкәннәр арасында үзләренең яшьлек чорындагы гына түгел, әти-әниләреннән, хәтта әби-бабаларыннан өйрәнеп калган йола-гадәтләрне, җырларны хәтерләүчеләр, әле дә саклап, үтәп килүчеләр бар. Әйтик, Бурсык Елга авылында туып, шунда гомер кичерүче Рәхмәтуллин Миңнерәхим Рәхмәтулла улы (1946) шундыйлардан.

Ул күпкырлы талант иясе: гармунда уйный, җырлый, агачтан йорт җиһазлары ясый. Районда агач осталары арасында үткәрелгән конкурста беренче урынны алган. Йортын да ул үз куллары белән төзи, барлык җиһазны агачтан үзе ясый.

Районда милли йолаларны, халык иҗатын саклаучылар белән дә очрашырга туры килде.

*Сабантуй.* «Сабантуйга яулык җыйганда урам буйлап йөриләр. Яшьләр култыклашып җырлап бара торганнарые. Капка төбендә хуҗаларны мактыйлар:

Ай, диләр, вай, диләр.
Фазылҗан абыйларны бай, диләр.

(Кемгә кирәсең, җырга шул хуҗаның исеме кушыла.)

Шулай иттереп, исәнләшәсең алар белән. Каршы чыккан хуҗалар, мөмкинлекләренә карап, сөлге, яулык бирәләр, акча, йомыркалар... Бөтенесен җыеп, атлар белән сабантуйга алып төшәләр.

Сабантуйны дин әһелләре башлап җибәрә. Алар Ходай Тәгаләдән уңдырышлы еллар сорап, илләргә хәвеф-хәтәрсез яшәргә, чәчкән игеннәрне югалтуларсыз җыеп алырга язсын, диеп, үзләренең нәсыйхәтләрен бирәләр. Сабантуй узганнан соң, икенче көнне яшьләр җыелышып, тәмле-томлы әйберләр алып, урманга менеп бәйрәм итәләр. Ул *«күрин»* дип атала. Кызлар-егетләр үзара танышалар шунда».

*Солдатка озату.* «Солдатка озатырга өйгә чакыралар. Табын әзерлиләр. Ишегалдында, капка төбендә бииләр. Кызлар кулъяулык чигеп китерәләр. Егет кулъяулыкларны армиягә алып китә».

*Таудан йомырка тәгәрәтү.* «Кесәңә берничә йомырка алып, тауга менәсе. Таудан йомырка тәгәрәтә башлыйсың. Билгеләнгән әйбергә тидерсәң, ул синеке була. Тидергәч тагын берне тәгәрәтәсең, тидермәсәң – синеке анда кала. Аннары чираттагы кеше тәгәрәтә».

*Әйлән-бәйлән уены.* «Егетләр, кызлар кара-каршы басып, егетләр – кызларга, кызлар – егетләргә җырлый торганые:

Кашың кара, буең зифа
Талларга үреләсең
Талга карап, сиңа карап,
Син матур күренәсең.

Аннары кызлар сиңа җавап бирә торганые».

Бурсык Елга авылында
Рәхмәтуллин Миңнерәхим Рәхмәтулла улыннан (1946)
язып алынды

## Кызны кияүгә озату җырлары

Иртән торып тышка чыксам,
Аккошлар җим эзлиләр.
Аккошлар йөри җим эзләп,
Мин йөрим сезне эзләп.

Шыбыр-шыбыр яңгыр ява
Баскыч түрдә ташларга.
Исеме – җирдә, урыны түрдә
Булсын иде гомергә.

## Кода-кодагыйга аталган җырлар

И туганнар, килдегез дә,
Исәнләшә белдегез.
Майның алсу чәчәге күк
Күземә күрендегез.

Тәрәз төпләрендә, ай, тутый кош,
Ак мамыклар белән тоттык без;
Безнең бәбкәбез сезнең кулда,
Какмый да, сукмый да тотыгыз.

Калошларың сырлы-сырлы,
Сырсыз булса, тая ул.
Бу илләрдә, бу җирләрдә
Сезнең күкләр кая ул?

Җылы якка очкан чакта
Санадым мин кошларны.
Күп эзләдем, табалмадым
Сезнең кебек дусларны.

Сәрдәүч су буйларыннан
Чәчәк җыйдым бер бәйләм.
Сезнең белән бер күрешү,
Бер сөйләшү – бер бәйрәм.

Ындыр арты тигәнәк,
Яңгыр ява сибәләп.
Ашадык-эчтек, хөрмәт күрдек,
Тау итиек бергәләп.

Биек икән тавыгыз,
Каршы ява карыгыз.
Без килдек тә, кунак булдык,
Инде үзегез килегез.

## «Чүпләмле» уены җырлары

Уртага син баскансың,
Әйләнмиме башларың?
Сандугач канаты кебек
Синең кара кашларың.

Яңа Сәрдек авылында Гарипова Гөлниса
Бәдертдин кызыннан (1940) язып алынды

Исемнәре Әлфинур
Бер битендә кояш уйный,
Бер битендә балкый нур.

Укы, дустым, алга кит,
Алган белемнәрең белән
Җәмгыятькә файда ит.

Син бит минем туганым,
Саф мәхәббәт чишмәсе
Битләреңне юганың.

Манара сырлатканчы,
Үзем чыгып җырлыйм әле
Дусларны җырлатканчы.

Аягыңда күн итек,
Урталарга чыгасың да,
Торасың матур итеп.

Биек тауның башларында
Аю уйный чылбырда.
Менә сиңа мәк чәчәге,
Дисәләр дә урнында.

Исемнәре Хәдичә.
Ничә сәгать сөйләштегез
Капка төбендә кичә.

Кашың кара кыйгачтыр,
Синең сөйгән ярларың да
Үзең күк сандугачтыр.

Чынаягы чын икән,
Матур, диләр, матур, диләр,
Матурлыгы чын икән.

Кашыңа күз тимәсен,
Кашың кара, буең зифа,
Сине кемнәр сөймәсен.

Кибетләр электоры,
Менә шушы була инде
Клубның директоры.

Ничек кулың тирләми?
Бу кадәрле чибәр булып,
Кайда үстең чирләми?

Ак ипинең телеме,
Менә шушы була инде
Төркәш авылы килене.

Төркәш авылында Зиннәтов Нәфыйкъ
Кыяметдин улыннан (1959) язып алынды

## «Борылдырыш» уены җырлары

Безнең авыл урамында
Уйныйлар борылдырыш.
Борылдырыш уйнаганда,
Булмасын ялындырыш.

Тау башында ике каен,
Берсен кисәргә кирәк,
Берсен киссәң, ялгыз кала,
Ялгыз нишләргә кирәк.

## «Наза» уены җырлары

Кызыл шарф муеныңда,
Килгән-киткән кунак кызлар
Бар да синең куеныңда.

Килдеңмени, синмени;
Зәйтүн гөле өч тармаклы,
Аның берсе синмени?

Ак ипинең телеме;
Менә шушы була инде
Биктимернең килене.

Казлар кайта бодайдан;
Кеше ярына кызыкма,
Үзең сора Ходайдан.

Итәгем сырлатканчы;
Үзем җырлап чыгыйм әле,
Кешегә җырлатканчы.

Исемнәре Мәрүсә;
Синең баскан эзләреңә
Матур гөлләр үсә.

Исеме Иванмыни?
Киләсез дә, утырасыз,
Бу сезгә диванмыни?

Оштырма Юмья авылында
София Александровна (1969) һәм
Анатолий Александрович (1956)
Ивановлардан язып алынды

Эчке күлмәк челтәрең;
Мин синең көндәшең түгел,
Көнләшмә, көнче тәре!

*Кушымта:*
Идел, Идел,
Идел ике икән ул,
Икең ике илләрдә булсаң,
Сагындыра икән ул.

Аклы яулык бәйлә, дустым,
Аклы яулык килешә.
Аклы яулык бәйләгәннәр
Теләгенә ирешә.

Кулымдагы балдагымның
Исемнәре Хәдичә.
Капка төпләренә кадәр
Кемне озаттың кичә.

Ядегәр авылында Әсхәдуллина
Вәсилә Нурмөхәммәт кызыннан (1947)
язып алынды

Су буенда кыек үлән,
Кыеп аласы иде шул,
Мәңге сагынмаслык итеп
Карап каласы иде.

*Кушымта:*
Талы, талы,
Талы бөгелеп тора.
Тагын бер күрәсе килеп
Үзәк өзелеп тора.

Ятмас Дусай авылында Хафизова
Зөлфирә Әсәдулла кызыннан (1939)
язып алынды

Чәчең озын билеңнән;
Шушы матурлыкларың белән
Чыгармаслар илеңнән.

*Кушымта:*
Алсуланып кояш чыга
Таң аткач,
Сагынырга туры килә,
яраткач.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Бикбари;
Кызлар үтеп киткән чакта
Капка астыннан карый.

Ике кашың уелган;
Ике кашың арасына,
Рамил, диеп куелган.

## Түгәрәк уен җыры

Яшьлек бит ул, яшьлек бит ул,
Яшьлек бит ул бер генә.
Яшьлек кебек чәчәк ата
Өйдә яран гөл генә.

Тал ярый, дип, тал кисмәгез.
Тал ярамый өрлеккә.
Өзелеп-өзелеп яр сөймәгез,
Булмый ул гомерлеккә.

Ике кашың уелган,
Ике кашың уелган.
Ике кашың арасына,
Самат, диеп куелган.

## «Бармаклы» уены җыры

Китәм, дисең, китәм, дисең,
Китәм, дисең кайларга?
Ерак булса сәфәрләрең,
Ишетелмәс хәбәрләрең.

Биек тауның башларында
Йөридер ике көек.
Су сипмәгән гөлләр кебек
Йөрибез янып-көеп.

Балыклы авылында Маликова Сания
Шәрәфетдин кызыннан (1928)
язып алынды

## Зәрә такмаклары

Зәр-зәр зәрәки,
Иске-москы кәзәки.
... абый бай, диләр,
Бер гөрәнкә май, диләр.

Зәр-зәр зәрәки,
Иске-москы кәзәки.
Кәзәкиең булмаса,
Кәҗәнекен ал да ки.

Кенәбаш авылында Федорова Галия
Шәйәкбәр кызыннан (1955)
язып алынды

Зәр-зәр зәрәки,
Иске москы кәзәки.
Сыра бирсәң, эчәбез,
Күкәй бирсәң, китәбез.

Ташлы Елга авылында Гәрәева Тәмлина
Әүхәди кызыннан (1932) язып алынды.

Югары Шөн – удмурт авылы. Шунысы гаҗәпкә калдырды: удмурт әбиләре исең китәрлек итеп саф татарча җырлыйлар. «Без үзебез яшь чакта татарча белми идек, нәрсә турында җырлаганыбызны

белмичә җырлый идек», – ди Елизаветта Алексеевна. «Безгә татар җырлары шул хәтле ошый иде», – дип өсти Антонина Николаевна.

Безнең яшь чаклар бар иде,
Киң урамнар тар иде;
Шул урамнарны селкетеп
Йөргән чаклар бар иде.

Әйдә, дуслар, җыелыйк та,
Китик Ленинградка;
Сез дусларны ошатамын
Йөзем-виноградка.

Минем кашым кара түгел,
Караләтам мин кашымны;
Мөмкин булса, чигерер идем
Уналтыга яшемне.

Әйдә, дуслар, җырлыйк әле,
Барыбыз бергә чакта шул;
Озакламый таралырбыз
Төрлебез төрле якка.

Урман якын, сайрый кошлар,
Ник сайрамый сандугач;
Җырлап та карыйм,
Булмый икән аерылгач.

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җыру безгә моң бит ул;
Безнең кебек моңлы бала
Җырламаса, үлә ул.

## Туй җыры

Күршеләргә кунак килгән
Инде нихәл итием,
Кара кашлы ал тавыкны
Суеп кунак итием.

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр патрон;
Чабатага мәче җигеп,
Кунакка кил, матурым.

Зимагур булып йөргәч,
Мин нужаны күрмәдем.
Кара көн, ява яңгыр,
Өстемдәге күлмәгем.

Ындыр арты тигәнәк,
Яңгыр ява сибәләп.
Ашадык-эчтек, хөрмәт күрдек,
Тау итиек бергәләп.

## Кыска җырлар

Лимон сары, лимон сары,
Лимон сары, йомшамый;
Кайгы була, төрле була,
Кайгыга кайгы ошамый.

Минем яныем армиядә,
Военный кием кигән.
Ул да шулай минем кебек
Елын исәпли микән?

Сандугачның балалары
Ике булмый, өч була.
Ялгыз башка кайда да бер,
Таң ата да, кич була.

Алтын кайчылар ялтырый,
Ал ситсылар кискәндә.
Их, дускаем, исемә төшәсең,
Кичке җилләр искәндә.

Сибелә чәчеңнең бөртеге,
Алмый кәле үргәнче.
Аерылмабыз, дускайларым,
Йә син, йә мин үлгәнче.

Эчтек тә, без исердек.
Тәртипсез бала икәнбез.
Авыр заманаларга калдык.
Бәхетсез бала икәнбез.

Югары Шөн авылында
Суякова Анна Семеновна (1926),
Артемьева Елизаветта Алексеевна (1930),
Кошкина Антонина Николаевна (1939),
Артемьева Александра Павловнадан (1937)
язып алынды

Балаларны тәрбияләүдә уеннарның әһәмияте гаять зур. Ядегәр авылының үзәгендә балаларның «Унике таяклы» уенын уйнауларын күреп, мин моңа инандым һәм иң сөендергәне – әби-бабаларның, эти-әниләренең балаларына үзләре уйнаган уеннарны өйрәтүләре, буыннан-буынга тапшырып барулары.

*Унике таяклы уены.* Бүкән өстенә такта куела. Тактаның бер башына бер сөям озынлыктагы 12 таяк салына. Шуннан соң балалар санамыш ярдәмендә гөрләүче сайлыйлар. Ул берәр багана, өй почмагы һ.б. янына барып «гөрли». Калганнары кача. Качучыларның берсе тактаның икенче ягына басып, таякчыкларны күккә чөеп китә.

Гөрләүче килеп таякчыкларны тактага тезә кала, шул арада балалар кайсы-кая яшеренәләр. Гөрләүче эзләп йөргәндә, берәр бала тактага килеп таякчыкларны һавага чөйдереп җибәрә алса, гөрләүче һаман үз урынында кала. Әгәр ул тактага басарга ирек куймыйча, барлык балаларны да табып-күреп тактага таягы белән сугып өлгерсә, яңа гөрләүче сайлана.

